PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ПЕНСИЯДӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР
картаерга иртәрәк

ИЯРТЕП КИЛГӘН БАЛА
икенче ир өчен кем ул

ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА СЫЙЛЫЙ
азу

Раушания БӘДРЕТДИНОВА:

КҮҢЕЛЛӘРГӘ АЧКЫЧ ЯРАТУ – ҮЗ КУЛЫБЫЗДА

Минем өчен син һаман да – 17дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә...
...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза!
Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Зиннур МАНСУРОВ

ШИГЪРИЯТ АЛИҺӘСЕ

Розага

Аның белән ярәшүле идем,
син — Җир кызын эзләп тапканда.
Ачуланма,
өйдән чыгып китсәм,
таң нурлары тәрәз какканда.

Бу дөньяга шагыйранә карап
яши алмам, сине сөймәсәм.
Ә ул төшкә ешрак керә бугай,
аның белән күбрәк сөйләшәм.

Сулышымны кысып, сарыла ул —
күңел кочагыңны җәй генә...
Минем хакта начар уйлама син,
соңлап кайтсам кичке чәеңә.

Бу сөюдән аралармын, димә,
зынҗырлары аның тап-таза!
Юк, көндәшең түгел ул алиһә —
уртабызга кереп ятса да.

Бер тамырдан үскән куш каен сез,
икегез дә — минем язмышым.
Тик өчәүләп яши алмый торган
шагыйрь хатыннары азмы соң?!

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Роза ханым.
1973 ел.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Газинур Хафизов

Җитәкче-баш мөхәррир
Г. И. кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Раушания Бәдретдинова
Фото: Татьяна Франк

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
1.10.2018 ел
Заказ Е-2617
Тираж 4831

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)


Банк реквизитлары:
Филиал АО "ТАТМЕДИА"
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002











٢٦نچی محرم ١٣٣٢ سنه. ١ نچی دیکابر ١٩١٤ سنه.

سویم بیکه ١٣٣١

٣ – صان

مندرجات

اعلان
































Баш мөхәррир сүзе



Бөтен нәрсә үзгәрештә. Еллар, чорлар, вазгыять үзгәрә, буыннар алмаша. Ә без һаман шул: 105 еллык «Сөембикә» нинди генә чорда, нинди генә вазгыятьтә дә гаилә кыйммәтләре, әхлак һәм милләт мәнфәгатьләре сагында. Хатын-кызларның якын дусты, киңәшчесе, сердәше ул. Журналны «Азат хатын» чорыннан алдырып килүчеләр дә, «Сөембикә» исеме белән якын итүчеләр дә бу сүзләрдә хилафлык күрмәс. Әйе, без заман белән атлыйбыз, һәр саныбызны тагын да кызыклырак, баерак итәр өчен эзләнәбез, яңа сәхифәләр уйлап табабыз, тик максатыбыз барыбер бер: безнең сезгә үз, якын, кирәкле буласыбыз килә.

Бу көннәрдә Сөембикә рухы белән яшәдек. Әйе, Сөембикәнең үзе белән! Махсус безнең юбилейга диярсең, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Сөембикә» операсының премьерасы узды. Операның тарихи һәм милли кыйммәте турында кайта-кайта сөйләрләр, язарлар әле, бүген сүзебез ул хакта түгел. Сөембикә ханбикә – милләт тарихы, милләт фаҗигасе. Ә операда без аны бөтен хатын-кызлар фаҗигасен үзенә туплаган образ итеп тә күрдек. Нинди генә хәлдә калганда да, хатын-кыз күңелен бары хатын-кыз тирәнтен аңлаган. «Сөембикә» журналы да еллар дәвамында сезнең күңелегезне аңларга һәм сезнең белән бергә вазгыятьне аңлашырга теләгән басма. Ханбикә исемен йөртү исә, горурлык һәм дәрәҗә булу белән бергә, җаваплылык та өсти.

«Сөембикә»гә – 105! «Сөембикә» бүген инде икенче гасыр тарихын яза. Аңа нигез салучыларга да, безнең заманнарда мөхәррирлек иткән һәм бүгенге көнгә алып килгән Асия Хәсәнова, Венера Ихсанова, Роза Туфитуллова, Фирая Бәдретдинова, Ләйсән Юнысовага, журнал редакциясендә эшләгән хөрмәтле ветераннарыбызга, актив хәбәрчеләребезгә, төрле төбәкләрдә яшәүче дусларыбызга, партнерларыбызга һәм, әлбәттә, сезгә, кадерле укучыларыбыз – туташлар һәм ханымнар, олы рәхмәтләребезне җиткерәбез! Безнең янда Сез булмасагыз, ул тарих булмас иде. Бу – безнең уртак бәйрәмебез. Киләчәктә дә бергә булыйк!

Гөлнара САБИРОВА



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



26
ҖАНГА АЧКЫЧ
Гөлнур Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



«КАРТАЙМЫШ КӨНЕМДӘ ЯЛГЫЗ КАЛДЫРМА...»
Мәдинә Авзалова
6



20
«ЭЛЕККЕГЕЛӘР ДӨРЕС ЯШӘГӘН...»
Ландыш Әбүдәрова



САЛАВЫЧ САНДУГАЧЫ
Эльмира Закирова
16

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



30
АЛТЫН КОЕЛГАН ҖИРДӘ
Лилия Гәрәева


Э Ч Т Ә Л Е К

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 

34 СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР
Нурихан Фәттах

ЯШӘЕШ 

40 
КҮБӘЛӘК БУЛЫП ОЧТЫ...
Гөлнур Сафиуллина


48 КУНАККА ГЫНА КИЛИК, ВЫБОРГ
Люция Шәрәфиева

ШУЛАЙ УК: 

12 ХӘРӘКӘТЛӘНҮ – ЯШӘҮ ДИГӘН СҮЗ
Гөлнур Хәсәншина

44 МИН КУРЧАК ТҮГЕЛ!
Чулпан Галиәхмәтова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60 
ҖӘЙГЕ КИЕМНӘРНЕ – САКЛАУГА

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ЧИТЛЕКТӘ, ТИК КОШ ТҮГЕЛ. ХАТЫН-КЫЗЛАР КОЛОНИЯСЕННӘН РЕПОРТАЖ

ӘНИЕМНЕҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ. ДИЛӘ НИГЪМӘТУЛЛИНА АЧЫКТАН-АЧЫК СӨЙЛӘШӘБЕЗ

УРЫНСЫЗ КӨНЛӘШҮ ГӨНАҺМЫ? ИЛАҺИ НИЯТ КЫЛДЫМ.

КАППАДОКИЯ: БАШКА ГАЛӘМГӘ СӘЯХӘТ. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ





Фото: Ксения Богданова

«КАРТАЙМЫШ КӨНЕМДӘ ЯЛГЫЗ КАЛДЫРМА...»



Мәдинә
АВЗАЛОВА

КЫЗЫ ЧАКЫРГАЧ, БӨТЕН ҖИР-ЙОРТЫН САТЫП КАЙТКАН КАРТ БЕЛӘН КАРЧЫК ЯРТЫ ЕЛ ДИГӘНДӘ УРАМДА КАЛА.

Әкрен генә, сиздермичә көз килә. Җанга рәхәтлек биреп, күз куандырып утырган агачларның яшел яфракларына да сары төс керә башлаган. Алар саргаер, ә саргайган яфракларны шыксыз көзләрнең салкын җиле бер мизгелдә талап, җиргә очырыр. Картлык та шулай бит. Адәм баласы олыгая, картая барган саен, сары яфрак сыман хәлсезләнә, җиргә чүгә. Ачы тормышның каһәрле мизгелендә аны моңарчы күрмәгән бәла-казалар каршында калдыру берни тормый.

Арчага җыенабыз. Өлкәннәр һәм инвалидлар йортында моңарчы да күп мәртәбәләр булганым бар. Санаулы гына калган гомерләрен тәрәзәгә багып, газиз баласын көтеп үткәргән әби-бабайларның моңсу карашлары, керфек очларында эленеп торган яшь бөртекләре,

нигә килмиләр дигән сорауга: «Вакытлары юктыр, кызым», дип йөрәгемне өзүләре әле дә колак төбендә, әле дә күз алдымда… Андый ишекләр артында җан җәрәхәте, авыр һәм гыйбрәтле язмышлар көн итә.

Ишекне ачып җибәрүгә аллы-гөлле чәчәкләр арасында калабыз. Зәвык белән эшләнгән фонтанлы бакчаны үтеп, түбәсе ремонтланган ике катлы чиста-якты бинага килеп эләккәч, дөньяларын онытып, кайсы нәрсә белән шөгыльләнгән әби-бабайларны күргәч, күңел бераз тынычланып куя. Биредә әле ике генә ел эшләвенә карамастан, зур эшләр майтарырга өлгергән шушы йорт җитәкчесе Гөлназ Галәветдин кызы Төхвәтуллина безне бүлмәдән бүлмәгә йөртеп, таныштырып чыга.

Алар гел нәни бала сыман. Берсен кочакласаң, икенчесен дә кочакларга, берсенә җылы сүз әйтсәң, икенчесенә дә җылы сүз табарга кирәк. Балалар йортларындагы ятимнәр шикелле. Хәер, алар да ятим ич. Дөм ятим. Югыйсә бирегә килеп эләкмәс иделәр. Язмышмы, кармамы, Гөлназ ханым әйтмешли. Ләкин берсе дә бүгенге тыныч тормышларыннан зарланмый. Канәгать алар. Хуҗабикәләренең эшлекле булуыннан, аның сөйкемле карашыннан, һәрдаим кайгыртып, хәлләрен белешеп, аркаларыннан сөеп торуыннан канәгать. Ул килгәч, әнә, ишек-тәрәзәләр, торбалар алмаштырылган, тәрәзәгә яңа өлengeләр эленгән… «Мунчабыз да шәп безнең», – дип мактанышып ала әби-бабайлар. Релаксация бүлмәсенә, табиб кабул итә торган кабинетка да кереп чыктык.

– Шифаханә ич бу! – дим, күргәннәремнән канәгать калып.

– Шуңа якынаерга тырышабыз, – ди Гөлназ ханым. Ул бераз дәшми тора да, әйтеп куя, – яшәү шартларын яхшыртырга була ла ул. Тик һәркайсының безгә михнәтләр күреп, сират күпере кичеп килүен онытмыйк!

Әңгәмәбез үзеннән-үзе көннәрен Өлкәннәр йортында кичерергә мәҗбүр булганнар язмышына барып тоташа.

«Мин аны кичермим»

Кайда күрдем соң әле ишекләренә фотосын һәм исемен язып куйган бүлмәләрне?! Әйе, исемә төште: яман шеш авырулы балалар ята торган «Фәрештәләр» йортында. Монда да шулай. Әзләп йөрисе түгел. Кемнең кем икәнлеге ишегенә язылган. Бу бүлмәдә ирле-хатынлы Клара белән Рәис Абдуллиннар яши. Монысын да керә-керешли үк беләбез. Якты-чиста бүлмә, телевизоры, шунда ук бәдрәфе, юыну бүлмәсе, балконы… Тыныч кына көн күреп яту өчен барысы да бар шикелле. Ләкин тыштан гына шулай күренә, тыштан гына кайгы-хәсрәтсез кебек.

«Йорт» хуҗасы Рәис абый (егетләрчә җитез, чандыр гәүдәле, җор телле бу кешегә «бабай» дип әйтергә тел әйләнми) каршындагы караватта утырган ак яулыклы әбигә күз төшергәли-төшергәли сөйли. Алар икесе дә сиксәннән узган.

– Авырдан йөри, аяклары сызлый, – ди бабай күк чәчәгедәй зәп-зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп ирен күзәткән карчыгы турында. – Гомер буе балалар дип яшәдек. Ике кызга да югары белем бирдек. Укысыннар, кеше булсыннар дип, Мәскәүгә кадәр җибәрдек. Хатын үзе ятим үскәч, балалар кыенлык күрмәсен, җитешсезлектә үсмәсен дип, аларны артык иркәләде. Менә шуның нәтиҗәсен күрәбез хәзер…

Рәис абый, «әйтергә оялам» дия-дия, күз яшьләрен сөртә-сөртә сөйләвен дәвам итә. Хәйран калып аны тыңлыйбыз. Шундый хәл дә була микән? Дөнья гизгән, Амур өлкәсе, Якутия якларында – шофер, хәвефле дип саналган уран шахталарында озак еллар шахтер булып эшләгән, хөкүмәтебезнең олы бүләкләренә – Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Шахтер даны» билгесе, башка Мактау кәгазьләре һәм дипломнарына ия булган кешенең гомер көзләре Өлкәннәр йортында тәмамланыр дип кем уйлаган менә?! Эшләп акча туплаганнан соң, алар Ташкентка күченеп кайта.



■ Ул һәркайсын килеп кочаклый, коридор буйлап куелган диваннарда җай гына утырышып алып, гәп куерткан ак яулыклы әбиләрнең башыннан сыйпап үтә. Мин дә берсен кочаклап алам. Гөлназ ханым миңа: «Инде хәзер башкаларын да…» – дип, янәшәдәге әбиләргә ишарәли.

– Элек бушлай фатир алу өчен дистәләгән еллар эшләргә кирәк иде. Ә миңа бер ел эчендә бирделәр, – дип, янә хатирәләргә бирелә ул. – Эшкә булган идем анысы.

Теләкләр кабул булсын: ялгыз калдырма, Раббым…

Тормышлар әйбәт. Бер кызыбыз – Ташкентта, икенчесе – Казанда. Казандагы кызыбыз белән гел хәбәрләшеп тордык. «Картаябыз инде, әниең дә начар йөри», – дип әйткәч, «Кайтыгыз, бергә торырбыз», – дип, безне үзенә чакырды. Үз балаң бит, ышандык… Фатирны 35 мең долларга сатып җибәрдек. Ул чагында чик аша чыкканда 1 мең доллар гына алып чыгарга ярый иде. Аның да хәйләсен таптык. Кызыма шундук 25 мең доллар тоттырдым. 5 мең долларын калдырдым. Күземә операция ясаттым. Ул арада җиде айлап вакыт узып китте. Кияү белән кызның безгә мөнәсәбәтләре турында сөйләргә дә кыенсынам. Чит кеше дә шулай итмәс. Аңладык: болар безне чыгып китәргә мәҗбүр итмәкчеләр. «Болай җәфаланганчы машина астына ташлан. Йә булмаса, өске каттан сикер», – ди кияү. Күрмәгән, ишетмәгән калмады. Җиде ай дигәндә, бер тиен акчасыз урамда калдык. Кая барырга, кемгә килеп тезләнергә?.. Шунда бер егет белән бер кыз

PRESSA



■ Рәис абый: «Әнисе әнә: «Кичерәм, балаларым бит», – ди. Ә мин кичермим. Ходай сезгә күрсәтсен, дим. Әти кешенең ризалыгын алмаган бала беркайчан да бәхетле булмый. Коръәндә шулай язылган. Әни кеше кичерә ул. Шуңа да әни бит ул!»

■ Республикада ялгыз карт-карчыкларны гаиләгә алып тәрбияләү программасы эшли башлавын хәбәр иткән идек инде. Бер генә өлкән кешене бәхетле итү дә үзе зур савап. Бибинур апабыз да бәхетле күренә. Һәрхәлдә, үзе шулай ди. «Мин бик канәгать. Ашау-эчү җитәрлек. Өйдә тыныч-рәхәт, кагучысугучы, яман сүзләр әйтүче юк», – ди.



Ә күңелләрендә җанны талап-тырнап торган үпкә-рәнҗү, борчу-хәсрәт...

очрады. Хәлебезне белештеләр, тыңлап-тыңлап тордылар да, кулыбыздан җитәкләп, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына китереп куйдылар. Аларга һәм министрлыкта эшләүче хезмәткәрләргә рәхмәт. Безне бирегә шулар урнаштырды.

Карчык янә аңа кинаяле караш ташлап ала. Мәскәүдән аның хәлен белешергә Ташкентта яшәүче кызының кызы – оныгы кайткан әнә. «Ул мине бик-бик ярата», – ди әби, кыз балага сыенып. Бу минутта аннан да бәхетле кеше юктыр.

– Һәр көнне кич белән уйланып ятам. Аллаһы Тәгаләдән сорыйм: вакыты җиткәч, алып кит, дим. Кеше кулларына гына калырга язмасын! – ди Рәис абый.

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТ

■ Татарстанда бүгенге көндә 26 Өлкәннәр һәм инвалидлар йорты эшли. Һәм анда барлыгы 1859 әби-бабай яши. Чарасыз калган һәм мондый йортларга мохтаҗ булган кешеләргә яшәгән урыннарында социаль яклау бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Хәзер чиратта нибары ике генә кеше тора.

«Беркая китмим. Монда рәхәт...»

– Чын Ак әбине күрәсегез киләме? – ди Йорт хуҗабикәсе.

Килә инде, килмәгән кая?! Без бит шуның өчен килдек тә. Әнә ул башына үзләре теккән, үзләре бизәкләп чиккән килешле калфагын киеп, калфак өстеннән ап-ак яулыгын бөркәп, тәмләп кенә чәй эчеп утыра. Безне күрүгә уңайсызланып киткәндәй булды. Кәүсәрия апа, сиксәннән узган Кәүсәрия әби.

– Сагынасыңмы туган ягыңны?

– Мин бит туган ягымда, – ди әби һәм кеткелдәп көлеп җибәрә.

Ул – Арчаның Мәлсә авылыннан икән. Унике ел фермада сыер сауган, аннары җыештыручы булып эшләгән. Аны, фермада эшләгән җиреннән урлап, Шушмабашка килен итеп төшергәннәр.

– Ике кызыбыз туды, – дип искә ала хәзер ул вакытларны Кәүсәрия әби. – Җиде ел торганнан соң, ирем үлеп китте. Кызларның берсе – Казанга, икенчесе Германиягә китеп барды. Ә мин ялгыз... «Сызланам, берүземә генә авыр», – дигәч, кызым Казанга чакырды. Ә бер елдан инсульттан үлеп китте... Икенче кызым хәзер Германиягә чакыра да, кая инде дим, үләр вакыт җиткәч, бер белмәгән ят җиргә барасың. Монда да бик рәхәт миңа. Үзе дә кайта, дусларына алып китеп, берәр ай минем белән торып китә.

«Асрамага әби алам, кем бирә?»

– Эзләп йөрисе булмады безгә, – дип елмая Гөлнара ханым Котдусова. – Өлкәннәр йорты янызда гына бит. Кызым Гөлия: «Әйдә алыйк та, әйдә алыйк», – дигәч, аның исеменә рәсмиләштердек. Барыбыз бергә шушы зур йортта яшәп ятабыз менә.

Бибинур апа – Апас районыннан. Озак еллар Казанда яшәгән. «Оргсинтез» заводында зарарлы эштә эшләгән. Сөйли башласаң, аның тормышы иң куркыныч әкияттән дә куркынычрак. Язмышы «Татар хатыны ниләр күрми»гә бер гыйбрәт, сабак дип әйтимме. Башта егерме ел бергә матур гына гомер иткән ирен чәнчеп үтерәләр. Аннары 18 яшьлек улын кыйнап үтерәләр. Аннары – 20 яшьлек тагын бер баласын... Белмим, ана йөрәге бу хәлләргә ничек түзгәндер, бу сынауларны ничек күтәргәндер? Еракта калган ул еллар тоташ фаҗигадән торса да, ике сүзнең берендә шул вакытларга әйләнеп кайта.

– Бу якларга ничек килеп эләктең? – дигән сорауга җавапны Бибинур апа бик ерактан башлый. Япа-ялгызы калгач, аны Казандагы «Милосердие» үзәгенә алып килгәннәр. Ә бераздан – Арчадагы Өлкәннәр һәм инвалидлар йортына.

– «Милосердие»дә төрмәдән кайткан хатын белән бер бүлмәдә яшәдек, – ди Бибинур апа. –

Кыерсыта иде мине. Шул вакытларда артымнан бер ир кеше йөри башлады. «Миңа кияүгә чык», – ди бу. Ул гомер буе төрмәдә утырган. Кеше белән сөйләшеп тормый, шундук сугышырга тотына. Бик ап-тыраткач, риза булдым. Бер ел тордым да качтым. Бабайны Буадагы Өлкәннәр йортына җибәрделәр.

Котдусовлар гаиләсендә әбигә начар түгел. Гөлнара ханымның кечкенә генә булса да үз эше, үз бизнесы бар. Ул кызы Гөлия белән алмаш-тилмәш туган авылы Яңа Саладагы кибеттә сату итә. Әбине дә алар чиратлашып карый. Дөресен әйткәндә, Бибинур апа карауга ул кадәр үк мохтаҗ түгел. Бакчасына да чыга, вак-төяк эшкә булышудан да тартынмый. Ашарга пешергәндә дә читтә калмый. «Тик торсаң, кызык түгел ич, хәрәкәтләнергә кирәк», – ди чая әби. Котдусовларның олы кызлары Гөлинәнең инде үзенең ике баласы. Кунакка килгән чакларында балалар әби яныннан китмиләр дә. «Әби» инде ул алар өчен. Гөлнараның үз әнисе бик яшьли – 32 яшендә дөнья куйган, аннан – әтисе. Иртә ятим калгангамы, әти-әни, әби-бабай назына сусагангамы, йортка дога кирәк, әни урынына кадерләп тотардай әби кирәк, дип, Өлкәннәр йортыннан Бибинур апаны алып кайталар.

– Илдарым – армиядә. Ул да каршы булмады, – ди Гөлнара ханым безнең белән саубуллашканда. Сүз арасында ире Шаһинурның читкә чыгып китеп эшләве турында да әйтеп ала. Әйләнеп чыкмаслык зур йортка исәнлек-иминлек теләп юлга кузгалганда, әчтән генә белгән догаларыбызны укыйбыз. Бибинур апа әйткәнчә, картаймыш көндә ялгыз калдырма безне, Ходаем. Балаларыбызга игелек, иман бир! Тагын, сискәндереп, Гөлназ ханымның сүзләре искә төшә: «Бездә атказанган бер укытучы яши, – дигән иде ул. – Аның өч кызы бар. Авырый башлагач, шуларның берсенә шалтыраттым. Ә кыз: «Ул безнең өчен күптән үлде инде», – дип аяктан екты». Куркыныч булып китә. Үз балаң шулай дисен әле?! Мондый сүзләрне ишетү өчен нинди начарлык кылырга кирәк булды икән? Һәрхәлдә, әни бит ул! Шуннан соң уйлап карагыз инде ике сүзнең берендә без кабатларга яраткан сүзләр турында: «Картлык – ул шатлык!» Картлык үзе ничек шатлык була алсын?! Картайган көндә балаларыңның игелеген күрү, аларның тәмле сүзләрен ишетү, кайчандыр син аларны наз бишегендә тибрәткән шикелле, балаңның назында коену... Шунысы аның шатлык, шунысы бәхет!

Ә әнине, ана баласын кичергәндәй, һәрвакыт кичереп була.

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТ

Бүген Татарстанда лаеклы ялга чыккан миллионнан артык якын кеше яши. Аларның күбесе – хатын-кызлар, бары 30% ы гына ир-атлар. Узган ел республикада уртача гомер озынлыгы 74 яшь булган: хатын-кызларныкы – 79, ә ирләрнеке 69 яшь. Эштән тукталгач, үзләрен кирәксез итеп тоймасын, гомер көзләрен моңсуланып уздырмасын өчен, пенсия акчаларының бик кечкенә (республикада ул уртача 13954 сум) булуын таныган хакимият төрле яклап ярдәм оештырырга тырыша. Илдә алып барылган «Өлкән буын» проекты Татарстанда да эшли. Аның кысаларында социаль яктан кайгырту, медицина ярдәме, укыту, актив тормыш өчен шартлар тудыру һәм иң мөһиме – картларга карата яшьләрдә хөрмәт уятуга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәр ел саен 70 яшен узып ялгыз яшәгән өлкәннәрнең тормыш шартларын тикшерә. Быел бу эш әлегә 84% ка гына башкарылган. Йорттан йортка кереп танышу нәтиҗәсе шуны күрсәткән: аларның яртысыннан күбрәге үз-үзләрен карый алмый. Ярдәмгә мохтаҗлар. Ата-ана кадерен белгән балалары булса өлкәннәргә җиңелрәк анысы. Ә караучысыз калганнарга булышырга социаль хезмәткәрләр алына. Республикада 45 социаль үзәктә махсус шуның өчен мобиль төркемнәр оешкан. Алар 11 меңнән артык кешегә хезмәт күрсәткән.

Узган ел Татарстанда «Өлкәннәрне тәрбиягә алучы гаилә» проекты эшли башлады. Ятим әби-бабайларны сыендырып, аларны хасиятләп караган гаиләләргә дәүләт ай саен акчалата түли. Өлкәннәрнең сәламәтлеге ни дәрәҗәдә булуга карап ул 4–8 мең сум чамасы. Картлык көнендә язмыш упкыны янында калганнарга 36 гаилә үз җылысын бирде инде.

Күңелләре яшь калганнар – дәрт-дәрманнары ташып торганнар да бар бит әле. Алар өчен булдырылган «Өченче яшь университеты»ның филиалы барлык районнарда үз ишекләрен ачты. Укырга кергән өлкәннәр анда компьютер-интернеттан файдаланырга гына өйрәнмиләр, фәлсәфә, тарих, икътисад, психология, телләр буенча да белемнәрен арттыра алалар. Иң мөһиме: аралашу мохитләре киңәя, чөнки өлкәннәр, иң элек җылы мөгамәләгә мохтаҗ. Сөйләшеп кенә калмыйча, күңел күтәрелеп, җырлап-биеп җибәрергә яки саф һавада бергәләп сәламәтлекләрен ныгытырга теләүчеләр өчен республиканың мәдәният йортларында төрле түгәрәкләр оештырыла. Казандагы «Мәңге яшисе килә», «Жизнелюб», Чаллыдагы һәм Әлмәттәге «Здоровье», «Огонек», «Вдохновение» кебек клублар шәһәрдә генә эшләмичә, авылларга да барып җитсә, анда яшәүче пенсионерлар өчен дә яңа сулыш булыр иде ул. Дөрес, кайбер җирлекләрдәге китапханәләрдә өлкәннәр өчен оештырылган клублар гөрләп эшли. Аларның үз фестивальләре дә бар. Үзешчән башкаручыларның «Балкыш» фестивале – йөзләрчә әби-бабайга яшьлекләренә кайтып килергә, гомер көзләрендә талантларын ачарга мөмкинлек бирә торган үзенчәлекле мәйдан.

PRESSA

ПЕНСИЯ ЯШӘРТТЕ



Гомерем буе көткән пенсиягә кайчан чыгам икән? Офыкта лаеклы ял күренгәннәрне әлеге сорау җәйдән бирле борчый. Дәүләт Думасы пенсияләргә кагылышлы канунга үзгәрешләр кертте. Бу уңайдан ил президенты Владимир Путин да, махсус мөрәҗәгать белән чыгып, үз фикерен халыкка җиткерде. Ил икътисады хакында гына уйлаган түрәләрдән халыкны яклап, пенсия яшен каралганнан бераз киметте. Шул рәвешле, ялга чыгу хатын-кызлар өчен дә, ир-атларга да төгәл биш елга артты. Үзгәреш кертми калып булмый идеме, нинди ташламалар каралган? Бу хакта Россия пенсия фондының Татарстан бүлеге җитәкчесе урынбасары Асия ВӘЛИУЛЛИНА белән сөйләштек.

Асия Зиннәтовна, пенсия системасын үзгәртми калып булмый идеме? Әлеге яңалыкның асылы нәрсәдә?

– Икътисадый яктан бу бик кирәкле үзгәреш. Аның төп максаты – хәзерге пенсионерларның һәм киләчәктә лаеклы ялга чыгучыларның керемнәрен арттыру. Хәзерге вазгыять дәвам иткән очракта, өлкәннәргә түләргә акча җитмәс иде. Статистикага күз салсак, киләчәктә эшләүчеләргә караганда ашаучылар саны күбрәк булачак. Гамәлдәге пенсия яше 1932 елда кертелгән һәм шул заман таләпләренә туры китереп саналган. Бу – тормыш авыр чор, уртача гомер озынлыгы да 45 яшьләр тирәсе генә булган. Бүгенге көндә халык ул еллар белән чагыштырганда озаграк яши. Фаразлар буенча, 2028 елда ирләрнең уртача гомер озынлыгы – 75,1 яшь, 2034 елда гүзәл затларның әлеге күрсәткече 85,3 яшькә туры киләчәк. Соңгы 35 елда Россиядә пенсионерлар саны ике тапкырга: 24 миллионнан 43 миллионга кадәр арткан. 1970 елда бер өлкән яшьтәгегә 3,7 эшләгән кеше туры килсә, киләсе елга бер пенсионерга эш яшендәге ике кеше генә туры киләчәк. Әгәр дә инде рәсми рәвештә эшләгәннәрдән генә чыгып санасак, бу сан тагын да кимеп, бергә-бер генә кала. Татарстанда бүгенге көнгә якынча 3,9 миллион халык яшәсә, шуның 1,1 миллионы – пенсионер, һәм аларның яртысы лаеклы ялга чыккач та эшләвен дәвам итә. Мондый вазгыять бер Россиядә генә түгел, Азәрбайҗан, Молдавия, Әрмәнстан, Балтыйк буе республикаларында да үзгәрешләр көтелә. Алга киткән илләрдә пенсия яше күптән бездәгедән югарырак. Японијадә, мәсәлән, ир-атлар да, хатын-кызлар да лаеклы ялга 70 яшьтән чыга. АКШ, Германия, Франциядә – 67, Бөекбританиядә ир-атлар – 68, хатын-кызлар 60 яшьтә эштән туктый.

Бүген-иртәгә лаеклы ялга чыгам дип сөенеп йөрүчеләр өчен бу хәбәр аяз көндә яшен сугуга тиң булды. Үзгәрешләр хәзерге пенсионерларга кагылмыймы? Алар да борчыла.

– Әйдәгез, сүзне башта хәзерге пенсионерларны тынычландырудан башлыйк. Агымдагы елның сентябренә кадәр теркәлгәннәргә әлеге үзгәрешләр кагылмый. Картлык буенча пенсия билгеләгәннәр икән, алар аны алуны дәвам итәчәкләр. Барлык ташламалар да сакланып кала. Ә иң мөһиме – ел саен югары индексация булачак. Киләсе елга, мәсәлән, эшләмәүче өлкәннәргә түләүне уртача бер мең сумга арттыру каралган. Дөрес аңлагыз, сүз ел дәвамында арткан сумма хакында бара. Кисәк кенә бер мең өстәлүне көтәргә кирәк түгел. Элек исә индексация уртача 300–400 сумнан артмый иде. Хезмәт урыныннан китмәгән өлкәннәргә ул кагылмый. Алар эштән туктагач кына, барлык үткәрелгән индексациядән чыгып исәпләнеп, өстәмәләр түләнәчәк. Пенсия яшен арттыру иң элек 1959 елда туган ир-атларга һәм 1964 елгы хатын-кызларга кагыла. Россия президенты тәкъдиме белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә алар яңа пенсия яшеннән алты айга иртәрәк чыгалар. Пенсия системасындагы күчеш чоры 2028 елга кадәр сузылачак. Ул процесс этаплап – һәр ел саен бер ел кушылып барачак. Хезмәт стажы җитмәгән ир-атлар социаль пенсияне – 70, хатын-кызлар 65 яшькә җиткәч кенә рәсмиләштерә ала.

Асия Зиннәтовна, укытучылар, медицина хезмәткәрләре өчен вакытыннан алда пенсиягә чыгу тәртибе ничек үзгәрә? Сер түгел, мәктәпләрдә һәм шифаханәләрдә эшләүчеләрнең күбесе Бальзак яшендәгеләр. Ә алар өчен пенсиягә алдан чыгу хезмәт хакына зур бер өстәмә иде.

– Алдан пенсиягә чыгу хокукы бирә торган махсус стажга бернинди үзгәрешләр кертелми. Укытучылар, авыл җирлегендә эшләүче табиблар өчен ул 25 ел, шәһәр поликлиникаларында эшләгәннәргә 30 ел. Ә менә алданрак лаеклы ялга китү вакыты әкренләп күчерелә. Пенсия системасындагы күчеш чорыннан соң ул 5 елга чигерелә. Мәсәлән, укытучы, хәзер ничә яшьтә булуына карамастан, быел 25 ел хезмәт стажын тутыра икән, ул аны шунда ук рәсмиләштерә ала. Әгәр дә 2019 елда гына тула икән, анда инде башкача тәртип белән эш йөртәләр. Киләсе елга пенсия яшен бер елга арттыру каралган, укытучының да алдан пенсиягә чыгу вакыты бер елга озынайтыла. Ул аны 2020 елда гына терки алачак. Әгәр инде хезмәт стажы 2020 елда тулса, лаеклы ялга 2022 елда китә һәм шул рәвешле дәвам итә.

Пенсия системасындагы бу үзгәрешләр барлык эшләүчеләргә дә кагыламы?

– Зыянлы производствода, авыр хезмәт шартларында эшләүчеләр өчен барысы да элеккечә калачак. Социаль мотив буенча пенсия билгеләгәннәргә дә яңарыш җилләре тими. Бала күп тапкан хатын-кызларга ташламалар каралган. Мәсәлән, биш баласы булган ана – 50 яшьтә, дүрт баласы булганнар дүрт елга, өч баласы булганнар өч елга алданрак пенсиягә чыга ала. Ир-атның хезмәт стажы – 42, гүзәл затларныкы 37 елга тула икән, ялга чыгу өчен билгеләнгән яшьне көтү кирәк түгел.

ХАТЫН-КЫЗЛАР

арту елы	туу елы	яшь	билгеләнү елы
2019	1964 (I яртыеллык)	55 яшь 6 ай	2019 (II яртыеллык)
	1964 (II яртыеллык)	55 яшь 6 ай	2020 (I яртыеллык)
2020	1965 (I яртыеллык)	56 яшь 6 ай	2021 (II яртыеллык)
	1965 (II яртыеллык)	56 яшь 6 ай	2022 (I яртыеллык)
2021	1966	58 яшь	2024
2022	1967	59 яшь	2026
2023	1968	60 яшь	2028

ИР-АТЛАР

арту елы	туу елы	яшь	билгеләнү елы
2019	1959 (I яртыеллык)	60 яшь 6 ай	2019 (II яртыеллык)
	1959 (II яртыеллык)	60 яшь 6 ай	2020 (I яртыеллык)
2020	1960 (I яртыеллык)	61 яшь 6 ай	2021 (II яртыеллык)
	1960 (II яртыеллык)	61 яшь 6 ай	2022 (I яртыеллык)
2021	1961	63 яшь	2024
2022	1962	64 яшь	2026
2023	1963	65 яшь	2028

ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТ

«ПЕНСИЯ АЛДЫ ЯШЕ»?

Бу категориягә лаеклы ялга чыгарга биш елы калган кешеләр керә. Беренчедән, алар өчен барлык федераль ташламалар саклана (Татарстанда президент Рөстәм Миңнеханов та республикада каралган ташламаларның саклануын әйтте – *авт.).* Икенчедән, квалификацияләрен арттыру буенча түләүсез программалар каралган. Эш бирүче әлеге категориягә кергән кешеләрне картлыкларын сәбәп итеп хезмәт урынына кабул итми йә азат итә икән, моның өчен административ йә җинаять җаваплылыгына тартылачак. Моннан кала, ул өлкәннәр бушлай диспансеризация үтсен өчен, хезмәт хакын саклап калу шарты белән, ел саен ике көн ял бирергә тиеш. Әгәр дә пенсия алды яшендәгеләр эш таба алмый икән, аларга бер ел буена эшсезлек буенча пособие түләнәчәк. Быел түләү 4900 сум булса, киләсе елдан артып, 11280 сум тәшкил итәчәк. Эшкә урнаша алмаганнар ике ел алдан пенсиягә китә алачак. Ил президенты авылда яшәгән эшләмәүче пенсионерларның билгеләнгән пенсия түләүләренә дә 25% өстәмә кертү тәкъдиме белән чыкты. Моның өчен өлкәннәрнең авыл хуҗалыгы тармагындагы хезмәт стажы 30 ел булырга тиеш. Ул киләсе ел башыннан түләнә башланырга тиеш.

Мәгълүмат РФ пенсия фонды сайтыннан алынды.











– Моңа кадәр гел балаларны, оныкларны көйләп яшәлде. «Син бит өйдә утырасың», – диделәр... Күптән түгел суыткычка үземнең күнегүләрнең расписаниесен язып элдем. «Ниндидер ярдәм кирәк икән, моннан соң миңа җайлашырсыз, хәзер вакытым тыгыз...» дидем. Залга шөгыльләнергә йөрүче апаларның берсе әйтә моны. Марина елмая. «Безнең Әлмәттә хәлләр шулайрак хәзер», – ди. Әйе, шулай – күпләр кызыгырлык!

Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

ХӘРӘКӘТЛӘНҮ – ЯШӘҮ ДИГӘН СҮЗ

Марина Попова – «Актив озын гомер» үзәге инструкторы. «Татнефть» компаниясе башлаган яңа социаль проект Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендә яшәгән өлкәннәрнең тормышын ничек үзгәрткәне – аның күз алдында. Дөресрәге, тормышын үзгәртергә теләгән өлкәннәрнең. Барысы да кешенең үзеннән тора: ишекләр бит һәркем өчен ачык. Марина шунда ук саннар теленә күчә: узган ел Әлмәттә ачылган ике үзәкнең берсендә – «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең спорт комплексында урнашканында гына да 7667 кеше шөгыльләнгән. Үзәккә йөрүчеләр быелның сентябренә инде 5 меңгә җиткән.

Ә хәзер күз алдына китерегез.

Мин алтмышны (ә бәлки җитмешне яки сиксәнне) узган өлкән яшьтәге ханым ди. «Актив озын гомер» үзәкләренең берсенә киләм. Ишекне ачып керүгә, инструктор миңа махсус беләзек тапшыра. Залга узып, тренажерларның берсенә барып утырам. (Әйтергә онытта яздым: башта кан басымымны үлчәтәм әле – хәлем әйбәт булган очракта гына, күнегүләр ясарга рөхсәт итәчәкләр.) Беләзек белән кагылуга, тренажерның дисплее яктырып кабына һәм экранда: «Исәнмесез, Гөлнур Мөдәрис кызы!» – дигән язу пәйда була. «Исәнме! – дип дәшәм аңа эчтән генә. – Башлыйбызмы?» («Безгә йөрүчеләр тренажерлар белән гел сөйләшәләр», – дип көлдерә Марина!) Иң беренче көнне үк табибның махсус миңа (!) дип төзегән күнегүләр программасы кулымдагы беләзек аша компьютердан тренажерга тапшырыла. Кайсы күнегүне ничә тапкыр кабатларга, кайда, күпме ял итеп алырга: барысы да дисплейда күренә – миңа аны тыңларга һәм ул кушканнарны җиренә җиткереп үтәргә генә кирәк. (Җиренә җиткереп үтәү дигәннән, ясаган һәр күнегүем дисплей-

да билгеләнеп бала. Аның янында яшел тамга чыга икән, димәк, табиб кушканны тиешенчә үтәгәнмен дигән сүз. Зәңгәр төс чыкса – күнегүләрнең саны язылганнан артыграк та эшләгән дигәнне аңлата. Ә кызыл төс күнегүнең санын киметүем турында сөйли.)

Гадәти тренажерларда күнегүләр вакытында организмга авырлык өстәүне 10 килограммнан тотынсалар, монда нибары 100 граммнан башлана. Һәр адым саклык белән эшләнә – өлкәннәрнең мускуллары авырлыкны кинәт арттырырга мөмкинлек бирми. Күнегүне, әйтик, унбиш тапкыр кабатлауга, программа үзеннән-үзе сүнә һәм: «Сез ял итәргә тиеш» дигән сигнал яңгырый.

Берсеннән икенчесенә күчә-күчә, тренажерларның соңгысына – сигезенчесенә җитәм. (Тугызынчы тренажер – «гравитацион йөгерү юлы» – инсульт кичергән, аяк-куллары сынган, бәрелгән, имгәнгәннәр өчен. Без бит урамда йөргәндә, аякларыбызга бөтен гәүдә авырлыгын төшереп басабыз: аяк буыннарына көч килә. Ә бу тренажерда капчыкка тутырылган һава кешене «күтәрә». Ул хәрәкәтләнә, күнегүләр ясый – барлык мускуллары, буыннары эшли, әмма организмга көч, авырлык килми.)

– Бер, ике, өч! Булды!

Бер сәгатьтән артык вакытның ничек узганын сизмәдем дә... Дисплейда шунда ук язу чыга: «Гөлнур Мөдәрис кызы, сез бүген программаны уңышлы үттегез!» «Рәхмәт!» – бу юлы шатлыктан кычкырып ук эндәшәм...

Йә ничек, ошыймы сезгә, йөрер идегезме?

– Кан басымым көйләнде, буыннар авыртуы кимеде... Тизрәк йөрим, сөрлекмим. Тын кысылмый. Элек икенче катка да кеше ярдәме белән генә менә идем, хәзер берәүне дә көтмим... Башым әйбәтрәк эшли башлады. Хәтерем яхшырды... Үзләрендә булган үзгәрешләрне гел шулай әйтеп тора алар.

Марина хаклы: безгә, яшьрәкләргә, әллә ни алга китеш кебек тоелмаска да мөмкин болар. Әмма алар үзләре – башка фикердә.



Розалия Лотфуллина:

«Татнефть»нең медсанчастенда 25 ел эшләп лаеклы ялга чыктым. Бирелә инде икенче ел шөгыльләнәм. Өч чакрым җәяү киләм, җәяү кайтам: залдан чыккач, өйгә таба атлыйсы гел җиңелрәк... Тренажерлардан соң кан басымы да көйләнә. Моны мин генә түгел, йөрүчеләрнең барысы да әйтә. Аритмия белән җәфалана идем – хәлем күпкә әйбәтләнде хәзер. Безнең өчен бирелә бөтен шартлар да тудырылган: чишенү, душ бүлмәләре



Николай ТЕРЕНТЬЕВ, «Татнефть» ГАҖнең спорт-сәламәтләндерү үзәге начальнигы урынбасары

– Узган ел «Татнефть» компаниясе, аның генераль директоры Наил Мәганов тәкъдиме белән, махсус программа кабул итте – республиканың көньяк-көнчыгыш районнарында «Актив озын гомер» үзәкләре эшли башлады. Әлмәттә, Җәлилдә, Азнакайда, Лениногорскида... Заллар ачу, җиһазлар сатып алу өчен акча бүлеп бирелде. Әлеге үзәкләрнең һәрберсендә тугыз тренажер урнаштырылды. Аларны сайлап алу белән Россия һәм Финляндия табиблары шөгыльләнде. Тренажерларның сигезе – финнарның HUR компаниясенеке. Берсе – «гравитацион йөгерү юлы» – Америкадан ук кайтартылды. Тренажерлар гади түгел: алар барысы да өлкән яшьтәге кешеләр өчен җайлаштырылган. Кысылган һава ярдәмендә эшлиләр, шуңа күрә организмга авырлык артык килми, буыннар, умыртка баганасы стресс кичерми.

«Актив озын гомер» үзәкләрендә «Татнефть»нең үзендә эшләп ялга чыгучылар гына түгел, теләсә кем шөгыльләнә ала. Һәм – бушлай! Татарстанның бу төбәгендә яшәүчеләр өчен компания менә шундый матур бүләк ясады. Яңа проект буш урында гына барлыкка килмәде, әлбәттә. Ветераннарның сәламәтлеген ныгыту программасын киңәйтү турында да күптән уйланыла иде инде. «Татнефть» башлангычы, аның ярдәме белән Әлмәттә «Яшел фитнес» проекты оештырылды. Безнең каланың соңгы еллардагы матур бер яңалыгы, үзенчәлеге! Шәһәрнең төрле сквер һәм паркларында – берьюлы биш урында җәен әлмәтлеләр йога, зумба, калланетика һәм спортның башка төрләре белән шөгыльләнә ала. «Яшел фитнес»ка чыгучылар арасында өлкән яшьтәгеләр дә күп. «Скандинавия йөрүе»н сайлаучылар да байтак: Әлмәттә «Актив озын гомер» үзәген ачканда, «Татнефть» аның таякларын күпләргә бүләк итте.

Безнең спорт комплексында да көн саен җиде йөзгә якын кеше шөгыльләнә. Шуларның утыз проценты – өлкәннәр.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

менә дигән. Башкалар арасында булып, күңелем белән дә ял итеп кайтам: безнең яшьтә аралашыр кешең булу да бик мөһим. Минем үземнең балалар еракта, Мәскәүдә яши. Скандинавия таягын алар бүләк итте – иртәләрен йөреп керергә дә чыгам әле. «Татнефть»нең ветераннар советы бассейнга атнага бер бушлай абонемент бирә: өем янындагы 16 нчы мәктәпнең бассейнына йөзәргә йөрим. Өстәл теннисы уйнарга өйрәнергә күптән хыяллана идем: тәвәккәлләп, язылдым. Атнаның ике көне шунда уза. Тотынсаң, булдырып була икән – инде уйныйм! Ә болай атнаның биш көне буш түгел минем. Кайгыртуны һәрдаим тоеп торабыз, моның өчен генераль директорга бик рәхмәт. Әмма барысы да кешенең үзеннән тора. Яшең ничәдә булуга карамастан, үзеңә туры килгән спорт төре белән шөгыльләнү, сәламәтлегең турында кайгырту – бу һәркем өчен гадәти хәл булырга тиеш. Хәрәкәтләнү – яшәү бит ул... »

Һәр көнне үзәктә алты төркем шөгыльләнә. Килергә теләүчеләр тагын да күп!



Софья Янина:

« Укытучы мин, 61 ел мәктәптә математика укыттым. Балалардан аерылганыма ике ел гына әле. Бер айдан сиксән биш яшемне тутырам менә... Проблемалар җитәрлек: кан тамырлары киңәю дә бар, тромбофлебит, артрит та, ике тапкыр бот башы сөяген дә сындырдым. Тагын холецистит, гастрит... Безнең яшьтә нәрсә авыртмаганын санау җиңелрәктер, мөгаен. Шулай булмыйча, бу гомер эчендә ни генә күрелмәгән бит?! Сугыш вакытында Брянскида, оккупациядә үстем. Сез ул чактагы тормышны күз алдына да китерә алмыйсыз. Көндез – немецлар, кичен, ярдәм сорап, партизаннар килә. Ә кайчак, партизаннар дигән булып, бандитлар ишегеңне кага. Сораган нәрсәне бирми кара, талап алалар – кулларында корал. Безне 1943 елда азат иттеләр. Шундый зур бәйрәм булып истә калган ул... Брянск өлкәсендә педучилище тәмамлагач, юллама белән Казакъстанга, Кустанай өлкәсенә җибәрделәр. Ирем Әлмәттән булып чыкты – бирегә күчеп кайттык. Аның мәрхүм булганына 34 ел инде. Кызым Казан университетын тәмамлады, физик иде. Ире белән икәүләп тауларга йөрделәр, шунда вафат булды. Улым белән бергә яшим, оныкларым бар. «Актив озын гомер» үзәге ачылу турында газетадан укып белдем. Биредә шөгыльләнә башлаганыма тиздән ике ел була инде. Кешеләр янында булу, аралашу өчен дә бик кирәк залга йөрүем. Без тагын кая бара алабыз?! Ә монда музыка да тыңлыйбыз, сөйләшергә дә өлгерәбез. Берәребезнең туган көне булса, чәй дә эчәбез... Чирләрем бөтенләй китми инде, әмма минем өчен аякта йөрү дә бик мөһим. »



Ольга Нагорнова:

« Утыз тугыз ел эшләп, лаеклы ялга чыктым. Мәктәптән киткәнемә инде ун ел, әмма укытуны бөтенләй ташлаганым юк. Балалар белән аралашу минем өчен гел шатлык... Лаеклы ялга чыккач, ике зур проблема туа икән: беренчедән, аз хәрәкәтләнә башлыйсың; икенчедән, аралашу җитми. Күпләрнең тормышы фатир, ишек төбендәге эскәмия, якындагы кибеттән ерак китми бит. Әмма минем алай гына яшисе килми! Шәһәребездә шушындый үзәк ачылуын белүгә, бирегә килдем. Һәм бер дә үкенмим! Чынлыкта, спортка мөкиббән кеше түгел идем. Әмма үзәккә йөри башлагач, үзем өчен тормышның башка ягын ачтым. Спортзалга йөрү миңа ошый икән бит! Хәзер инде тренажерларсыз яши дә алмыйм.

«Татнефть» компаниясенә бик зур рәхмәт: алтын көзебезгә кереп барганда үзебезне тонуста тотарга шундый мөмкинлек бирә. Икенчедән, әйткәнемчә, бирегә йөрү безнең өчен аралашу да ул. Аның никадәр кирәклеген, мөһимлеген олыгайгач аңларсыз... Үзәктә яңа дуслар гына түгел, фикердәшләр таптым, алар да минем кебек картаерга теләми. Менә дигән әйбәт группа җыелды безнең. Алар янында күңелем белән дә, тәнем белән дә ял итәм. «Җитәр сезгә эскәмиядә утырырга», – дип, күршеләремне дә үгетләдем, алар да йөри хәзер.

Бер ел эчендә нинди дә булса үзгәреш булдымы-юкмы? Бер үлчәмгә ябыктым – минем өчен бу бик әйбәт! Шәһәр буйлап дүрт-биш чакрым рәхәтләнеп җәяү йөри алам хәзер. Өченче катка, сумкалар күтәреп, туктамыйча менә алам! Дөрес, мин әле тагын бассейнга да йөрим, йөзәм дә. »

– Дөрес килдемме? «Актив озак яшәү» үзәгеме? Әниемне сезгә алып килмәкче булам. 74 яшь аңа. Паркинсон авыруы белән чирли...

– Рәхим итегез! – дип җавап бирә Марина урта яшьләрдәге бу ханымга.

Кем белә, бәлки, картлыкны да, аңа ияреп килгән чирләрне дә, чыннан да, «алдап» буладыр?!

Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

БҮГЕНГЕ АКЫЛЫМ БЕЛӘН АНЫҢ ЗӘП-ЗӘҢГӘР КҮЗЛЕ АК ЙӨЗЕНДӘ БАРЫ ТИК БЕР ГЕНӘ СЫЙФАТНЫ АП-АЧЫК ИТЕП КҮРӘМ. УЛ ДА БУЛСА САБЫРЛЫК. АКЛЫККА ТӨРЕЛГӘН САБЫРЛЫК...

АКТАН СУККАН, САБЫРЛЫКТАН ТУКЫГАН

Мин туганда әниемнең әнисе Әлфия әбиемә 51 яшь булган. Үземне белгәндә, ул әле колхозда төрле эшкә йөри иде. Аның эштән кайтып кергәндәге мизгелләре бала хәтеремә бер күренеш кебек уелып калган.

Тегермән тоткан Муса белән остабикә Ләйлинур кызы булса да, совет власте урнашып, колхозлашу чорында тугач, аңа хәлле гаилә баласы булуының ачысын гына татырга туры килгән. Ләкин әбием балачагы турында артык бер сүз дә сөйләми иде. Сорасаң, дәшмәс була.

1929 елгылар сугыш афәтен үсмер җилкәсендә күтәргән. Билгеле, үгез җиккәннәр, ач бүреләр улап торган кышта кырдан салам ташыганнар. Җәйләрен, куна-төнә, болында печән җыйганнар. Җентекләбрәк сөйлә әле, дисәң, сүзне икенчегә – замананың иминлегенә бора.

36 яшендә алты бала белән тол калган. Олы кызына – 14, кечесенә 2 генә яшь була ул чакта. Колхоз эшеннән бушаган арада киез каты басып саталар. Болары турында без – оныклар әниләребездән генә белдек, әбиебездән төпченеп сораштыру гадәткә кермәгән иде.

Без үскәндә, өйдә әнә шулай сөйләшергә, кагылырга ярамый, сүзсез генә дә аңлашыла торган темалар бар иде. Аерым кайгы турында да сөйләмиләр, шул ук вакытта илне җимереп узган сугыш хәсрәтен дә искә төшермәскә тырышалар. Онытып булмаганга, кат-кат искә төшермәгәннәр, күрәсең. Дәшмиләр, сабырлык белән күтәрәләр. Ә безнең бәхетле булуыбызны бик тели иде әбиебез. Бәхетне ак төстә генә күрә иде. Шуңадырмы, ул тирә-юнен аклыкка күмде.

Әбиемнең һәрнәрсәсе гел актан гына булырга тиеш иде. Кечкенәдән шул аклык белән үскәнгәме, мин ул әйберләрне бүген дә башка төстә кабул итә алмыйм. Гадәтләнмәгәнмен. Әбиемнең миче һәрвакыт ап-ак итеп акшарланган була иде. Урын-җире дә гел актан. Крахмалда катырып, тәрәзәгә ап-ак пәрдәләр элдерә. Тәрәзә рамнарын бары тик акка гына буята. Өй каршындагы шомырты да яз саен ап-ак чәчәккә күмелә...

Чәй эчә торган йомрылары (ул заманда чәй эчә торган чынаякны шулай дип йөртәләр иде), тәлинкәләре бары тик актан гына. Безнең чорда өстәлгә чәчәкле клеенка җәю гадәткә кергән иде инде (гәрчә элгәре ак ашъяулык җәя торган булганнар), әбиебезнең клеенкасы астында ак тукыма җәелгән була иде. Сөлгеләрне дә гел ак итеп тота...

Кайчан карама, әбиебез эш белән мәшгуль. «Ял итү» дигән сүзтезмәне кулланмый иде диярлек. Ул аны «кич утыру» ди. Ә кич утырганда кулында һәрвакыт эш булыр: йон яза, эрли,ката, бәйли. Ак бәрән йонынннан гына ак оек бәйли иде ул безгә.

Һәм иң мөһиме: яулыгы һәрвакыт ак иде. Шәл астына һәрвакыт киҗемамыктан тегелгән ак яулык бәйли. «Кыз баланың ак яулыгы булырга тиеш», – дип әйтә иде. Күрәсең, аны йөз аклыгы белән дә бәйләп карагандыр. Совет чоры баласы, дин сабакларын әнисеннән өйрәнеп калган кадәресен безгә дә өйрәтте. Өйрәтте дип, кичтән ул догалар кабатлый иде. «Әлхәм», «Аятел көрси», «Колһу алла»ны аның артыннан кабатлап өйрәнгәнгә күрә, кайбер урыннары хаталы булган – соңрак китаптан карап өйрәнсәм дә, әбиемнеке канга ук сеңеп калган, укыганда нәкъ аныңча әйтелә. Ул шулай ук мәктәпкә имтиханга озатканда, үзенчә «өшкереп» җибәрә торган иде: гарәпчә догаларын да укый, үз сүзләре белән келәүләр дә әйтә: «Йа Раббым, бу балага тел ачкычлары бир, зиһенен ачык, күзләрен нурлы ит». Ни хикмәт, ул өшкереп җибәргәннән соң, имтиханнарда иң җайлы билетлар гына эләгә иде. Хәзер үзем дә аның үрнәгендә балаларыма теләкләремне әнә шулай матур калыпларга салып җиткерергә гадәтләнеп киттем. Калганын... әбием үзе үрнәгендә сеңдереп салган тәрбиягә. Тормыштан да, язмыштан да зарланмыйча, сабырлык һәм аклык белән тәрбияләгән ул безне. Аның шушы сыйфатлары безгә артык сүзсез генә, эш-гамәлләре, аның үрнәге аша әманәт итеп тапшырылган сабак булган. Алтын бәһасенә тиң сабак.



Фото: Ксения Богданова

САЛАВЫЧ САНДУГАЧЫ



Эльмира ЗАКИРОВА

Сез Җәмиләне беләсез микән? 70–90 нчы елларда бөтен республиканы шаулаткан пионер-вожатый Җәмилә Сабирова-Сибгатуллина, ягъни Салавыч Җәмиләсе турында әйтүем. Балтачның Салавычын аның исеме белән генә телгә алсалар да, гаҗәпләнмим. Салавыч диюгә, иң элек ал галстуклы Җәмилә күз алдына килеп баса. «Җир белән күк арасында ул. Җирдән атлап кына бармый, каядыр ашкына, оча. Хыял, романтика белән канатланып, үзе дә әллә нинди кызык эшләр уйлап таба, балаларны да, үз артыннан ияртеп, әллә кайларга очырта, күкләргә күтәрә, дөньялар гиздерә, якты уйлар, яңа эшләр белән илһамландыра, үз эшенең фанаты», — дигәннәрен ишеткәнем бар. Үзе гармунчы, үзе җырчы, үзе нәфис сүз остасы, үзе спортчы… Кырык ел буена өлкән пионервожатый булып эшләгән данлыклы Җәмилә бит ул! Республика комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы. ВЛКСМ Үзәк Комитеты аны «Иң яхшы пионер вожатыена» значогы белән бүләкләгән. «Вожатый-инструктор», «Вожатый-методист» дигән исемнәре бар. Комсомолның Үзәк һәм өлкә комитетларының, В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының Үзәк һәм Республика Советларының Мактау грамоталары гына да дистәләп. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Быел район Сабан туенда «Балтачның почетлы гражданины» дигән дәрәҗәле исем тапшырганнар әнә үзенә. Хәер, бүгенгесе хакында соңрак.





Ал галстук аңа килешә

Үзем белгән пионервожатый Җәмиләне искә төшереп карыйм әле. Иң элек «Татарстан яшьләре»нә язган мәкаләләре аша күңелгә уелып калды ул. Татарстан, Мари Иле һәм Киров өлкәсе пионерларының ел да бергәләп кабыза торган «Дуслык учагы» турындагы язмасы аеруча ошаган иде.

Соңрак, «Ялкын» журналында эшләгәндә, якыннанрак та аралаша башладык. «Пионер ялкыны» штабын оештырып, «Һәрвакыт әзер!» Бөтенсоюз маршының «Без синең турылыклы алмашчың, комсомол!» этабындагы маршрутлары буйлап төрле кызыклы идеяләр белән янып йөргән чаклар. Салавыч урта мәктәбенең Муса Җәлил исемендәге дружинасы районда гына түгел, республика буенча алгы сафта икәнен беләбез. Шул хакта өлкән пионервожатыйдан яздырасыбыз килә. Җәмилә Сабирова белән телефоннан сөйләшәм. Әңгәмәбезне ишетеп торган Фәйрүзә Мөслимова (бер бүлмәдә утыра идек): «Җәмилә апа дип эндәшсәң калган. Ул бездән ярыйсы зур бит», – дип әйтеп куйды шунда. Ун яшькә зуррак икән Җәмилә апа. Ә минем өчен ул япь-яшь пионервожатый кыз кебек иде! Моннан берничә ел элек аңардан котлау открыткасы алдым. Кыска гына хаты да бар. «Ялкын»да чәй эчеп йөргән вакытларны сагынып искә алам, дигән. Ахырдан: «Ихтирам белән, онытмаган булсаң, Җәмилә апаң», дип тә куйган.

Онытырлыкмыни! Минем өчен ул барыбер дә яшь, тынгысыз, хыялый, ихлас Җәмилә. Чып-чын пионер вожагы! Тагын әле «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхозның комсомол секретаре, җирле радиотапшыруларны алып баручы (һәр көн иртән Җәмилә: «Тыңлагыз, Салавыч сөйли!» – дип, яңгыравыклы матур тавышы белән авылдашларын сәламли дә, язгы чәчү йә урып-җыю эшләре белән таныштыра, беренче бригадага салам өләшүләре, икенче бригадага ашлык бирүләре турында хәбәр итә), район газетасы «Хезмәт»нең актив хәбәрчесе (газеталарда басылган мәкаләләре белән бер альбом шыплап тулган: андый альбомнарны журфакка имтихан тапшыручы абитуриентлар кабул итү комиссиясенә тапшыра иде), «Туган якны өйрәнү» музее җитәкчесе, мәктәп балаларының җыр укытучысы, спектакльләрдә уйный, концертларда катнаша... Ул җырласамы!.. Салавычларны районда, яратып, сандугачлар дип йөртәләр икән. Җәмилә – үзе Салавыч сандугачы инде!

Күптән түгел Җәмилә Габдулла кызы безнең редакциягә килде. Гади, сабыр, ягымлы, шук-шаян телле – тамчы да үзгәрмәгән. Ә ал галстугы һаман килешеп тора үзенә. Җырлаттык та, шигырь укыганын да сокланып тыңладык. Сөйләшкәндә исә ул яңа яклары белән ачыла барды. Аның дөньясы, тирә-ягындагы кешеләр, төрле вакыйгалар, уңышлар, сөенечләр – һәркайсы матур мизгелләргә төренеп, Җәмилә Сибгатуллина тормышыннан кечкенә хикәяләр булып кәгазьгә күчте.

Салют сиңа, Муса Җәлил!

Җиденче сыйныфтан соң Балтачка йөреп укый башладым. Мин инде гармунда уйный беләм. Апам Язилә клубның «списать» ителгән тальян гармунын алып кайтып биргән иде. Шунда уйнап өйрәндем. Балтач мәктәбенең өлкән пионервожатые Люция апа Кадыйрова кебек пионер рапортлары кабул итәсем, бала-чага белән кайнашып, әллә нинди кызыклы эшләр оештырасым килде. Шигырьләр яратуым, аларны яттан белүем дә ярап куйды. Сценарийлар яза башладым. Кулдан язып утырасы түгел: миңа машинка бирделәр. Җырлый белүем дә ярап куйды. Дәрестә парта артында утырту –бер нәрсә, ә монда теләсә ничек йөргән баланы җәлеп итәргә, тыңлатырга, кызыксындырырга, илһамландырырга кирәк. Миңа бер дә авыр булмады. Дружина үзенең вожатыйлары белән данлыклы иде. Отряд вожатыйлары үзләрен чын укытучылар кебек тота. Шуңадырмы, мәктәпне тәмамлаган пионерларымның күбесе укытучылар хәзер. Иң актив отряд вожатыем Люция Галимуллина – бүген Салавыч мәктәбе директоры Люция Харисовна Закирова. Гөлнира, Зөһрә, Гөлзидәләр дә – укытучылар. Ә чөгендер игү звеносы җитәкчесе Халит Шиһаповка фидакарь хезмәтләре өчен республикабызның Муса Җәлил исемендәге премиясе тапшырылды. Дружинабыз тикмәгә генә Муса Җәлил исемен йөртмәгән, тикмәгә генә «Салют сиңа, Муса Җәлил» дип җырлап йөрмәгәнбез икән шул. Бер Салавычта ике Җәлил премиясе лауреаты яшәсен әле.

Тавышы да яшь ишетелә, үзе дә янып тора!

Яраткан пионервожатыебыз

Мәктәбебездә кунаклар өзелеп тормый. Балтачка килсәләр, Салавычны читләтеп үтмиләр инде. Язучылар, шагыйрьләр, артистлар... Күбесе мине таный да икән әле. Керә-керешкә: «Исәнмесез, Җәмилә апа! – дип сәламлиләр. – Сезне дә беләмскә... Яраткан пионервожатыебыз!» – дип тә куялар әле. Бу хәлләрне күреп торган директорыбыз: «Кунакларны каршылап торырга Сезне генә чыгарасы бар, Җәмилә апа», – дип көлә. Берчак Камал театрында шагыйрь Роберт Миңнуллин әллә каян күреп алып, «Нихәл, Җәмилә?» – дип килеп күреште. Ничаклы халык алдында бит. Күңелле булып китте. Берсендә Балтачтан Казанга барырга торабыз. Такси йөртүче егет миңа карап алды да: «Ә сез гармунчы апай бит әле, әйеме? – ди. – Сезне 150 тәңкәгә генә алып барам», – дип елмая. Калганнарга инде 200 сум.

Спорт буенча район ярышларында исә мине күреп: «Оһо, Җәмилә апа килде, безгә көн юк!» – дип әйтәләр икән. Чаңгы, тенниста, шашкада I, II урыннарны берәүгә дә биргән юк.

Алыштан һәм барыштан булсын!

Шәһидулла белән икебез дә – Салавычныкылар. Ул авылның автомеханигы, әйбәт егет. Очрашып йөри башлагач: «Мин дә яшь түгел, син дә... Йөрсәк, әйдә, алыштан-ба-

PRESSA

рыштан булсын», – диде. Өйләнешик дигән сүзе инде. Мин семинардан кайткач, язылыштык. 1975 елның марты бу. Гадәттә, колхоз рәисе Харис абый бүлмәсендә үтә иде андый тантаналар. Бик абруйлы җитәкче, Социалистик Хезмәт Герое Харис Галимуллинны бөтен республика белә иде... Авыл советы, клуб, китапханә – шунда эшләүчеләр бар да җыелган. Җитмәсә, райком секретаре Фәесханов та килеп керде. «О-о! Җәмилә чыгамыни, котлыйм!» – ди. Аңа кадәр әле үзем концерт куеп йөрим, әрле-бирле чабыпниләрдер хәстәрлим, үзем җыештыручы апага: «И-и миңа бүген кияүгә барырга диләр бит әле», – дип сөйләнәм. Бигрәк беркатлылык инде! «Барырсың, барырсың, Алла боерса», – ди апа да. Ел ярымда өй салды да Шәһитем, мине алып чыгып та китте. Җайлы, тыныч кеше иде ул. Көнләшмәде, бәйләнмәде. Төнгә калып кайткан чаклар да була. Концертка, бәйрәмнәр, кичәләр үткәрергә дип тә чакыра килләр. «Минә – хатын, менә – баян. Баянга ни булса да сүзем юк, хатынымны гына исән-сау китереп куярсыз», – дип утыртып җибәрә иде.

Вожатый булып эшләве дә – балаларны яратудан.





Фото: Җәмилә Сабирова-Сибгатуллина архивыннан

Ә балаларыбызны бөтен мәктәп, бөтен урам, авылдашлар карады. Декрет ялларына чыкмый гына таптым аларны. Җәйге лагерьда эшләгәндә Шушманы аркылыга-буйга йөзеп, икенче көнне Шамилебезне алып кайттым. Су кереп кайткач, фельдшер Нурания апага күренергә барган идем, карыйсы калмаган инде, утыр тизрәк, дип, Балтачка алып та китте. 1979 елның 1 гыйнварында Зөбәрҗәтебез туды. Анысы да кызык кына булды. Декабрь ахырында ук бәби көтүчеләр янына салмакчылар иде. Риза булмадым. «Яткырырсың инде Җәмиләне!» – ди икән врач үзе дә. 31 декабрьдә авырлы килеш клубка бал-маскарадка барып утырдым. Харис абый: «Әйдә, уртага чык. Синнән башка булмый», – дип, мине тәки Яңа ел кичәсен алып барырга чыгартты. Халык таралышканчы, төнге уникегәчә җырлап-биеп Яңа ел каршыладык. Ә иртәнге өчтә кызымны таптым. Беркем ышанмаган. Шәһидулла парторгка машина сорап баргач, «Әле яңа гына клубтан бергә кайттык бит», – дип тора ди. Хәзер оныклар үсә инде: Наилә, Булат, Камилә. Зөбәрҗәт Фатихов Равилләргә кияүгә чыкты, Фатихова Равиләләрдән Шамилгә кыз алдык. Улыбыз – әтисе юлын, кызыбыз минекен сайлады.

Комсомол җырлары

Мин хәзер юбилейлар, туйлар алып барам. Балтачка, Кукмарага, Арчага чакыралар. Казанга да барганым бар. Беләсезме, пионер, комсомол җырларын да җырлыйбыз табын артында. Җәй көне Гүзәлнең 60 яшен бәйрәм иткән идек. Әйдәгез, «Взвейтесь кострами!»ны җырлыйк диюем булды, дәррәү күтәреп алдылар! «Балкый учакның төнге нурлары» дип, татарчалап әле... Галстуклы елларым күз алдымнан йөгереп узды. Берчак комсомолның Татарстан өлкә комитетыннан «Орлёнок» Бөтенроссия лагерена вожатыйлар укуына җибәргәннәр иде. Кара диңгез, таулар, илнең төрле почмакларыннан җыелган ал галстуклы егетләр-кызлар... Бергә кич утырганда нинди генә җырлар җырламыйбыз. Мин баян белән дә булгач, бөтенесе яныма җыела. «Любовь, комсомол и весна», «Орлята учатся летать», «Не расстанусь с комсомолом»... Без, Татарстан кызлары, татарча да җырлыйбыз...

Минем дөньям

Кыш көне фонарь яктысында бөтерелеп яуган карларны, бураннарны яратам. Ә көзнең үз яме. Алтын-сары яфраклардан чыштыр-чыштыр узулары үзе ни тора. Таудан мәктәпкә менгәндә, туктап, авылыма карап торам. Бигрәк матур инде! Төзек йортлар, урамнар, бакчалар күзне иркәли. Талларга ышыкланып кына Шушма ага. Юл читендә үскән әремнәргә кадәр якын шул миңа. Китап, китапханә – минем дөньям. Көненә бер мәртәбә клуб белән китапханәгә кагылмасам, узып барышлый булса да спортзалга кереп чыкмасам, Җәмилә буламмы инде! Спектакльләрдә уйныйбыз. Анысы инде туганнан бирле. Район күләмендә конкурста «Иң өлкән хатын-кыз башкаручы» исемен алдым. Миңа шаянрак рольләр эләгә гадәттә. Ә театрга Казанга ук йөрибез. Бер репертуарны да калдырган юк. Мине авылдашлар «Ак апа», «Ак әби» дип йөртәләр икән. Сабыр булганга, гайбәтләрне ишетмәгәнгә, берәү белән дә сүзгә килмәгәнгәдер, бәлки? Булыр әле, дип яшим. Чәбәләнмим, каударланмыйм. Башкаларны да җайларга тырышам. Нәрсәгә тотынсам да: «Була ул, борчылмагыз», – дим.

* * *

Менә шундый ул Җәмилә. Гапгади җир кызы. Хыяллары, ашкынулы җаны исә күкләргә оча, камиллеккә омтыла, һәрнәрсәдән матурлык эзли. Балтачның бизәге ул.

ҖЫЕЛЫШКА ЙӨРҮ КЕМ ЭШЕ?

Ике бала укытып (берсе инде мәктәпне тәмамлады), иремнең бер тапкыр да ата-аналар җыелышында катнашканы юк. Күп гаиләләрдә әтиләр балаларының укуы-тәрбиясе белән кызыксынмый, ахрысы. Җыелышларда күбесенчә әниләрнең генә катнашуыннан чыгып әйтәм моны. Әтиләрне бала тәрбиясенә ничек җәлеп итәсе икән ул?

Ләйсәрия Н.
Казан шәһәре.

Алсу Исмәгыйлева, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе шеф-редакторы, ике бала әнисе.

Ир-ат баласын карарга атлыгып тормый икән, җәнҗал чыгарып кына, проблема хәл ителмәячәк. Бу очракта хатын-кыз тәмле теле, хәйләкәрлеге белән әти кешене баласына якынайтырга тиеш. Әлбәттә, бу бер-ике көндә генә мөмкин эш түгел.

Ир кеше нәрсәгә тартыла? Рәхәт атмосферага. Дискомфорттан курка алар. Мөгаен, баласын карашуны да үтә дә авыр, җаваплы эш дип күзаллыйдыр. Кайвакыт ситуацияне хатын-кыз үзе дә катлауландырып җибәрә: «оекбашның зәңгәрен түгел, кызылын кидерәсе иде; башлыкның колакларны каплый торганын кидермәгәнсең». Болай шелтә белдереп, ул ирен тәмам куркытып бетерә. Әти кешедә «мин бала карый белмим», дигән стереотип барлыкка килә, һәм ул бу вазыйфадан кача башлый. Бала үстерүнең кызыклы һәм мавыктыргыч икәнен күрсәтегез аңа. Әни кеше баланың уңышлары, шөгыльләре, әкәмәт сүзләре турында сөйләп торса, әти кеше дә кызыгып куяр.

Баланың үзен дә әтисенә якынайту өчен тырышырга кирәк: «Улым, әтиең тәмле карбыз алып кайткан, бар, кочаклап ал әле». Яки: «Әтиеңне эшендә мактаганнар, кулын кысып кил!» Иң мөһиме – проблеманы бары тик позитив атмосферада гына хәл итеп була. Әлбәттә, әтисе баланы ярата, үзе генә аңлап бетерми. Ирләргә үз-үзләрен аңларга ярдәм итү – акыллы хатын-кызның бурычы ул.

Булат Бәйрәмов, шоумен, өч бала әтисе:

Тормышта нинди генә очрак булмасын, башта сәбәбен аңларга тырышырга кирәк: ни өчен болай? Ни өчен әти бала тәрбиясендә аз катнаша? Бәлки, ул иртән чыгып китеп, кич кенә кайтучыдыр. Гаиләсен тәэмин итеп, кайгыртып торадыр, ләкин җыелышка йөрергә аның вакыты да, көче дә юктыр. Кайчак хатын-кызлар эштән арып кайткан ир-атны: «Бала минеке генәме әллә, карашмыйсың, кызыксынмыйсың», – дип битәрләргә ярата, аның гаиләсе өчен куйган тырышлыгын «оныта».

Әти кеше баланың тәрбиясе белән кызыксынырга тиеш, билгеле. Җыелышлар гел булмый. Шуларның берсенә генә булса да вакыт табарга мөмкин. Инде үзе бара алмаса, хатыныннан сорашып, барыбер дә баласының ничек укуыннан хәбәрдар булырга кирәк. Кайчак әни кеше үз баласын артык кайгырткангамы, әти кешегә ышанмагангамы – баштарак җыелышларга үзе генә йөри. Соңыннан ирен дә җәлеп итәсе килә, әмма анысы инде рәхәткә чыккан була.

Безнең гаиләдә ике укучы бала үсә. Вакытым булса, беркайчан да баш тартмыйм, җыелышларга бик рәхәтләнеп барам, сорауларым булса, бирәм. Кайчак икесенең дә класс җыелышларын бер үк вакытка куялар. Андый очракта мин – бер кызыбызныкына, әниләре (җырчы Ләйсән Гыймаева – *ред.*) икенче кызыбызныкына керә. Ата-аналар җыелышына йөрүне әти кешенең дә бурычы дип саныйм.

Өч фикер



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Әти кешене бала тәрбиясенә ничек җәлеп итәргә дигән сорау күп гаиләләр өчен актуаль. Гомер-гомергә шулай килгән инде – ирләр макросоциумда, хатын-кызлар микросоциумда күбрәккә ирешкән. Әмма бу әти кеше баласының тәрбиясе, укуы белән кызыксынмаса да була дигәнне аңлатмый.

Бу очракта мин әтисе белән бергәләп баланың шәҗәрәсен – нәсел агачын төзергә тәкъдим итәм. Ир кешегә үзен шушы чылбырның бер буыны, ә баласын үз тармагының дәвамы итеп күрү аңа баласының үзенә никадәр якын торуын аңларга ярдәм итә.

Ир кеше булмышы белән табучы, булдыручы. Ә хатын-кыз аңа эштән соң ял итү, уйларын тәртипкә китерү өчен уңай мохит тудыручы. Әни кешенең вазыйфасы – әти белән бала арасын якынайту, әтиләрен бала тәрбиясенә җәлеп итү. Аңа үзенең әтилек сыйфатларын тормышта сынау шартларын фәкать хатын-кыз гына тудыра ала. Ир кеше эштә – хезмәткәр, үз әти-әнисенә – бала, иптәшләре арасында – дус, ул фәкать баласы янында гына әти ролен башкара ала.

Гаиләдә әти эксперт ролен үти. Ул бала белән уйнамаска, аңа дәресләрен дә әзерләшмәскә мөмкин. Ләкин ул эшнең нәтиҗәсен тикшереп, баланың эшенә бәя бирүче, ниндидер мәсьәләне чишүдә аңа юл күрсәтүче, макросоциумда аңа үзен ничек тотарга кирәген өйрәтүче. Ул балага төрле ситуацияләрдән чыгу күнекмәләрен бирә, әти кешенең роле әнә шуның белән әһәмиятле.

Хатын-кызның тагын бер мөһим вазыйфасы – балаларга әтиләренең уңай якларын күрсәтү. Әгәр дә әтисе бүген балага игътибарны җитәрлек бирмәгән, аның белән уйнамаган яки кызыксынмаган икән: «Ул сине кирәксенми, син бер миңа гына кирәк», – дию – зур хата. Бу хатасы өчен соңыннан әни кеше үзе үк түләячәк. Киресенчә: «Әтиең арган, аның бүген бик авыр көне булган», – дип, әтинең абруен күтәрү бала өчен дә файдага гына. Хатын-кыз иренең уңышларын күреп, аның өчен горурлануын иренә һәм балаларына да әйтеп торса, ул тагын да зуррак үрләр яуларга илһамлана. Ләкин кем өчен тырышканын гына онытмасын.

«ӘЛЕККЕГЕЛӘР ДӨРЕС ЯШӘГӘН...»

«МИН БЕЛГӘННӘР АРАСЫНДА ИҢ ТАЛАНТЛЫ ДОКТОР ИДЕ УЛ.

Андыйлар бүгенге клиникаларда сирәк очрый. Табибның минем авыруымны төпченеп өйрәнүе истә калды. Беренче тапкыр аралашканда ук тынычланып киттем, табиб аңлаешлы телдә сөйләште. Артык дарулар алырга, кирәкмәгән анализлар бирергә кушмады. Пациентларына ихтирам белән карый торган табиблар күбрәк булсын иде. Аңа беренче тапкыр күренгәннән соң ук хәлем күпкә яхшырды. Әлеге белгечнең кулына эләгүем бәхетем булды...»

Ландыш ӘБҮДӘРОВА



Республика клиник хастаханәсенең гинекология бүлеге җитәкчесе, югары категорияле табиб, акушер-гинеколог Наилә Иршат кызы ТӨХВӘТШИНА дәвалаган ханымнарның берсе интернет челтәрендә калдырган сүзләр бу. Андыйлар бихисап. Авыруы турында район табибы язып биргән кәгазьне күкрәгенә кысып, Республика клиник хастаханәсенең капкасы аша узганда, хатын-кыз билгесезлек чиген дә атлый. Моннан соң аның язмышы – табиблар кулында. «Ходаем, яхшысы очрасын иде», дип тели ул, чөнки хатын-кыз сәламәтлеге – гаиләле булу, әни булу бәхетенең гаранты икәнен бик яхшы аңлый. Тик менә авырып китте... «Ходаем, яхшы табиб кына...»

Республика дәваханәсенең якты коридорларыннан Наилә Иршат кызының үтеп киткәне сизелми дә кала: ул шундый җиңел һәм тавышсыз итеп атлый, әйтерсең лә шушында дүртенче дистә елын тутырып эшләүче табиб түгел, ә рәхәтлек бирә торган җиләс һава ургылып керә. Була бит шундый кешеләр: алар гүя бу заманныкы түгел. Гомумән, бер заманныкы да түгел. Алар турында күп тә сөйләп булмый, тоярга гына кирәк. Тоемлауга сораулар артык булып кала. Алар җиңел яши, җиңел эшли, барысын да белә кебек. Наилә Иршат кызы үзе турында ике-өч җөмлә белән әйтеп бирүгә, җыенысы бер учка җыелды да бетте.

– Әлмәттә тудым, мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. Казанда медицина институтына укырга кердем, кияүгә чыктым, бала үстердем. Алты ел элек тол калдым. 1980 елдан Республика клиник хастаханәсендә эшлим. Барысы да шулай гап-гади...

Болар янына Наилә Иршат кызының гаиләләрендә бердәнбер табиб икәнен, апасы белән сеңлесенең икътисад өлкәсендә эшләвен өстәргә була.

– Гомумән, мин бәхетле кеше, чөнки яраткан эшем белән шөгыльләнәм, табиб ул – кешеләргә бәхет бирүче кеше. Эшеңнең нәтиҗәсе шунда ук күренә, авыруның терелүен күрүдән дә рәхәт хис юк. Дәвалангannan соң, шалтыратып: «Безнең бәбиебез була!» – дип шатлык уртаклашсалар, табиб кеше өчен тагын ни кирәк?

Акушер-гинеколог, ягъни үзебезчә әйтсәк, хатын-кызлар табибы белән авырулар турында сөйләшергә килешкән идек, әңгәмәбез хатын-кыз бәхете, шуның белән кыз балалар тәрбиясенә күчеп китте. Дүрт дистә елга якын бер урында эшләгән табибның һәр сүзе олы тәҗрибә белән җөпләнгән.

Наилә Иршатовна, хатын-кызларда аналык төшү дигән киң таралган бер авыру бар. Моның сәбәпләре нидә?

– Аналык төшү дигәндә, аның русчага ике төрле тәрҗемә ителүен ачыклау урынлы булыр. Төшү – «опущение» һәм «выпадение» мәгънәсендә. Беренче мәгънәсе турында сөйләгәндә, аның килеп чыгу сәбәпләре (этиологиясе) берничә: бәби тапканнан соң килеп чыккан катлаулыклар; икенчесе – җенси гормоннар синтезында үзгәрешләр барлыкка килү, ягъни менопауза чорына керү; өченчесе – корсак басымы күтәрелүгә китерә торган авырулар, мәсәлән, бронхит, бронхиаль астма белән бәйле. Дүртенчесе – тумыштан тоташтыргыч тукымалар дисплазиясе булган хатын-кызлар категориясе бар.

Икенче төрле аналык төшү (выпадение), гадәттә, менопауза вакытында авыр күтәрергә туры килгәндә барлыкка килә. Еш кына шулай килеп чыга: хатын-кызга авыру ирен яки карт әти-әнисен карарга, аларны күтәрергә кирәк була. Менопауза вакытында җенси гормоннар синтезы акрын бара, тоташтыргыч тукымалар йомшара.

Аналык төшүне булдырмас өчен нинди профилактика чаралары бар?

– Бу очракта оча төбе мускулларын ныгыту күздә тотыла. Йөзү, йөгерү, бию, аеруча шәрык биюләре. Кегель буенча гимнастика, цигун, шул исәптән йога – болар барысы да оча төбе мускулларын ныгыта.

Тумыштан тоташтыргыч тукымалар дисплазиясе булган хатын-кызлар иң элек нишләргә тиеш? Диагноз куелгач кына соң булуы ихтимал бит.

– Иң элек тоташтыргыч тукымалар дисплазиясенең билгеләренә игътибар итәргә кирәк: астеник гәүдә төзелеше, мускуллар гипотониясе, яссытабанлылык, вегетатив-кан тамырлары дистониясе, мәсәлән. Мондый билгеләр булганда, кыз бала үзен кайгыртырга, биш килограммнан артык авырлык күтәрергә ярамаганлыгын белергә тиеш.

Әбиләребез белән чагыштырганда, безнең буын физик эш белән артык «ватылмый» да кебек. Ләкин без үзебезне, алар белән чагыштырганда, сәламәт дип әйтә алмыйбыз. Бу нилектән шулай?

– Сәламәтлекләрен саклау өчен башка төр чыганаклар җитәрлек булган ул заманнарда. Мәсәлән, алар көн саен, хәтта, сәгать саен бездәге кебек стресслар кичермәгән. Куркулардан азат булган. Аннан соң без компьютер, телевизор һәм смартфоннарыбызга текәлеп утырып, бик күп энергиябезне югалтабыз. Кеше энергиясенең 60 процентын күзләре аша сарыф итә.

Без эштән кайтуга телевизорны кабызабыз да калган вакытны хәрәкәтләнмичә диярлек үткәрәбез. Сау-сәламәт булыйм дисәң, көнгә дүрт-биш сәгать хәрәкәтләнергә кирәк. Спорт белән генә шөгыльләнергә димәгән. Саф һавада йөрү, бию, сулыш алу

Фото: Ксения Богданова

PRESSA



■ Хатын-кыз авыруларына килгәндә, әбиләребез заманындагы тәрбия зур роль уйнаган. Гыйффәтле булып кияүгә чыгып, бер генә ир-ат белән яшәп, аннан гына бала тапкач, ялкынсынулар бөтенләй булмаган диярлек. Ә бу бик зур әһәмияткә ия.

күнекмәләре, мәсәлән. Әбиләребез күп вакытларын саф һавада эшләп үткәргән. Эш һәрвакытта да авыр күтәрү белән бәйле булмаган бит. Алар саф һава сулаган, чиста су эчкән. Үзләре үстергән чиста ризык ашаган. Безнең рациондагы иң популяр тавык итен генә алыйк: аның әбиләр ашаганы яшел үлән чемченеп үскән. Бер пациентка операция ясап, миомасын алгач, кайтып киткәндә ул, ниһаять, «серен чиште»: соңгы вакытта гел «чипсы»лар ашаган икән. ГМО ризыклардан баш тартырга кирәк. Дөресрәге, үзең үстергәнне, әзерләгәнне генә ашарга тырышырга кирәк.

Билгеле булганча, бик күп авырулар «яшәрә». Хатын-кызларныкы да...

– Яшәрә, чөнки яшәү рәвеше үзгәрде. Шешләр турында гына сөйлибез икән, аларның барлыкка килүенең төп сәбәпләре: эчке органнардагы ялкынсынулар, абортлар, стресслар, иммунитет төшү, бик иртә җенси тормыш белән яши башлау, партнерларны еш алыштыру. Мин эшли башлаганда, миома һәм башка шешләр белән 40 яшьне узган, 50 гә җитүче хатын-кызлар килә иде. Хәзер – 30 яшьтән башлап, хәтта иртәрәк тә. Операция ясап, шешне алабыз. Соң чиккәчә аналыкны калдырырга тырышабыз, билгеле. Безнең хастаханәдә аналыкның кан тамырларын эмболизацияләү кебек консерватив ысул да бар әле. Бала табарга теләүче хатын-кызларга шуны кулланабыз.

Яман шеш куркынычы булса, Көнбатышта күкрәкләрне, аналыкны алдыру күзәтелә.

Мәгълүмат

Аналык төшү – еш очрый торган патология

■ 30 яшькә кадәрге хатыннарның – 10 процентына;
■ 30–40 яшьлекләрнең – 40 процентына;
■ 50 яшьтән узганнарның күбесенә шундый диагноз куела.
■ Җенси органнарга ясалган операцияләрнең 15 проценты аналык төшү белән бәйле.

Мәсәлән, Голливуд йолдызы Анджелина Джоли, башкаларга да үрнәк булсын дип, профилактик максатларда күкрәген алдыруы турында игълан итте. Спортчы хатын-кызлар исә бу турыда алдан ук кайгырта, диләр.

– Әйе, Көнбатышта мондый тәҗрибә бар. Әмма минем практикада бер генә органны да профилактик максатларда алырга туры килмәде. Безнең төбәктә мондый хәлнең булганы юк дип әйтә алам. Бу адымга бару өчен билгеле бер сәбәпләр булырга тиеш.

Сез акушер-гинеколог, шул ук вакытта хирург та.

– Хирург булып эшләү өчен, табиб үзенең физик халәтенә зур игътибар бирергә бурычлы. Операциягә кергәндә минем үземнең хәлем әйбәт булырга тиеш. Арыганлык операциянең уңышына да йогынты ясый. Кайчак уникешәр сәгать эшләргә туры килә. Шуңа да мин, кагыйдә буларак, спорт залына йөрим.

Олы яштәге пациентларыма да һәрвакыт үзләренең физик формаларына игътибар итәргә киңәш бирәм. Ким дигәндә, Стрельникова буенча гимнастика ясарга була. Ул бернәрсә дә таләп итми: бары тик тәрәзәне ачарга яки балконга чыгып басарга да суларга гына кирәк. Энергетиканы күтәрүнең менә дигән ысулы. Кешенең энергетикасы өч өлештән тора: сулыш, хәрәкәт һәм өченчесе – ашау.

Хәзер йога да киң таралды.

– Әйе, йога менопаузадагы хатын-кызлар өчен дә бик файдалы: буыннар хәрәкәте сизелерлек активлаша. Йога ул физик хәрәкәтләр генә түгел, аң хәрәкәте дә әле. Бездә аның физик өлешенә күбрәк игътибар бирәләр. Адәм баласы эш белән мәшгуль икән, ул кояшны сәламләү комплексын гына да үти ала. Сәламәтлек өчен монысы да бик файдалы.

Хатын-кызларның сәламәтлеген кайгыртучы буларак, нинди киңәшләр бирер идегез?

– Бәлки, бик искечә фикер әйтермен, ләкин кыз бала үзенең сафлыгын сакларга тиеш. Шул чагында гына аны бик күп проблемалар урап узачак. Мәктәптә, югары уку йортында ул уку белән генә мәшгуль булачак. Ялкынсынулар эләктермәячәк.

Кызларга тәмәке тартмаска киңәш итәр идем. Ул тышкы кыяфәттә чагыла: тән тиресе ямьсезләнә. Тәмәке тарту күкәйлекләргә начар йогынты ясый, ә бу киләчәктә язмышка тәэсир итә, чөнки тәмәке тарткан хатын-кызның менопаузасы биш-алты елга иртәрәк башлана.

Алкоголь куллануга карата да әйтер сүзем бар. Спиртлы эчемлекләр бавырны, ашказаны асты бизен токсиннар белән агулый. Сәламәт булыйм дисәң, тормышыңа физик культура кертергә кирәк.
Без үскәндә спорт клублары юк иде, гимнастика, физкультура белән шөгыльләндек. Ә хәзер мөмкинлекләр күбрәк. Иң мөһиме: сәламәтлекне дә намус кебек яшьтән сакларга кирәк. Әти-әниләрне тыңларга кирәк. Милләт сәламәт булырга тиеш.

ИЯРТЕП КИЛГӘН БАЛА



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Хатынының ияртеп килгән баласы каршында ир кешенең бурычлары бармы?

– Сүзне шуннан башлыйк: хатын-кыз бала ияртеп килергә тиеш түгел. Ул кабат кияүгә чыгарга теләсә, беренче никахыннан туган баланы, әтисе булса, ата кешегә бирәләр. Ни өченме? Гаиләдә хуҗа булып ир-ат санала, һәм матди чыгымнар белән бәйле барлык мәсьәләләрне ул хәл итә. Ә бала үзенеке булмагач, үги ата аңа карата үзен кырыс та тотарга мөмкин. «Нишләп әле мин кеше баласына акча чыгарыйм?» – дип, кирәк булганда да акча бирмәве мөмкин. Гомумән, башыннан артык сыйпап тормый инде ул аның... Менә шуңа күрә дә хатын-кыз икенче тапкыр кияүгә чыгарга ниятләсә, шәригать буенча, балаларны әти кешегә бирәләр. Үз әтиләре аларны үги әнидән (ирнең дә яңа хатыны булырга мөмкин), аның кыерсытуыннан саклый алачак. Балаларга ямьсез каравын күрсә, аны куып та чыгарырга хәленнән килә. Ә хатын, үги әтиләре сабыйларын кыерсытуны күргән, белгән очракта да кайчак берни эшли алмаска мөмкин.

Ә нинди очракта балаларны ияртеп килә ала соң ул? Әйтик, ире үлеп, тол калса. Хәтта бу очракта да хатын-кыз кабат кияүгә чыгарга теләгәндә, шәригать буенча, аның балаларын мәрхүм иренең якын туганнарына – абыйсына, энесенә, әтисенә тапшыралар. Алар алудан баш тартса, хатын-кызга баласын ияртеп килүдән башка чара калмый.

Һәм бу очракта ул шуны аңласын: яңа ирнең аның баласы каршында бернинди бурычы юк. «Улыма (кызыма) шушы әйбер кирәк, алыйк әле», – дип сорый, таләп итә башласа, белеп торсын – кайчан да булса ирнең бу ачуын чыгарачак. Хатын-кызга, гомумән, «яңа ирем минем балаларга нидер тиеш», дип уйларга ярамый. Әгәр икенче ире аның баласын кабул иткән, йортында бер бүлмә биргән, өс-башларын карап тора, укыта, каядыр ялга да алып бара икән, хатын-кыз аңа бик рәхмәтле булырга тиеш. Кызганыч, хәзерге хатын-кызлар алай уйламый. «Ул бит мине бала белән алды, аның барын белде, карасын», – диләр. Ә бит, алдарак әйткәнемчә, ир-ат боларның барысын тиеш булмаган килеш эшли! Хатын-кызның үзен болай тотуы бернинди кысаларга да сыймый. Чынлыкта, мондый хатын үз-үзенә дошман ул.

Тагын бер нәрсәне онытмыйк: ир кеше бервакытта да чит кеше баласын кабул итмәячәк. Тышкы яктан мөнәсәбәте әйбәт булса, сиздермәсә дә, йөрәге белән ул аны беркайчан да үзенеке итеп тоймаячак, якын итмәячәк. Шуңа күрә, кияүгә чыгу белән, хатын-кыз ул ирдән бала табарга тырышырга тиеш. «Безнең балабыз бар бит инде», – дип, үзенекенә күрсәтергә ярамый. Синең балаң аның нәселен дәвам итми. Хәер, әгәр ирне үзенә якынайтасы килсә, хатын-кыз уртак баладан баш тартмаячак.

Үзенеке булмаганга күрә, үги балага ир кешенең җүнле тәрбия бирә алмау ихтималы да бар. Күңелендә бу балага карата йомшаклык булмагач, артык кырыслык белән кайчак ул аны сындыра ала. Яки киресенчә: «Мин аның үз әтисе түгел, күңелен кайтармыйм», – дип ачуланырга кирәк булганда да тыелып калырга, аны артык иркәләп ташларга – чаманы югалтырга мөмкин. Әйе, күп чакта үги баласы белән ул үзен ничек тотарга белми. Хатын-кыз бала белән килгән һәм яңа ире аны кабул итүен тели икән, баланы тәрбияләргә комачауларга тиеш түгел. Ә ир кешенең, гаиләдә тәртип булсын өчен, тәрбия дилбегәсен үз кулына алырга хакы бар.

Үги баласына ир кеше үз фамилиясен бирә алмый – ислам динендә мондый тәртип юк. Бала үз әтисе фамилиясендә йөрергә; әтисе баланы күрергә, үзенә алырга теләсә, әнисе дә, аның яңа ире дә бернинди каршылык күрсәтергә тиеш түгелләр. Әмма баланың әтисе алар йортына килеп йөрми, очрашырга теләсә, алып китә.

Шәригать буенча, хатынның ияртеп килгән баласы вафат булган үги атасының мирасына керә, аның малына хуҗа була алмый. Хәтта бик кечкенәдән аның гаиләсендә тәрбияләнсә дә.

Шундый четерекле хәлне күз алдына китерик. Хатын-кыз кияүгә бала белән килде ди. Ияртеп килгән бу кыз бала үскәч, буй җиткәч, матурайгач, үги атаның аңа күзе төшсә?

– Хатынын аерып, ир кеше үги кызын кияүгә ала аламы дип сорарга телисез инде. Әйе, андый теләк туган очракта, бу – мөмкин хәл. Шәригатьтә шундый кызык әйбер бар. Хатыны белән җенси мөнәсәбәткә кермәгән булса, ир кеше хатынын аерып җибәреп, үги кызы белән никахлаша ала. (Тормышта төрле хәлләр очрарга мөмкин. Ир, әйтик, бергә яшәр өчен генә карт хатын алса яки авыру аркасында ике арада җенси мөнәсәбәт булмаса.) Әгәр инде кызның әнисе белән җенси мөнәсәбәткә керергә өлгерсә, ир кеше бу кызны үзенә хатынлыкка ала алмый. Ул кыз ир алдында яулыксыз да йөрергә мөмкин, әмма кияүгә чыга алмый. Хәтта ир аны үз кызы кебек кабул итмәсә дә.

Бу бала ярты ятим бит инде. Аны кыерсыткан өчен Ходай каршында җавап бирергә туры киләчәкме?

– Ислам динендә «ярты ятим» дигән сүз юк: әтисе үлсә генә бала ятим санала. Пәйгамбәребез әйтә: «Кем ятим баланы алып үстерсә, шуның белән без, ике бармак арасы ничек якын булса, җәннәттә шулай якын булырбыз», ди. Ятим баланың башыннан гына сыйпасаң да, аның башында ничә чәч бөртеге бар, шулкадәр савап языла. Әгәр инде кемдер кыерсытып, ятим бала еласа, бу вакытта Аллаһы Тәгаләнең тәхете калтырый ди: ул аны үз яклавы, үз канаты астына ала. Ятим балага гаделсез булсаң, Аллаһы Тәгаләгә карата начарлык кылган буласың.



ГРИМЕР

Рәмзия
КАШАПОВА

Атаклы режиссер Константин Станиславскийның «Театр кием элгеченнән башлана» дигән мәгълүм гыйбарәсе күпләргә таныш инде. Ә менә театрда, актерлар һәм режиссердан кала, тагын кемнәр эшли соң? Сәхнә артында көн саен кем хезмәт куя? Артистларны сәхнәгә чыгарга кем әзерли, образларны кем тудыра, кем киендерә?

Җиңелчә генә тоныклатып күрсәтә торган серле яктылык, көчле лампалар белән яктыртылган зур көзгеләр, агач болванкадагы парик, сакал-мыеклар, исәпсез күп пумалалар, төрле төстәге буяулар – театр гримеркалары барысы да бертөрле буладыр инде. Шулай да аларның һәркайсы, театрның үзе кебек үк, үзенчәлекле. Мәсәлән, гример цехлары бер-берсеннән нәрсәсе белән аерылып торганны шунда эшләүчеләр үзләре генә beләдер.

Театр гримеры – бер сәгать эчендә сезнең кыяфәтегезне танымаслык итеп үзгәртә алучы универсал кеше ул. Иҗади фикере, төрле вак детальләрне күрә белүе һәм, әлбәттә, креативлыгы белән әллә каян аерылып тора ул.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының грим патшабикәсе Сания Гыйлемхан кызы Мавровская – Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, грим салучы рәссам. Сонечка (театр артистлары аны үз итеп шулай дип йөртә) беренче очрашуда ук соклану уятты. Мода буенча киенгән зәвыклы ханым үзенә дә оста итеп грим салган. 45 ел шушы эштә эшләп, театрның алыштыргысыз гримерына әйләнгән Сания ханым күпкә яшьрәк күренә.

– Эшемне бик яратам, – ди ул. – Театр әһелләре белән бер казанда кайнау, шуларның кадерле бер кешесе булу бик ошый миңа. Гаҗәеп сәхнәсе булган, штатта күп хезмәткәрләр торткан опера һәм балет театрында бик күп һөнәр ияләре эшли. Театр аларга бер-берсенә терәк һәм таяныч була алу мөмкинлеге дә ача.

Гример һөнәренә укытканда күп нәрсәләргә өйрәтәләр. Әйтик, театр һәм кино өчен грим салырга, бөтенләй башка чорны чагылдырган прическалар ясау серләренә төшенергә, костюмнар тарихын белергә, сынлы сәнгать, скульптура буенча мәгълүматлы булырга...

Мин салган гримнар әйбәт килеп чыга иде, ә менә чәч ясау катлаулырак тоелды. Сынлы сәнгатьне дә яраттым, институтта шундый предмет бар иде.

Озак еллар эшләү дәверендә шушы профессиягә генә хас гадәтләр барлыкка килде: бертуктаусыз кешеләрне күзәтәм, йөз-кыяфәтләренә, сакал формаларына һәм төсенә, җыерчыкларга, башкалар күзе төшми торган шуның ише башка бик күп вак-төяккә игътибар итәм.

Гример хезмәте ул көн саен эш барышында ниндидер яңа әйберләргә өйрәнү, һәрчак комфорт зонасыннан чыгу.

Күпчелек гримерлар өчен иң катлаулы баскыч – пластик грим. Грим салучы рәссамны алыгыз – чын мәгънәсендә профессионал бит ул. Югарыда саналган барлык һөнәрләрне үзләштергән: визажист та, макияж да сала, стилист та, портрет, характер, фантазия, пластик, күләмле-скульптур һәм бүген «спецэффектлы» дип аталган махсус гримнар ярдәмендә йөзне дә үзгәртә ала. Аның эш диапазоны киңкырлы: париклар да ясый белә, чәчтараш сәнгате белән дә таныш, прическалар тарихы белеме дә бар үзендә. Әлеге катлаулы һәм үтә нечкә технологияләрдә гаҗәеп бер төгәллек белән бар нюанслар сакланган. Рәссам грим буенча аерым бер образны тудырып кына калмый, иҗат төркеме белән тыгыз элемтәдә торып, билгеле бер характерга туры килерлек йөзне трансформалый. Профессиональ яктан да үсеш бу, белемнәреңне баету да. Мәсәлән, бүген куела торган спектакльләрнең беренче чыганакларын – пьесаларны белергә, яхшы фильмнар карарга, театрларга йөрергә, әдәбият, рәсем сәнгате белән кызыксынырга кирәк.

Гример, гомуми рәвештә генә булса да, тарихны, судмедэкспертизаны, медицина нигезләрен өйрәнергә, чәч кисә, прическа ясый, визаж, грим, пластик грим сала һәм махсус эффектлар куллана белергә тиеш.

Опера һәм балет театры гримы белән драма театры гримы бер-берсеннән шактый аерыла. Балет гримы күзгә ташланып торган төсләре белән үк бөтенләй башка! Күз һәм кашларга күбрәк игътибар бирелә: җете төстәге теньнар, ясалма керфекләр, үз кашыңнан өстәрәк сызылган кашлар. Балеттагы кызлар гримны үзләре сала. Егетләр дә булдыра ала бу эшне. Чөнки училищеда махсус грим дәресләре алганнар. Күпләргә ошый ул. Алай да, гадәттә, егетләргә гримны профессионаллар сала. Операда ирләр гримы сирәк кулланыла. Сакал, париклар турында сүз барса гына инде. Хатын-кызларның да күбрәк чәчләрен ясыйлар, парик кидерәләр.



■ Сания Мавровская: – Күптән пенсиядә булсам да, тормышымны театрдан, сәхнә артыннан, грим бүлмәсеннән башка күз алдына да китерә алмыйм.

Баштарак гримерлар аларга макияж ясарга булышса, тора-бара үзләре генә дә ясый башлый. Институтта опера һәм балет өчен кырыс грим кануннарына өйрәтсәләр дә, чынлыкта, ул кагыйдәләр бик үтәлми дә. Гәрчә опера-балеттагы грим күзгә ташланырлык, образларның һәр детале җентекләп эшләнгән булса да. Биткә пластик грим ясалмаса да (әйтик, борын беркетелмәсә), барыбер (хәтта ирләрнең дә!) күзләрен «зурайталар» йә «тарайталар», иреннәрне, тән төсен үзгәртәләр. Миңа сәхнәдә классик грим ошый. Соңгы вакытта театрларда натуральлеккә күчү күзәтелә. Монысы кәефне төшерә. Институтларда укытылган һәм һичшиксез булырга тиешле классик грим кирәксезгә әйләнә. Ләкин ул барыбер дә тәмам юкка чыкмас дип өметләнәм. Безнең театрга бу шаукым кагылмады әле. Мин күбрәк ир-атлар белән эшлим, алар грим салырга хатын-кызларга караганда сирәгрәк мөрәҗәгать итсә дә, сакал-мыеклар, париклар, төрле гримнар гел кирәк була. Аеруча әкиятләрдә «кычкырып торган» гримнар салына.

«Сөембикә» операсы турында да берничә сүз әйтәсем килә. Премьерага әзерлек елдан артык барды инде. Иван Грозный, Сөембикә ханбикә образларын тудыру, эскизлар ясау бик катлаулы булды. Аеруча Сөембикә образы буенча сораулар күп иде. Чөнки ханбикәнең ниндирәк кыяфәттә булуын беркем белми, ул хакта мәгълүматлар да бик аз. Рәссам үз эскизларын ясады. Аның буенча гримерлар, костюм әзерләүчеләр, театрның тегү цехы эшләде. Бүгенге яшь рәссамнар күзаллавы аша эшләр яңа юнәлештә үсеш алды.

...Театрда очраклы кешеләр була алмый. Гадәттә, монда гомерлеккә дип киләләр. Ихтыярсыз, актер Андрей Миронов сүзләре искә төшә: «Театрдан беркайчан да китмәячәкмен, мин аннан башка яши алмыйм...»

БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ

■ Грим сүзе борынгы грек сүзе «гримо» – җыерчыктан алынган. Европа реалистик гримының чишмә башы антик мифология театрына барып тоташа. Биттәге җыерчыклар күңелнең төрле халәтләрен чагылдыра. Софокл, Аристофан, Еврипид кебек бөек драматурглар да битлекләрдән файдаланган.

Фото: автор



Фото: Татьяна Франк

ҖАНГА АЧКЫЧ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– «Инде ике атна буе бер ханым көн дә күргәзмәгезгә йөри. Шушы картинагыз каршына килә дә елап тик басып тора», – диделәр. Соңрак ул мине үзе эзләп тапты. «Начар чир дигән диагноз куйганнар иде... Яңа гына тикшерелдем, терелгәнмен. Сез терелттегез! Нәрсәгә икәнен дә аңламадым, әмма аякларым үзләре көн саен картинагыз янына алып китте...» – дип сөйләде ул миңа. Кем белә, табиблар, бәлки ялгышкан гына булгандыр. Әмма сүз таралды...
«Кочак» дип атала иде ул эшем. Кешенең эчке энергиясен ачарга булышучы махсус тренингка йөреп, күнегүләр узып, бик канатланган чагым иде. Бөтен дөнья камил булып күренгән мәл. Ясаганда ук картиналар сериясенең уңышлы килеп чыкканын тойдым. Мактану түгел бу... Үзең канәгать булганда гына башкаларга да ошый эшләрең. «Халык күргәзмәне карап чыга да кабат «Кочак» янына килеп туктый», – диделәр. Мәскәү кешесе сатып алды аны. Соңыннан гына белеп шаккаттым: мин сораган бәядән дүрт тапкыр артыграк акча калдырган! Авырганда Һиндстанга, атаклы гуру Саи Баба янына барырга җыенган идем, операциядән соң терелдем, Аллага шөкер. Әмма әлеге теләгем калды – шул хыялны чынга ашырдым. Аннан – машина сатып алдым...
Ишембайның басу-кырларында үскән үләннәрдән пешерелгән гаҗәеп тәмле чәй безнең әңгәмәне шулай бөтенләй башка якка алып кереп китте әле. «Әни җыйган үләннәр... Аның янында гел халык – чир-сырхаудан дәва эзләп киләләр. Әнисенең әбисе кендек әбисе булган, дәвалаган, бу сәләт, бәлки, бераз миңа да күчкәндер, белмим. Янымда берәр кешенең нәрсәседер авыртса, шул урынга кулымны куям, булыша дип әйтәләр», – диде дә шушы тарихны сөйли башлады Раушания.
– Картиналарым – минем үзем, тормышым хакында, – ди ул...
Белмим, аның тоташ сынаудан гына торган тормышын киндергә төшерергә буяулар җитәрме?! Ә төсләрне... Төсләрнең кайсысын сайлыйсы?

Беренче адым

...Кечкенә чакта балерина булырга тели Раушания. Хәер, әнисенең чынга ашмаган хыялы булгандыр монысы: хореография училищесында укыган вакытта травма алгач, Зинфира апаны әтисе бухгалтерлыкка укырга күндерә – гомер буе баш хисапчы булып эшли ул. Әмма сәнгатькә тартылу күңелдә барыбер кала. Кызын да иң элек биергә, аннан соң гына тегәргә-бәйләргә өйрәтә. Ә Раушанияне... Пионерлар сараенда биюгә алмыйлар. «Башта ябыгырга кирәк», – диләр. «Салкын булгач, әни мине калын киендергән иде – шуны әйтергә оялдым», – дип көлә ул. Ә менә сәнгать мәктәбендә рәсем укытучысы аңа ике куллап ябыша: «Талант!» – ди. Әзерлексез-нисез аны беренче сыйныфка укырга алып та куя. Һәм адым саен: «Синнән күренекле рәссам чыгачак!» – дип кабатлый... Бу вакытта инде алар Стәрлебаш районының таулар арасына качып утырган Яшергән авылыннан Ишембайга күченгән булалар. Әти-әнисе шулай хәл итә: балаларга белем бирү өчен, кечерәк булса да, шәһәр кирәк.

Сәнгать мәктәбен тәмамлап диплом алуга аның үзен шунда укытырга чакыралар. Әле сигезенчегә генә күчкән Раушания өчен зур вакыйга була бу. Хезмәт хакы да түләячәкләр бит! Ул инде үзенең киләчәген рәсем ясау белән генә бәйләп күрә. «Син – хатын-кыз, гаилә корырсың, өйдә дә эшләргә мөмкинлек калсын дисәң, укытучы һөнәре ал, үзеңә җайлырак булыр», – дип киңәш бирә укытучысы. Әнисе китү турындагы сүзне ишетергә дә теләми. Ә Раушания барыбер үзенчә хәл итә: әнисен шифаханәгә ялга озаткач, документларын ала да Уфага чыгып китә. Зинфира апа кире әйләнеп кайтканда, кызы инде Уфа педагогика училищесы студенты була. Сызым һәм рәсем укытучысына укыячак!

Укулар башлана. Ишембайга кадәр атна саен кайтып йөри алмыйсың. «Санаторийда танышкан хатын сине үзләренә кунакка чакыра, барып кил әле», – ди әнисе. Бара Раушания. Үз йортлары белән торалар икән. Улы әфган сугышыннан кайткан, инвалид. Килгән арада да кызның өйдә әллә никадәр эш эшләп китүе хуҗаларга ошый, күрәсең. Беркөнне әнисенең яңа танышы Раушанияне каршысына утырта да: «Улымның сиңа күзе төшкән, әгәр аңа кияүгә чыкмасаң, ул үләчәк, – ди. – Әниеңнәргә: «Бала көтәм», дип әйт...»

– Җәлләвемне сизгәннәрдер инде... «Мин булмасам, аңа кем чыга?» – дип уйладым. Батырлык эшлим янәсе. Ул терелгәч, китәрмен, дидем. Нинди бала, үбешә дә белми идем әле... Әни бик елады инде. Уналтыда гына идем бит.

Яши башладык... Чәчем беренче тапкыр шул чакта агарды. Ә мине буятты дип белделәр... Аңарда эпилепсия иде. Өянәге көнгә өчәр тапкыр кабатлана. «Ул егылганда теш арасына кулыңны тыгарга кирәк», – дип өйрәтте әнисе. Ә ул андый чакта үз-үзен белештерми, тешли. Училищеда рәсемне начар ясый башлавыма игътибар иттеләр – кулым гел җәрәхәттә иде...

Күзгә күренеп сүнә башладым. Ярату юк. Кайдан килсен! Ә ансыз ничек яшәргә?! Озакламый барысы да бала юклыгын аңлады. Мин дәшмәдем. Дәшә алмадым... Хирург булырга укучы туганнан туган Илшат абыем бар иде. Безнең училище аның тулай торагы белән янәшә: сукмаклар гел кисешеп тора. Бер очрашуда барысын да аңа сөйләдем. Ул шунда ук әти белән әнине чакыртып китерде... Ул чакта борчылудан колагым ишетми башлады. Өстәвенә: «Балагыз булмаячак», – дигән диагноз куйдылар. Бердәнбер шатлыгым – рәсем калды...

Тормышка беренче адымым шулай күңелсез тәмамланды минем. Әмма ул язмышымда бар – сөйләми кала алмыйм...

...Ә Яшергән, Ишембайлар бер эшеннән икенчесенә күчеп, аны гомер буе озатып барачак. Менә – «Намаз» картинасы. Сәҗдәгә иелгән татар карчыгы – Маһирә зурәнисе. «Аның намаз укыганын күзәтергә ярата идем, – ди Раушания. – Хыялыма чикләр юк! Намазлыгында килеш аны күкләргә күтәрәм, ак яулыгы – ике ак канатка әйләнә, йолдызлар аның баш түбәсенә таҗ булып тезелә... Адәм баласын дога гына шулай күкләргә менгезә ала. Бу эшем – шул хакта».
«Картәни» картинасында исә аны тәрбияләп үстергән Рәхимә әбисе. «Картәнием авылдан беркая чыкмаган, – ди Раушания. – Унбер бала табып үстергән. Үзе вафат булганда җидесе генә исән иде.
Бу кадәр хәсрәткә ничек чыдагандыр... Ул пешергән ипиләрнең тәмен хәтерлим. Сигезәр ипи сала иде берьюлы. Кешеләргә ярдәм итү сәләте шушы Рәхимә әбиемнең әбисеннән килә безнең нәселдә».
Яки менә «Азан» картинасы. Монысында – картәтисе Зәкиәхмәтнең язмышы. Аллаһы Тәгаләгә ышануы аның өчен инану гына түгел, зур сынау да булган. Диннең иң тыелган чагында мулла вазыйфасын үтәгән – авылдашларын хак юлга өндәгән. Сүз уңаеннан: Раушаниянең Нефть институтын тәмамлаган абыйсы Алмаз, көннәрдән бер көнне барысын да ташлап, Уфага, мәдрәсәгә барып укырга керә. Бүген ул Себер шәһәрләренең берсендә – имам. Тамырлар чакыруы...

Мин Аллаһы Тәгаләгә һәм... Мәхәббәткә ышанам!

Икенче адым

Училищены тәмамлауга, Уфа дәүләт сәнгать институтына (бүген ул сәнгать академиясе дип атала) укырга керә Раушания. Хәер, укый да, «Иске Уфа» нәшриятында эшли дә. Чәчләре җиргә тиеп торган кызны фотомодель итеп тә чакыралар. Ә аннары юлында Илдар очрый... «Балагыз булачак!» – дигән хәбәрне ишетеп (табиблар бөтен өметне өзгәннән соң!), шатлыктан кая басарга белмәгәндә, әнисе аны җиргә төшерә: «Шалтырат үзенә. Кияүгә чыгасың...»

Уллары Рәүф туа. Әмма Раушанияне: «Рәссам булам!» дигән хыялына илтеп җиткерергә тиешле уку да бар бит әле. Ире сүз әйтмәсен дип, рәсем ясаулар төнгә кала. Сессия алдыннан берничә көн рәттән йокла-

маска өйрәнә. Дәресләр гел бер вакытта тәмамланмый – соңарган чаклары да була... Беркөнне иртүк ишектә кыңгырау тавышы шалтырый. Ачса – әтисе белән әнисе басып тора. «Ни булды?» дип аптыраган кызларына кулларындагы телеграмманы сузалар: «Кызыгызның тәртибен тикшерергә кирәк, тиз килегез». Кайнатасы иренә аның кайчан, ничәдә кайтканын язып барырга кушкан икән. Көләргәме, еларгамы?

Ясый башлаган картинаң, син уйлаган кысадан чыгып, бөтенләй башка юлдан да китәргә мөмкин.

– «Ул бит сине кыйнамый, түз», – диде әни. Түздем... Онкология, диделәр. Хастаханәдә ятканда кулыма Луиза Хейның китаплары килеп эләкте. Аның язганнарына ышанам мин. Чиремнең сәбәбе – күңелемдәге үпкәләремдер дидем. Операциядән соң улымны алдым да (бу вакыт аңа 5 яшь иде), тулай торакка күчендем... Шөкер, мин аларның барысын да күптән кичердем инде...

Ходайның ярдәм итүе булгандыр – заказ арты заказ ява! Эшләремне ала башладылар. «Картәни» картинасын саткач, тоттым да Сочига китеп бардым. Авырганда: «Мин бит әле диңгезне дә күрмәдем», – дигән уй һич башымнан чыкмаган иде...

Көндез нәшриятта эшлим, кичләрен килгән заказларны үтим. Алны-ялны белми эшләдем ул чакта, өч-дүрт сәгатьтән артык йокламадым. Ике ел дигәндә, фатир сатып алдым. Әти белән әнине, абыйны ялга җибәрә алдым, үзем дә шифаханәләргә бардым.

Шәһәр, республика, халыкара күргәзмәләрдә катнаша башлаган еллар да бу.

Үзеңне ирексез итеп санаган чаклар һәркемдә буладыр. Моны бөтен барлыгы белән тойган мизгел исә – иң авырыдыр. Әмма һәркемнең дә сайлау мөмкинлеге бар – киләчәкнең ачкычы үз кулыңда. Раушаниянең «Читлектә дә очып була» картинасы – шушы хакта. Бу эше Мәскәүдә, Милләтләр музее йортында саклана. Елы күрсәтелмәгән, әмма аның «Дога» картинасы да шушы чорга карый бугай. Ике дөнья чигендә торган Ана, кулларын күтәреп, Ходайга ялвара: «Баламны гына сакла! Аны гына ярдәмеңнән ташлама!..» Керфекләре түбән төшкән, әмма андагы ихтыяр көче, ныклык, сабырлык бөтен барлыгында чагыла.

Ә доганың көче зур. Җирдән дә зур!

Өченче адым

Илдар белән уртак танышларында күрешәләр алар. (Әйе, тагын Илдар! Өстәвенә, әфган сугышы ветераны да әле, республиканың әфганчылар хәрәкәте җитәкчесе. Нишләтәсең, язмыштан уза алмыйсың! Раушаниянең исә үз фәлсәфәсе: «Мин аласы сабаклар бетмәгән, димәк».)

– Илдар тимерче иде ул чакта. Әлбәттә, иҗади тимерче... Кулы эш белә, кадак кага ала дип уйладым. Бөтен хатын-кыз кебек өйдә утырырга теләдем, балалар тәрбияләп кенә. Утырдым. Тик бу минеке түгел икән...

Ирем миңа улын ияртеп килде. Әскәр – улым Рәүф белән яшьтәш диярлек: мин аны шунда ук кабул иттем. Яраткан ир-ат өчен хатын-кыз барысын да эшли... Әскәр миңа «әни» дип дәшә. Үз әнисе исән булганда болай эндәшү дөрес түгел кебек, әлбәттә. Әмма ул бик ягымлы бала, яратуын яшерми – күрсәтә белә. Бәйрәмнәрдә шундый котлаулар җибәрә – күз яшьләрсез укый да алмыйм. Кайтуга кочып ала, миңа булышырга тырыша: «Син утыр, ял ит», – ди. Илдар аларның икесен дә кадетлар мәктәбенә бирде. Мин теләмәдем, билгеле. Төннәре күгәреп кайтулар еш булды, әмма мәктәпне ташламадылар. Аның каравы, бик мөстәкыйль булып үстеләр. Бүген берсе – Мәскәүдә, икенчесе Санкт-Петербургта яши. (Рәүф нәкъ үзем кебек, кон-







цертка дип китте дә укырга кереп кайтты!) Ә Илдар без өйләнешкәннән соң күтәрелә башлады, эшмәкәр булып китте.

Хәер, ул үзе дә иҗатның күптән башка биеклегендә инде. Раушания Бәдретдинова бүген ЮНЕСКО Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясе, Россиянең дизайнерлар һәм Башкортстанның Рәссамнар берлеге әгъзасы. Егермедән артык шәхси күргәзмәсен оештырырга өлгергән. Аның эшләре Россия, Украина, Канада, АКШ, Австрия, Германия, Нидерланд, Төркия, Намибия кебек илләрнең картиналар галереяларында, шәхси коллекцияләрдә саклана. (Беркайчан, берәүгә дә сатмаячак эшләре дә бар. «Айшә белән Әхәт» картинасы – шундыйлардан. Кечкенә балалары – улы белән кызы сурәтләнгән анда. Кадерледән-кадерле җаннар. Аларга кадәр җиде өметеңне җир куенына салгач соң...)

Өч ел элек Мәскәү Милләтләр йортында аның «Агыйдел ярындагы кала» дигән шәхси күргәзмәсе уза. Картиналарны сатудан кергән табыш «Подари жизнь» һәм «Мәрхәмәт» (Уфа) хәйрия фондларына күчерелә. Бер кичтә 600 мең сум! Журналистларның берсе, Раушания янына килеп: «Үзегезгә нинди әйбәт пиар ясадыгыз», – ди ул көнне. «Җавап бирмәдем, – ди. – Ни диим? Авырганда: «Исән-сау терелсәм, кулдан килгән кадәр башкаларга ярдәм итәр идем», – дигән сүзем бар иде...»

Үсеш ягыннан артта калган балаларга «Мәрхәмәт» фонды еш кына рәсем дәресләре оештыра. «Күңелем куша, шуңа бу балалар янына барам да, – ди Раушания. – Яшермим, алар янында җиңел түгел. Үзләрен кайчан, ничек тотасын белмисең. Утырган җирдән кинәт торырга, сине этеп җибәрергә мөмкиннәр. Очлы әйбер белән кулыма да кадаганнары булды. Алар белән эшли торган үз методикам бар инде. Дәфтәр битенә проблемаларын ясыйбыз, аннан, төсләрне үзгәртү аша, алардан котылырга тырышабыз».

Владимир Спиваковның Уфадагы талантлы балаларга ярдәм итү хәйрия фонды хезмәткәрләре дә аңа бик рәхмәтле: ул аларның проектларында катнашудан беркайчан баш тармый. («Ана һәм бала» клиникасында әзерләнгән бер күргәзмәне маэстро өчен тәкъдим итүне Раушаниянең үзенә тапшыралар. «Җандагы көй» картинасы янында озаграк тукталалар. «Яр буенда утырам, бала искеләре юам, ә үзем Париж турында хыялланам», – дип елмая Раушания. «Ә мин Парижда яшим», – ди атаклы музыкант. «Беләм, сез бәхетле...» Икенче көнне исә Владимир Спиваков фондыннан шалтыратып, аны Парижга иҗади командировкага чакыралар. «Җандагы көй» – аңа Париж урамнарын күрсәткән картина.)

Киндергә төшәсе сурәт гел күз алдында, уеңда – коймаклар кайчак шуңа көя.

Башкортстанда Раушания Бәдретдинованы үз кием линиясен уйлап чыгарган рәссам буларак та беләләр. «Монысына үзем матур киенәсе килгәнгә тотындым – дип көлә ул. – Екатеринбург шәһәрендә узган күргәзмәдә батик ысулы белән яулыклар ясаучы рәссам белән таныштым. Самолетта кайтканда исә башыма уй килде: «Мин бит картиналарымны тукымага күчерә алам», – дим. Берне ясап карадым, икене... «Коллекциягә тотынып карарга кирәк сиңа», – диделәр. «Яратам» һәм «Киндердән – тукымага» коллекцияләре шулай туды. Тәкъдим итү кичәсендә үк алып бетерделәр. «RUSHA» линиясен дәвам итү өчен вакыт һәм матди мөмкинлекләр кирәк».

(*Ахыры 64 нче биттә.*)





PRESSA



АЛТЫН КОЕЛГАН ҖИРДӘ



ИҢ-ИҢ ЯХШЫНЫ АЛТЫН БЕЛӘН ТИҢЛИЛӘР. АЛТЫН КУЛЛЫ ОСТА, АЛТЫНГА БИРГЕСЕЗ ЭШ, ДИЛӘР.

Лилия ГӘРӘЕВА

Ләкин үз бәһасен алганчы, ул алтынның җиз иләкләрдән иләнәсе бар әле. Алтын куллы оста булып та тумыйлар, анысы өйрәнә-өйрәнә килә.

Бер бүлмәсеннән – яңа гына юнылган йомычка, икенчесеннән затлы күн исләре килгән, кайдадыр тегү машинасы теркелдәгәне ишетелгән бу уку йорты Казанда гына түгел, бөтен Идел буенда берәү генә. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән студентлар белем ала монда. Кем кайдан гына килмәсен, максатлары бер – халык сәнгате һөнәрләренең чын остасы булу. Алар белем алган, осталыкларын чарлаган уку йорты да нәкъ шулай атала – «Халык сәнгате һөнәрләре техникумы».

Илле елдан артык тарихы булган бу техникум 1963 елда сәүдә хезмәткәрләре әзерләүче 40 нчы һөнәри-техник училище булып ачыла. 2010 елдан уку йортын Раушания Сәүбәнова җитәкләргә алына. Чирмешәндә туып-үсеп, токарь һөнәрен үзләштергән Раушания Кыяметдин кызына үз гомерендә программамист та булырга, методист эшен дә алып барырга туры килә. Аннары Казан дәүләт мәдәният институтында укыган еллары, фән кандидаты булу, үзен зур дөньяга чыгарган белем йортында студентлар укыту... Әнә шулай чарланып, зур тәҗрибә туплап килгән ханым беренче көннән үк училищеның статусын күтәрергә, онытыла баручы халык сәнгате һөнәрләренә игътибарны арттырырга омтыла. 2011 елдан училище,

34 нче лицей белән кушылып, «Халык сәнгате һөнәрләренең профессиональ лицее» дип үзгәртелә. Бүгенге атамасына ул 2013 елда ирешә.

Күксел төтенгә өртелгән остаханәдә зәркәнчеләр мәш килә. Алларында кәгазь битенә төшерелгән эскизлар – алка, йөзек, түштамгалар әнә шулай ак кәгазьдә туа башта. Бер шәкерте янында озаграк туктала директор апалары. «Илгиз Латыйпов дигән егетебез бу. Быел Мәскәүдә узган «WorldSkills» милли чемпионатында ташларны кырлау компетенциясе буенча җиңү яулады». Гаҗәпләнмим. Техникум студентларын берләштергән волонтерлар отрядының да башкаладан танылу алып кайтканын беләбез.

Диварларның бизәлешенә карап кына да кайсы катта нинди белгечләр әзерләнгәнен чамалап була монда. Керамик паннолар балчыктан сәнгать туа торган остаханәгә юл күрсәтә бара. Бер карасаң, гап-гади кызыл балчык кебек. Укытучылары Алсу Саттарова кебек осталар кулында кызыл балчыкка да җан иңә икән. Әллә нинди затлы павильоннарда сатылучы керамик савыт-сабалардан һич кайтыш түгел, бәлки, үзебезгә генә хас милли бизәкләре белән тагын да күркәмрәк күренгән шушы вазаларны, комган, кувшиннарны чыгарып тез идең кибетләргә. Бик рәхәтләнеп алырлар иде. Милли төсмерләр шулкадәр тансык бит хәзер.

Чигүчеләрдә рәсем дәресе иде. Миләүшәләр, күгәрчен күзләре тукымага сибелсен өчен югары категорияле укытучылары Разидә Юнысовадан рәсем әлифбасын өйрәнәсе бар әле. (Сүз уңаеннан: Разидә Заһит кызының Әмир Мәҗитов музеенда күптән түгел генә күргәзмәсе узды.) Кайсы гына һөнәрне алма, идеяләр әнә шулай ак кәгазьдә бөреләнә. Оста чигүче – иң элек оста рәссам да. Тукымадагы күкчәчәкләргә зәңгәр нур бөркергә өйрәнгәнче, остазлары Елена Угремова белән бер генә йомгак мулине бетермәсләр әле. Барысы да бер сүз белән – чигеш дип кенә аталса да, аның да әллә никадәр төре бар: канитель белән чигү, шома чигү, тамбурлы җөй, тасмалар белән чигү, энҗеле бизәк... «Идел буенда нинди халыклар яшәсә, барысының да киемнәрен, бизәкләрдәге чигешләрне, аларны башкару ысулларын өйрәнеп, заманага ярашлы яңа костюмнар тегәргә өйрәнәбез», – ди тегүче остазлары Лилия Хәбибрахманова.

Зәркәнчеләр, чигүчеләр, кисүче-тегүчеләр, костюм буенча рәссамнар, агачтан, металл, күннән, балчыктан сәнгать эшләнмәләре осталары, бизәүче рәссамнар, халык сәнгате һөнәрчеләре, интерьер һәм экстерьер дизайнерлары – боларның барысын да Халык сәнгате һөнәрләре техникумында әзерлиләр. 9 нчы сыйныфны тәмамлап килүчеләр, белгечлегенә карап, 3 ел да 10 ай, 2 ел да 10 ай укыса; 11 нче сыйныфтан соң 1 ел да 10 ай гына укый, 10 айлык кына курслар да бар. Техникумга Россия һәм Татарстан хөкүмәте заказы буенча бюджет урынына 263 укучы кабул ителә, һәр елны 175 белгеч әзерләп чыгарыла. Түләүле бүлекләр дә бар, теләге булган беркемне дә кире бормыйлар. 50 елдан артык эшләү дәверендә биредә 11 мең белгеч әзерләнгән. Раушания Кыяметдиновнаның да, остаз-укытучыларның да, директорның уң кулы булган Миңзифа Гаязова, Гүзәл Касыймова, Гүзәл Газизова, Фәния Фәйзуллина, Илмир Мифтаховларның да максатлары уртак – техникум җәмгыятькә кирәкле хәзерге заман кешесен тәрбияләргә тиеш.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Б. Урманче, Г. Тукай премияләре лауреаты Софья Кузьминых, «Алмаз-Холдинг» зәркән компаниясен оештыруда башлап йөргән зәркән осталары – Евгений Баканин, Андрей Гавриков, Марат Галиев (Worldskills чемпионатының сертификатлы эксперты), алтын җепләр белән чигү остасы Елена Угремовалар әзерләгән шәкертләр бер җирдә дә сынатмый. Техникумны тәмамлап, үз остаханәләрен ачучылар да, «Адонис», «Тылсым», «Туран» ширкәтләрендә, «Алмаз-холдинг», «Кулон», «Магия серебра» зәркән заводларында, театрларда эшләүчеләр дә бар. Алтын куллы осталарга кайда да ихтыяҗ. Техникум тәмамлаучыларның 87,5 проценты үз һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча эшләсә, 7,4 проценты үз профиле буенча югары уку йортларында белем алуын дәвам итә.

Соңгы өч елда гына да техникумга хөкүмәттән 25 миллион сум акча бүлеп бирелгән.

Үзе яңа сулыш өргән, материаль-техник базасын ныгыткан техникумга килгән кунакларны Раушания Сәүбәнова музейга алып керми калмый. Ләкин бу юлы алдан ук кисәтеп куясы итте: «Музеебыздагы күп кенә экспонатлар съемкада әле». «Зөләйха күзләрен ача» фильмын төшергәндә техникумның алтын куллы осталары җитештергән зиннәтләр файдаланылган икән. Безнең бу музейда беренче генә булуыбыз түгел, манекеннардагы костюмнарга карап, төбәгебездә нинди халыклар яшәгәнен дә белергә, Идел Болгарстаны чорыннан сакланган һәм Казан татарларының борынгы бизәнү әйберләрен өлге итеп ясалган зәркән эшләнмәләре, күннән, балчыктан ясалган көнкүреш товарлары буенча тарихыбызга сәяхәт кылырга да мөмкин монда.

Уку йортында татар халкының милли бизәнү әйберләрен өйрәнү һәм җитештерү буенча фәнни лаборатория эшли. Болгар музей-тыюлыгы экспозицияләрендәге зәркән эшләнмәләренең дә шактые биредә җитештерелгән. Хәзерге вакытта техникумда Татарстан Республикасы Милли музееның экспозиция фондын булдыру буенча зур эш бара.

Раушания Кыяметдиновнаның якын киләчәккә бер хыялы бар: үзләрендә җитештерелгән шушы алтынга биргесез сәнгать эшләрен шәһәребезгә килгән туристларга да күрсәтү һәм сату. Буй җитмәслек хыял түгел ул. Техникум Кабан күле буенда гына: яр буйлап сузылган җәяүлеләр сукмагы аларга кадәр килеп җитсә, бу тирәләрдә сәүдә рәтләре гөрләр әле.

PRESSA



КҮКСЕЛ РӘШӘЛӘРНЕҢ СУЛЫШЫ

Рәмис АЙМӘТ

Коеп куйган шагыйрь шундый була-дыр. Рәмис Аймәт кебегрәк. Эстет, романтик, хыялый, ихлас... Моңлы яктылык бөркелә үзеннән... Гаҗәп нечкә тоемлы: ялгыш та берәүнең бер хәтерен калдырмас, сүзләрен уйлап-җайлап әйтер. Ә шигырьләре – җырлап тора. Хәер, Рәмис үзе дә җырлый бит! Ул җырчы-шагыйрь дә әле.
«Өзелсә барасы юлларың,
Үрермен мин күпер гөлләрдән...»
Исегезгә төштеме? Рәмиснеке!
Аны яшьләр «безнең Есенин» дип йөртәләр... Дәрдмәндне ярата. Роберт Әхмәтҗановның җыр итеп язылган шигырьләре җанына якын. «Шомырт салкыннары», «Айның аръягында» исемле шигырь китапла-рын укучылары бер сулышта укып чыктылар. «Рәмиснең зәвыгы, сүзләрнең затлы бизәге күбәләк кана-тыннан җилпенеп калган алтын тузан булып уйный һавада...» Шагыйрә Луиза Янсуар шулай бәяләгән иде аның иҗатын.
Игътибарыгызга Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Рәмис Аймәт шигырьләрен тәкъдим итәбез. Сезнең күңелләргә дә күбәләк канаты булып кагылсын-нар әле...

Эльмира ЗАКИРОВА

Белмим инде...

Кичә генә бар да башка иде:
Карасы да башка, агы да.
Никтер бүген ерак офыкларның
Алсулыгы арткан тагы да.

Төссезләнеп калган дөньялыкның
Сагышлысы әллә мин генә?
Алай дисәм, моңсу өрәңге дә
Сары шәлен салган иңенә.

Тирән уйга чумган болынымның
(Юк, юк, аның уен бүлмәдем).
Ул да инде, чуар күңелемдәй,
Кигән үзенең чуар күлмәген.

Әллә мин дә чатта дөрләп янган
Ялгыз чаган кебек кабыныйм?
Белмим инде, шушы хәлләремдә
Нинди генә төскә ябыныйм?..

Үтә икән...

Если боль не тревожит,
Разве радость найдешь?
Поль Верлен

«Үтмәс!» дигән идем. Үтә икән.
Үтә икән. Телә. Теләмә.
Вакыт – дәва. Һәрбер үткән яра
Җан газабы белән түләнә.

Үтә икән. Җаннан китә икән,
Китмәскә! дип килгән даулар да.
Карашымның тамырын
йолкып җирдән
Күтәрелеп карыйм тауларга.

Карашларым котсыз кыяларны
Кинәт кенә иңләп җиталмас.
Тезләнсәң дә килеп, йөрәк әле
Кинәт кенә гафу италмас.

Йөрәк әле... һаман иңләп йөри
Шатлык белән кайгы арасын.
Көннәремдә көн яктысы җитми,
Төннәремнең җитми карасы...

«Үтмәс!» дигән идем. Үтә икән.
Үтә икән. Телә. Теләмә.
Вакыт – дәва. Һәрбер үткән яра
Җан газабы белән түләнә.

Элегия

Көтәм...
Көтәм...
Шәфәкъ шәүләседәй
Офыккача сузылсачы хәбәр:
Иңнәремнән таулар төшәр сыман,
«Кай-та-ам» диеп аваз салсаң әгәр.

Араларда кояш бата мәллә? –
Сузылып ята соңгы күләгәләр...
Синнән алып миңа хәтле ара –
Мәхәббәттән хыянәткә кадәр...

Көтәм сине, кышын – ап-ак карлар,
Көзләр җиткәч, сары яфрак булып.
Синнән миңа соңгы хәбәрме ул –
Узып бара кәрван-кәрван болыт.

Чакыру

Ты опять со мной, подруга осень!
И. Анненский

Көзгә керәм...
Берьялгызым гына.
Син җәйләрдә әле йөрисең.
Әле һаман җәйнең кочагында
Шәфәкъ нуры булып эрисең.

Күптән сулган чәчәк таҗларыннан
Син һаман да назлар эзлисең.
Үткәннәрне утка яга-яга
көзләр килгән.
Ә син сизмисең.

Тузганактай тузгып очынасың,
Тыялмыйча шашкын хисләрең.

Кил көземә, кил син,
күңеленә
Җыеп җәйнең соңгы төсләрен.

Кил көземә...
Ул үзәннәр, таулар
Безнең хакта күпме сер саклар?

...Көтеп синең аяк тавышларың,
Җиргә ятып тыңлый яфраклар...

Без генәме?

Аерды ла толымыңдай сукмак,
Араларга ятты елан сымак.
Беркем дә юк. Шомлы шәүләмени –
Язмыш атлый, язмыш бара сынап.

Беркем дә юк. Миңа юлдаш булып,
Тезләремә сырыла сырганаклар.
Минем кебек барыр юлын эзләп,
Бөргәләнеп ага ерганаклар.

Ага уйлар...
Истәлекләр ага...
Ера-ера хәтер буразнасын.
Җир әйләнә. Галәм тәлинкәсе
Яза безнең Сөю елъязмасын.

Җир әйләнә...
Безнең сөюләр дә
Бер әйләнеп кайтыр бит әле.
Без генәме? Әллә дөньяның да
Мәхәббәтен җуйган бер мәле...

Яңгыр

Шулчаклы да гөнаһлымы син, җир –
Туктый алмый көзнең яңгырлары.
Бу җиһанга бүген яңгыр хуҗа,
Яңгыр, яңгыр...
яңгыр гына бары.

Күкләр серен җиргә сөйли-сөйли
Или генә, или көзге яңгыр.
Нигә борчулы соң күлдәвекләр?
Аһ, күкләрдән берәр хәбәр бардыр.

...Гөнаһларны юып, яңгыр ява.
Яңгыр гына бары...
яңгыр, яңгыр...

Әйтер микән таулар?..

Таулар – сабыр,
таулар әнкәй кебек,
Эчтән яна, эчтән көядер.
Шул тауларга карап уйга калсам,
Әнкәй төшә искә нигәдер.

Хәлсез куллар кебек, тауларымны
Кочып алган күпме сукмаклар.
Әйтер микән таулар, әнкәемнең
Йөрәгенә күпме сукмак бар?!

Араларда күпме таулар ята, –
Сагынуларым салыйм кайларга?..
Мин дә бүген, сабырлыклар сорап,
Башым салдым килеп тауларга.

Китәсең...

Язлар булып килеп кергән идең,
Көзләр булып китеп барасың.
Ерагая бара, ерагая
Безнең мәхәббәтнең арасы.

Ерагая бара ант-вәгъдәләр,
Серле карашыңның җылысы.
Якыная... сине кочып алган
Куксел рәшәләрнең сулышы.

...Көзләр булып китеп барасың син,
Соңгы яфрак кебек талпынып.
Йөрәгемдә минем дөрләп яна
Көзге усакларның ялкыны.

Дөрләп яна минем йөрәгемдә
Үткәннәрнең һәрбер мизгеле.
Ул көннәрнең һәрбер мизгеле дә
Килеп табынырдай изгеме?!

Хатирәләр генә басар микән
Сагыну-югалтулар ярасын?
...Язлар булып килеп кергән идең,
Көзләр булып китеп барасың...

Ярты юлда

Хәрәкәтсез җиһан –
нидер көтә бар да,
Онытылып дөнья аһ-зарыннан.
Китәлмичә тора поездлар да
Актарылган күңел вокзалымнан.

Вагон-вагон сагышларым тора,
Тукталган да йөрәк перронында.
Ярты юлда өзелеп калган кебек,
Көпчәкләрнең серле җыры монда.

Сүзсез ак сүрәме, ни язылган
Аккошларның киткән юлларында?
Туктап калган... кошлар көтүедәй
Күтәрелеп киткән елларымда.

Сүрәнәйгән мәллә карашлар да? –
Үзе таныш дөнья, үзе ят та.
Туктап калган, ни могҗиза көтеп,
Ярылырга торган йөрәк хәтта.

Ач бүредәй ташланган да дулкын –
Катып калган язмыш өнсез ярда.
Вакытларның кайсы мизгеле бу? –
Ярты юлда, ярты юлда бар да.

Җәйнең соңгы җыры

Инде... үтте! Ерак офык аръягында
Җанкаемның яшел кошы –
оча гына.
Мин үлмимен, юк, үлмимен –
китәм бары
Дөрләп янган чуар төсләр кочагына.

Мин үлмимен, юк, үлмимен –
күчәм бары
Лепердәшкән яфракларның
моң-җырына.
Иярәмен җан җылымны
саклап барган
Ап-ак сагыш – киек казлар
чылбырына.

Ки-тә-мен бит! Томан булып
ята тыным. –
Үтте инде – уңды төсем, тынды көем.
Инде нишлим? Узган гомер
сәхнәсендә
Салкын көзнең шәрә җиле
булып бием.

Бием – шашып! Изүләрем ачып-ачып!
Сызланса да, утлы тәлгәш булып,
ярам. –
Күрегез, күр! (Яңгыр түгел.)
Соңгы тамчы,
Күз яшедәй, тәгәрәпләр
төшеп барам...

Чарасыз күбәләк

Телеп үтте кинәт күкне яшен, —
Яшь өрәңге куйды чүгәләп.
Куркынганмы? Әрле-бирле килеп,
Очып йөри ялгыз күбәләк.

Урын табалмады күбәләк-җан,
Нинди генә гөлгә кунса да.
«Ачмаслармы ишекләрен?» – диеп,
Килеп кунды салкын тупсага...

Исеп куйды кинәт яңгыр җиле,
Кара болыт күкне каплады.
Ә күбәләк, бахыр, эчтән генә
Һаман серле сүрә ятлады.

...Таң атарга тиеш иде бүген,
Озаклады никтер...
Атмады...


Нурихан Фәттах... Күренекле язучы, галим, философ, этнограф, публицист, тәрҗемәче... Без аны «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», «Кол Гали», «Сармат кызы Сәринә»ләре аша беләбез, «Сезнеңчә ничек?», «Бала күңеле далада», «Мөдир Саҗидә»ләре өчен яратабыз. Ә серле «Фест дисбесе» могҗизасы тагын? «Моннан өч-дүрт мең еллар элек язылган бу серле язуны без төрки телдә укырга тиешбез», – дип, Нурихан ага 90 ел буе диярлек бер кеше дә укый алмаган текстны укуга ирешкән! Дөнья тарихында ачыш ясаган!

«Картәтәйнең язган һәр юлын, һәр сүзен тулысынча аңлар өчен ул белгән хәтле белергә, ул укыган хәтле укырга кирәктер», – ди әнә оныгы Зөләйха.

«Үземнең бөтен иҗатым, тормышым белән мин халкымның бөеклеген исбат итәчәкмен». Бу – язучының тормыш девизы. «Үзенең кем нәселе, нинди халык булуын яхшы белгән кеше беркайчан башкалар алдында каушап калмас...» Нурихан Фәттахның шушы сүзләре бүген васыять кебек яңгырый.

Тарихта зур бәхәсләр уяткан «Аклан» романы турында сүз чыккач: «Нурихан татарның килеп чыгышын көнчыгыштан түгел, көнбатыштан дип әйтә иде. Ул татарларның борынгы Греция, Мисыр, Шумер цивилизациясеннән килеп чыгуын үзенең хезмәтләрендә раслады», – дип искә ала язучының хатыны Руфина ханым (тәгәлләнмәгән бу әсәрне Руфина Фәттахова үз кулы белән яңадан күчереп яза).

Халык язучысы Нурихан Фәттахның тууына 90 ел тулуны билгеләп үткәндә, игътибарыгызга «Сызгыра торган уклар» романыннан бер өзек тәкъдим итәбез.


Нурихан ФӘТТАХ

СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

(Романнан өзек)

Туман тарханның Күксай үзәненә килеп урнашуы турындагы сүзләр музлыларның Кондыз авылына соңгарак калып иреште. Дүрт өйлек Кондыз авылы Олы тау, Кече тау дип аталган ике биек тау башындагы уч төбедәй тар гына, кысан гына яланда утыра иде. Тау башындагы әлеге яланга менү юлы шактый текә һәм җайсыз булганга, Кондыз авылына бөтенләй диярлек чит кеше килми иде. Монда бары кайчагында аучылар килеп чыга да, онытканда бер йомышлары төшеп, ерак күршеләр килгәлиләр иде.

Бу юлы да шулайрак булды. Кичкә таба, тыштагы барлык эшләрен бетереп, Сылу-кыз өйгә керде, учакка утын өстәде дә өстен-башын чишенмичә генә казан асты. Аннан соң ул кара өйдән туң болан тиресе алып керде, эресен өчен аны җайлап бастырып куйды.

Шулай тире белән булашкан арада Сылу-кыз тышта кайдадыр тау астындамы эт өргән тавышлар ишеткәндәй булды. Сагаеп тыңларга тотынды. Чыннан да, авылның теге башында этләр өрә иде бугай. Тунын яңадан каптырып ул тышка чыкты һәм тавыш килгән якка карап, тыңларга тотынды.

Ялгыз өйдә ялгыз яшь хатынга бик тә моңсу һәм күңелсез иде. Көне буена ул бүген кемнедер көтте, сагынып, өзелеп көтте. Тар сукмактан тау астындагы чишмәгә суга барганда да, кара өйдән утын алып кергәндә дә, эше төшеп каеннаталары өенә барганда да ул әледән-әле еракка – көн ягындагы күгелҗем таулар ягына карап торды. Ул көткән, ул теләгән кемдер менә шул сихри-моңсу таулар ягында булырга тиеш иде. Һәм ул кемдер нинди дә булса башка бер кеше түгел, бәлки аның сөеклесе, аның Мамак атлы ире булырга тиеш иде.

Көчле иде, кыю иде Мамак. Ул аткан ук беркайчан тими калмый, ул ыргыткан сөңге беркайчан читкә тайпылмый иде. Былтыр кыш ул берүзе бер аю алып кайткан. Бөтенләй коры кул белән диярлек. Искәрмәстән килеп чыккан аю аны сугып ега. Мамакның кулында уксыз

җәядән башка берни булмый. Баштарак Мамак шул җәясе белән каршы тормакчы булып карый. Ярсыган аю аның җәясен теше белән эләктереп ала да чәйнәп, ботарлап ташлый. Мамакның кынында пычагы да була. Исенә килеп, ул пычагын кыныдан тартып чыгара да иләмсез аю үзенә якынаю белән алга ыргыла һәм ерткычның күкрәгенә, йөрәк турысына очлы, үткер тимерен батыра. Бу хәл кичтән була. Икенче көнне иртән киемнәре теткәләнеп, канга буялып беткән Мамак, аю тиресен көчкә өстерәп, өенә кайтып җитә. Кондыз кешеләре генә түгел, килгән-киткән аучылар да шакката моңа. Мамакның батырлыгы, кыюлыгы турындагы сүзләр бөтен тирә-якка тарала. Шуннан соң еш кына аны Аю-Мамак дип атый башлыйлар.

Үзәндәге музлылар белән таулар-урманнар арасындагы тузбашлар элек тә бик үк тату яшәмәгәннәр. Ачык җирдә, үзәндә көтү көтеп көн күрүче музлылар баерак, көчлерәк һәм борнайраклар иде. Тар аралыкларда, кысан яланнарда яшәп яткан тузбашлар, мал-туар асраудан бигрәк, аучылык белән көн күрәләр иде. Еш кына аларга ялынып, теләнеп Күксай үзәненә барырга, музлыларга бил бөгәргә туры килә иде. Кайчагында музлылар белән тузбашлар үзара сугышып, кан коеп та алалар иде. Шундый үзара сугышларның берсендә Сылу-кызның абыйсы музлыларга бөлген төшкән. Аннан соң аны музлылар кемгәдер сатып җибәргәннәрме, үтергәннәрме – беркем рәтләп белми. Ни генә булмасын, абыйсы аның юкка чыккан.

Туман тархан Күксайга килеп, музлыларны аннан өрдергәч, бөтен нәрсә үзгәрде-куйды: ярлы, көчсез тузбашлар кинәт кенә көчәеп киттеләр, музлылар бетәшеп калдылар. Олы яудан котылган кайбер музлылар, сыену урыны эзләп, таулар-урманнар арасына басып керделәр, кайбер җирдә тузбашларны яланнардан, үзәннәрдән кысрыклап, арырак күченергә мәҗбүр иттеләр. Баштарак тузбашлар музлыларга берникди каршылык күрсәтә алмадылар. Ни әйтсәң дә, алардан шүрләү һәм шул ук вакытта аларны олылау тузбашларның канына сеңгән иде. Ләкин музлыларның тәмам җиңелүе һәм качып килүчеләрнең бик аз санлы булуларын күреп, тиз арада тузбашлар масая башладылар.

Шуннан, бервакытны кондызларның Мамак... Аю-Мамак атлы егете тузбашларның Баян авылында Сылу-кыз дигән бер чибәр кыз барлыгын ишеткән. Теге аю тиресен күтәргән дә килгән бу Баян карт авылына. Аю тиресен күреп, Баян картның күңеле йомшый. Шулай да аның болан бозавыдай озын торыклы, нечкә билле чибәр кызын килмешәк музлыга биреп җибәрәсе килми. Бу килмешәк музлы егете кайчандыр моннан берничә еллар элек Баян картның бердәнбер улын арканга алып киткән Кондыз алыпның улы була. Ата кеше шулай да Кондыз алыпның кияү булырга теләгән егетен кырт кисеп кире борып җибәрергә дә яхшысынмый. Шунлыктан ул юри аннан түләп булмастай калым сорый. Монда тагын икенче төрле исәп тә була бугай. Аю-Мамактан элегрәк Сылу-кызны тузбашлардан Йәрмәк улы Камаш сораган була. Кызым яшь дип, Баян карт аны кире борып җибәргән була. Нишләптер ул Камашны өнәп бетерми.

Аю тиресен кире күтәреп кайтып киткәч, көннәрдән бер көнне Аю-Мамак, туганнары белән бергәләп бер көтү терлек-туар куып, Баян авылына килеп төшмәсенме! Берьюлы бер көтү мал-туар күреп, шуларның барысының да үзенеке булырга тиешлеген аңлап, Баян карт юашланып калды. Кондыз улы Мамак белән бу юлы карт бик ягымлы сөйләште, шулай да күңелендәгесен тиз генә чыгарып салырга да ашыкмады. Йәрмәк улы эчен тырнап тора иде бугай.

Үч иткәндәй, икенче көнне үк Баян карт авылына Камаш үзе килеп төште. Мамакның бер көтү мал-туар куалап килүен аңа, күрәсең, кемдер хәбәр итеп өлгергән. Баян картның аягы астына ул таудай итеп тире-яры, кием-салым, табак-савыт өеп ташлады.

– Сиңа, бүләккә! Калымы аерым булыр, – диде ул Сылу-кызның әтисенә.

Болай булгач, эшләр зурга китте. Баян карт шунда Мамакны чакырып алды да бөтенесе алдында:

– Ярышасыз. Кем җиңә – кыз шуңа, – диде.

Камаш та батыр иде, ару-талу белмәс аучы иде, үткер күзле мәргән иде. Тик шулай да чын батыр булу өчен аңа нидер җитми иде сыман. Ягымлылык, эчкерсезлек җитми иде микән, тәвәккәллек, кыюлык җитми иде микән – Сылу-кыз моны бик үк төшенә дә алмады. Атасы Баян карт менә бөтенесен дә белгән.

Ярыштылар алар. Ерактан ук аттылар, сөңге ыргыттылар, көрәштеләр. Бөтен халык алдында Аю-Мамак җиңеп чыкты. Ата кеше әйткән сүзендә торды. Мамак белән Сылу-кызга аерым өй кордылар, шаулатып туй ясадылар. Өч көннән соң Аю-Мамак яшь кәләшен үзләренә алып кайтып китте. Нинди бәхетле иде алар ул көннәрдә!

Менә ул монда, Олы тау белән Кече тау арасында. Мамак өйдә юк.

...Чыннан да, Кече тау ягында этләр өрә. Анда кемдер бар иде булса кирәк. Кем булыр ул? Сылу-кызның Мамагы кайттымы әллә? Ул бит әйткән иде киткәндә пышылдап кына: берәр сылтау табып кайтып килермен әле синең янга дигән иде. Ләкин нишләп аңа этләр шулай абалап өрәләр икән соң?

Сылу-кыз белән Мамакның өе дүрт өйле авылның көнчыгыш ягында, иң кырыйда иде. Көнбатыштан исә, Кече тау итәге буйлап, аягына чаңгы таккан ниндидер карачкы килеп ята. Ул карачкы соңга калган берәр аучы булырга тиеш сыман. Ерактан аның кемлеген аерырлык түгел, шулай да Мамак түгел. Мамакның йөрүе бөтенләй башка – Сылу-кыз аны ерактан ук танып алыр иде.

Яшь хатынга кинәт салкын, күңелсез булып китте. Алдануы өчен үкенү сыман бер тойгы белән ул кире борылды, теләр-теләмәс кенә өенә керде, теләр-теләмәс кенә чишенеп, яңадан учак белән казан тирәсендә булаша башлады. Ләкин бер кузгалган күңеле тиз генә тынычланмады. Аның хәзер бернәрсәгә дә кулы бармады. Элеккечә бирелеп, иркенләп эшләргә, уйларга-хыял-

PRESSA

ланырга һәм шул рәвешчә үз-үзеңне юатырга әлеге теге килеп яткан ят аучы комачаулый шикелле тоелды. Мамак булмагач, кем булыр икән соң ул? Кайсы авылдан, нишләп йөри? Мамакларны очратмады микән таулар арасында?

Әллә, бернәрсәгә карамыйча, китеп барыргамы хәзер үк алар янына? Юлны белә, урман-тауларны белә, чаңгыда йөри белә. Кайчан барып җитә алыр иде икән ул анда? Төн урталарындамы? Ләкин ул бит анда үзе генә түгел! Алар анда күп. Шуңа да алмадылар бит аны үзләре белән.

Сылу-кыз казандагы су кайнап чыкканчы гына көтте дә кабаланып өстенә киенә башлады. Күн савыттагы түгәрәк җиз көзгесен алып, ут каршысында үзенең бик нык кечерәйтелгән шәүләсенә карады, битенкашын сыйпаштырды, чәчләрен төзәткәләде. Кем генә булса да, ул ят кешене күрергә кирәк иде.

Уртадагы калкурак өйгә таба ул тар сукмактан кызу-кызу атлап барды. Ул туп-туры каенатасы өенә юнәлде.

Эт өргән тавышны, күрәсең, авылдагыларның барысы да ишетеп алганнар иде инде – килүчене каршыларга дип, барлык өйләрдән бала-чага, хатын-кыз чыккан иде. Таягына таянып, Кондыз карт та килүчене көтеп тора иде. Кондыз карт, сукмактан килгән Сылу-кызның аяк тавышларын ишетеп, артына борылып карады.

– Таныйсыңмы, килен, кем соң бу? – диде ул, яшь килененә эндәшеп.

– Юк, танымыйм, ата, – диде Сылу-кыз, әкрен генә кыймылдаучы карачкыдан күзен алмыйча.

– Барыгыз әле этләрне чакырып алыгыз, – диде Кондыз карт аяк астында уралган малай-шалайга.

Малайларның тавышын ишетеп, этләр тагын да ярсыбрак өрергә тотындылар. Шулай да аларның ярсуы озакка бармады – кинәт алар авыл ягына борылдылар һәм, малайлар белән узыша-узыша, бата-чума, тау башындагы кешеләр янына ашыктылар. Иңбашларына, бил каешына төлке, тиен, ас тиреләре аскан аучы да, чаңгылы аякларын кар өстеннән авыр гына шудырып, озакламый тигез җир өстенә килеп менде һәм өйләр янындагы кешеләргә якынлаша башлады.

Сылу-кызның йөрәге кинәт тынычсызланып тибәргә тотынды, аяк буыннары хәлсезләнеп калды. Килүче кешене ул, ниһаять, танып алды. Бу – теге Йәрмәк улы Камаш иде.

Ник килгән ул монда? Ялгышып, адашып килгәнме, әллә туры атап, белеп килгәнме?

Камаш аучы сукмакка килеп җитте дә туктап калды, аягындагы чаңгыларын салып кулына тотты. Сукмак туры Кондыз карт өенә алып килә иде. Үзәктәге өйгә берничә адым кала аучы тагын туктады, чаңгыларын карга батырды, ук-җәя савытларын, билендәге кынысын алып, чаңгы янына куйды. Шул рәвешчә җиңеләеп калгач, төлке койрыкларын кар өстеннән өстерәтеп, билендәге вак тиреләрен селкеткәләп, кешеләргә якынрак килде.

– Илегез имин булсын, ата, – диде ул Кондыз картка эндәшеп.

– Түрдән уз, улым, – диде Кондыз карт, арыган, талчыккан ят аучыны караштырып.

– Тузбашларның Камаш аучы мин, – диде килүче кеше.

– Алай икән, – диде Кондыз карт.

Тузбашларның барысын да ул бик үк белми иде, аннан да бигрәк, музлы буларак, белергә дә теләми иде.

– Бу тирәдә безнең тузбашларның ау җирләре. Монда төлке, тиен күп була, – дип сөйләнде Камаш аучы, Кондыз картның уйларын сизенгәндәй. – Монда элек авыл юк иде. Каяле, күрим әле, кемнәр икән, дидем дә... Ерактан өегезне, төтенегезне күреп килдем, ата.

– Без инде ул монда... кош очып җитмәстәй җирдә, – диде Кондыз карт. – Арыгансыңдыр. Әйдә, өйгә керик.

– Арыдым, – диде кунак, телен көчкә әйләндереп. – Кичә иртән иртүк чыкканыем. Шуннан бирле менә аяк өстендә.

Авыл агасы Кондыз алыпның киез өе башка өйләргә караганда биегрәк тә, иркенрәк тә иде. Шулай да берьюлы биш-алты кеше килеп кергәч, өй эчендә басып торыр урын да калмады. Өйдә иң элек кунакка чишенергә булыштылар, аннары учакка утын өстәделәр. Учакта кечкенә кара чүлмәктә тары боткасы пешә иде. Чүлмәкне учак читенәрәк күчереп, аның янына уртага зур тимер казан астылар, казанга су, ит салдылар, казан өстенә түгәрәк җиз капкач каплап куйдылар.

Кондыз карт, өстен-башын чишенеп, түргә, калку урынга утырды. Кунакны ул үзе янына утыртты. Картның киленнәре, кызлар, малай-шалайлар идәнгә, ишек тирәсенәрәк елыштылар. Барысы да кызыксынып ят аучыны күзәтте. Озынча зур башлы, зур иякле һәм эчкә баткан төссез күзле җирән бер кеше иде ул. Аучы да ара-тирә өйдәгеләргә күз йөртеп алды. Сылукызны ул тышта өй янында ук күреп, танып алган иде. Ләкин, таныса да, бернинди сөенү дә, гаҗәпләнү дә сиздермәде. Әйтерсең ул аны күрмәде дә, күрсә дә, әйтерсең аның аңа бөтенләй исе дә китмәде.

Казанда ит пешкәнче дип, капкалап торырга кунак алдына кипкән эремчек китереп куйдылар. Аннары һәркемгә әз-әзләп ботка бүлеп бирделәр. Ачыккан аучы кыстатып тормады – нәрсә китерсәләр, шуны ялтыратып кына куйды. Ашаганда ул үзәндәге хәлләр турында сөйләде. Үзәнгә яңадан Туман тархан килүен ишетеп, өйдәгеләрнең шундук колаклары үрә торды. Ашау-эчү, хәтта тын алу да кинәт туктап калгандай булды. Бу өйдә сөннәр һәм Туман тархан турында, үзән турында тыныч кына тыңлый алган беркем дә юк иде. Алар өчен «сөн», «тархан» иң әшәке каргыш сүзләре белән бер иде. Кунакка сорау да бирмәделәр, кайгыру, борчылу да белдермәделәр. Кондыз карт бары тик сирәк сакал-мыекларын сыпыргалап алды да әледән-әле Алланы, изге ияләрне исенә төшерде.

Җылынгач, ашап туйгач, кунакның йөзе кызарып, җанланып китте. Шул ук вакытта бик тирәнгә

яшеренгән күзләре кысылып, сирәк каш астында күмелеп калды. Бер-ике мәртәбә ул бөтенесе алдында, йокысына баш була алмыйча, калгып-калгып алды.

Кондыз карт хатын-кыз ягына карап алды да тамак кырып куйды.

– Минем бер киленем Тузбаштан, синең ырудашың, – диде ул кунакка.

– Беләм, – диде Камаш аучы.

– Килен! – диде Кондыз, Сылу-кызга эндәшеп.

– Әү, ата? – диде Сылу-кыз, оялчан гына каенатасы ягына борылып.

– Өең иркен, үзең яшь – ырудашың синдә кунар, – диде каената.

– Ярар, ата, – диде кече килен, учактагы ялкындай кызарынып.

...Кондыз авылында картның үзеннән башка ир затыннан беркем юк иде. Барлык ирләр – картның өйләнгән уллары, бер кияве, бер карасы моннан бер ай чамасы элек үк инде көтүләрне түбәнгә – ерактагы кышлауга алып киткәннәр иде. Ул ерактагы көтүлекләр, дөресрәге, Язулы кая үзәне дип аталган җир чынлыкта аларның үз биләмәләре иде. Элек Күксай үзәнендә яшәгәндә алар көтүләрен һәр елны шунда кышлаталар иде. Олы тау белән Кече тау арасына күченеп килгәннән соң бер-ике елны алар Язулы кая үзәненә бара алмадылар. Ни өчен дигәндә, Язулы кая Күксайга якын иде һәм анда үзән ягыннан җиңел генә килеп тә була иде. Шулай булгач, тархан кешеләренең дә анда бернинди тоткарлыксыз килеп чыгулары ихтимал иде. Караштырып, күзәткәләп йөри торгач, кондызлар анда сөннәрнең килмәвен аңлап алдылар.

Быел көз алар тәвәккәлләргә булдылар. Язулы каяга кадәр булган урман-тауларны яңадан бер карап-тикшереп чыктылар да булган барлык көтүләрен түбәнгә таба куалап алып киттеләр. Сылу-кызның яшь ире Мамак та, каенагалары да менә шунда булырга тиешләр иде. Камаш бу турыда белеп килгәнме, әллә чыннан да белмичә, ялгыш кына килеп чыкканмы?

Караңгыда ашыгып үз өенә таба атлаганда яшь хатынның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Ырудашы белән бу көтелмәгән очрашуны ул нәрсәгә юрарга да белмәде. Хәзер аның нишләптер зиһене томаланды, бер дә юктан тәне, аяк-куллары авыраеп калды. Үз артыннан күләгәдәй тавыш-тынсыз атлап килгән ирнең бернинди яманлык эшләмәячәген ул яхшы белде. Шул ук вакытта күңеленең бер кырыенда ырудашы Камаштан шикләнү, хәтта курку сыман бер тойгы саклануын да танымыйча булдыра алмады. Юк, үзе өчен курыкмады, ерактагы ире өчен курыкты ул. Әгәр бу Камаш былтыр Аю-Мамак белән ярышмаган булса, әгәр дә ул җиңелмәгән булса, күңелендә, ихтимал, бернинди икеләнү-шикләнү дә булмас иде. Җиңелгән кеше көнчел һәм мәкерле була бит!

Өенә кайтып кергәч ул, гадәтенчә, учагындагы күзләрны әвеш-түеш китерде, утын өстәде дә өстен-башын чишенде. Ләкин аңа никтер салкын тоелды. «Өй суынган» дип уйлады ул, дер-дер калтыранып.

Кунак, тоткарланып, беразга тышта калды. Йола кушканча, ул чаңгыларын янә дә карга бастырып куйды; барлык коралларын, энә, без ише нәрсәләре салынган күн янчыгын шулай ук чаңгы янына ташлады. Ул бары тиреләрен генә үзе белән алды. Шуннан соң ишек янына килде, киез ишекнең бер кырыен калкыткандай итеп, тамак кырды.

– Кем бар анда? – дип кычкырды Сылу-кыз эчтән, ишек янына килеп, усал итеп. – Ирем өйдә юк, йөрмәгез төн уртасында кеше борчып!

– Бу мин, аучы. Төнгә калдым. Артымнан аю-бүре куа килә, – диде тыштагы кунак.

– Кайсы авылдан, кайсы ырудан син? – диде Сылу-кыз ягымлырак тавыш белән.

– Тузбаштан, Йәрмәкнен уртанчы улы мин, – диде аучы.

– Ник аны башта ук әйтмәдең?! Мин дә Тузбаштан. Без туганнар икән ич! – диде Сылу-кыз, ишеген ачып.

Урталай бөгелеп, тәбәнәк ишектән аучы килеп керде. Килеп керде дә билен турайтты һәм, уенын-чынын бергә кушып, куанып, яшь хатынны кочагына алды...

– Туганым! Түкәнәгем! – диде ул, Ут анасы ишетсен өчен юри кычкырып.

Шуннан соң ул бер төлке тиресеннән өзелергә генә торган туң май кисәген куптарып алды да, иелеп, дога сүзләре әйтеп, учакка салды.

– Изгелегеннән ташлама, Ут-ана! – диде учактагы утка эндәшеп.

Шул сүзләрне әйтеп, шул эшләрне башкаргач, ул үз өенә, үз хатыны янына кайткандай, ашыкмыйча гына чишенә башлады. Сылу-кыз, ирен каршылаган сыман, аның киемнәрен салышты, тиреләрен ипләп кенә бер читкә алып куя торды. Өстен-башын чишендергәч, ул аны түргә, калку урынга утыртты. Шуннан соң ул кабаланып һәм никтер ашыгып ашарга-эчәргә әзерли башлады. Кунакка ул пешкән ит, шулпа җылытып бирде.

– Менә кайда торасың икән син! – диде кунак, ашаган-эчкән арада беренче мәртәбә ырудашының йөзенә туры карап.

– Шушында торып ятам, – диде Сылу-кыз.

Ул да, очрашканнан соң беренче мәртәбә диярлек, кыюланып һәм якын итеп аучының җил кискән кырыс, таныш йөзенә карап-карап алды.

– Мин сине... эзләп килдем, – диде кинәт төнге аучы ап-ачык итеп.

– Мин төлке түгел! – диде Сылу-кыз һәм җиз кыңгырау чыңы сыман матур, ягымлы тавыш белән көлеп җибәрде.

– Син тоттырмас төлке, – диде кырыс йөзле аучы да, елмайгандай итеп.

– Тоттырмас төлкенең үзе янында утырасың түгелме соң, аучы? – диде Сылу-кыз, шаянланып. – Ник эзлисең мине?

– Онытa алмыйм, – диде кунак.

Яшь хатынның йөзе җитдиләнеп китте.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Балаларны бәхетле булсыннар, матур гаилә корып, үз балаларын тигезлектә үстерсеннәр дисең. Бу – әти-әнинең иң зур теләге. Ләкин тормыш син уйлаганча гына барса икән лә...

Беренче оныгыбыз Мансурның үскәнен без күрә алмадык. Нишлисең, үсеп җиткәч, балалар безгә буйсынмый шул. Үзләрен акыллыга саныйлар, әйткәнеңә колак салучы юк. Яшь гаиләнең таркалуын сабый да туктатып кала алмады. Көтеп алган оныгыбыз белән юлларыбыз аерылды. Аның әтисе – безнең улыбыз. Ул тулы гаиләдә, җитеш тормышта үссен дип, без бар көчебезне бирдек югыйсә. Тормышыбызны бөтен итү өчен колхоз эшеннән кайтып кермәдек. Ә ул... Үзенең газиз баласын язмыш кочагына ташлап калдырды.

Мансур ул вакытта әле башлангыч мәктәптә генә укый иде. Алар – Мәскәүдә, без Татарстанда яшәдек. Оныгыбыз белән кунакка кайткан чакларында бәхетнең җиденче катында булыр идек. Бала баласы балдан татлы, диләр бит. Балакаемның тезләремә башын салып: «Әбием, син минеке генә бул, яме!» дигәннәре әле дә күз алдымда. Тагын кемнеке булыйм ди инде, безнең беренче һәм ул вакытта бердәнбер оныгыбыз ул гына иде бит. Мансур шулкадәр дә апасына – безнең кызыбызга охшаган, хәтта киленебез үзе дә аптырый иде. Шатлыгыбыз, бар куанычыбыз шушы бала булды. Нинди бәхетле вакытлар!

Көннәрдән бер көнне безнең өчен кояш сүнде. Улымның гаиләсе таркалды. Ул вакытта ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. Мансурны уйлап, йөрәгем парә-парә телгәләнде. Еллар узды. Арада еллар гына түгел, меңнән артык чакрымнарга сузылган юллар да иде. Мансурны уйламаган көнем булмагандыр. Ул исемә төшә дә, уйлар өермәсе бөтереп ала: «Нәрсә ашый, тамагы тукмы? Укуы ничек? Безне онытмадымы? Әби-бабасын уйлый микән? Без ул балага нәрсә бирә алдык инде? Бернәрсә дә! Әтисе хәтта алимент түләүдән дә баш тартты...» Еллар узган саен, ара ераклашты гына. Инде янына барсаң да: «Хәзер генә исегезгә төштеммени? Күрәсегез килдеме? Моңарчы кайда булдыгыз?» – дип әйтер сыман. Мансур белән безне нибары кан гына бәйли бит. Киленебезнең аны үз фамилиясенә яздырып, кияүгә чыкканын белдек.

Оныгымны бик күрәсем килеп үзәгем өзелгәндә, җәяүләп чыгып китәрдәй булам да, аннары: «Мәскәүгә барып, каян эзләп тапмакчы буласың?» дип, үз-үземне туктатам. Кызым да: «Аларның күптән үз гаиләләре. Сине күрәселәре килә микән соң? Башың бармы синең, Мәскәү бит ул авыл түгел, анда исем белән генә кешене эзләп табып булмый. Оныт инде син аларны», – ди.

Башым бар ла, сагынудан телгәләнгән йөрәгем дә бар шул. Оныт дип кенә йөрәккә боерып булсачы. Оныгыма ерактан гына бер күз салсам да риза булыр идем. Баламны күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем.

Кызым үзе дә Мәскәүдә яши. Аптыраганнан, йөрәгемнең ничек өзгәләнгәнен аның кызына – оныгыма сөйләдем, Мансурны табарга ярдәм итүен үтендем. Оныгым тырышып карарга вәгъдә бирде.

Бер ел буе түземсезләнеп хәбәр көттем. Ниһаять, оныгым Мансур улымны эзләп тапты! Кызым аның белән очрашу ниятемне хупламаса да, шалтыратып сөйләшергә ризалашты. Шатлыгымнан аяк астымдагы җирне тоймас булдым.

Алар безне кунакка чакырганнар. Шунда ук, җыенып, Мәскәүнең бөтенләй башка очына чыгып киттек. Менә ул улым яшәгән фатир! Ишекне киленем ачты. Аның: «Исәнме, әни!» – дигәнен ишеткәч, йөрәгем тибүдән туктагандай булды.

Безне бик хөрмәтләп каршы алдылар. Күңел бушанганчы сөйләштек тә, кочаклаштык та, елаштык та...

Без беркайчан да аларның тормышына кысылмадык. «Бәлки, дөрес эшләмәгәнбездер? Безнең яктан да гаеп булгандыр, син миңа үпкәләмисеңме?» – дидем киленемә. «Әй әни, үзем хозяин, үзем хуҗа. Синең бер гаебең дә юк. Яшьлегебез белән ясаган ялгышлык. Киләчәкне уйлый белмәгәнбез...» – киленем безне гаепләми иде.

Ул беренче очрашудан соң инде унбиш еллап вакыт үтте. Аллага

шөкер, тормышлары яхшы. Мансур улым инде өйләнде, кызлары үсеп килә. Киленем дә алар белән бергә яши. Бәхетле, тату торалар. Кызымның кызы белән дә Мансур гел аралашып тора. Берсендә киленем: «Әни, кара син нинди бай! Никадәр оныгың бар», – ди.

Инде җаным тыныч. Мансурыбыз өчен, аның белән очрашуыбызга киртә булмаганы, безне кабат үз туганнарыдай кабул иткәне өчен киленемә зур рәхмәт.

Мөнәвәрә ГАЛИЕВА.
Лениногорск районы.

Корбан бәйрәме алдыннан ата-бабаларыбызның каберләренә зиярәт кылып, бер дога укып кайтыйк дип, туган якларга – Кукмара районының Янсыбы авылына юл алдык.

Минем әтием Садрислам Фәхрисламов Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк солдатка алынган. 1 нче Украина фронтының 151 нче укчы дивизия командиры урынбасары, озын сугыш юллары үтеп, 1944 елның 5 мартында батырларча һәлак була. Ул шул җирләрдә ятып кала.

Әтием – чыгышы белән Янсыбы авылыннан. Кайчандыр авыл халкы Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларына һәйкәл дә куйдырган иде. Фамилияләре күрсәтелгән тактадагы 126 солдат арасында әтиебез – майор Садрислам Фәхрисламовның да исеме бар. Авыл уртасындарак урнашкан шушы изге җирне барып күрдек тә, борчуга төштек. Һәйкәлне чүп үлән, кычыткан басып алган. Мин инде чәчәкләр турында әйтмим дә. Ватан өчен, авылдашларының тыныч-матур тормышы өчен кан койган, гомерләрен өзгән ата-бабалары турында онытканнар. Күрәсең, укучы балаларга да патриотик тәрбия тиешенчә бирелми. Югыйсә бер килеп җыештырып китәрләр, һичьюгы ромашкалар гына булса да утыртып, үлгәннәр рухын куандырырлар иде. Һәйкәл янында туп типкән малайлар белән дә сөйләштек. «Җыештырырга, карап торырга кирәк», – дидек. Алар да аңлаган сыман булды. Күңелне авыр уйлар тынгысызлый: җирлек башлыгы ни карый икән? Аның да йөрәге сызланмый микән? Ул бит бу тирәдән көненә ничәмә-ничә мәртәбә уза торгандыр?

Светлана ФӘХРИСЛАМОВА.
Яшел Үзән районы,
Осиново бистәсе.

Бу тирәләргә асфальт юл салыныр дип, беркем дә хәтта хыялланмагандыр да. Җимерелеп беткән агач күперне рәтләсәләр, халык шуңа да риза булыр иде.
Ә монда, күперне генә түгел, юлны да өр-яңадан салып куйдылар.

Элек Олы Мәңгәр белән Иске Кишет арасындагы дүрт-биш чакрым арада шушы басу юлы гына иде. Арча районыныкы да түгел ул, Әтнәнеке дә... Көннәр коры булса, шул тирәдә яшәүчеләрнең тормышын шактый җиңеләйтә торган, кирәкле юл югыйсә – берәр нәрсә булса, 30 чакрымдагы Арчага барганчы, 10 чакрымдагы Әтнәгә барып килүе тизрәк бит. Авыл белән Казан арасы да Әтнә аша кыскарак... Җәй корысында бу юлдан халык өзелмәде. Ләкин яңгыр яуса, яз, көз, кыш аннан йөрерлек булмады. Ә менә быел басу уртасына яңа дамба күтәртеп, асфальт юл түшәгәннәр. Җимерек Әче күпере, күпләрнең әче яшьләре тамган газаплы юл хатирәсе булып, бер читтә торып калган.

Безнең дә аз таммады монда күз яшьләре. Балачагымның шушы юл белән бәйле бер хатирәсен һич тә онытасым юк. Без ул вакытта әни һәм сеңлем белән Әтнәдә яши идек. Язгы ташу кузгалган бер атнада әни авылга – идән астыннан бәрәңге чыгарырга кайтып китте. Безне – ике кызын, аяк асты йөрерлек түгел, дип, өйдә калдырды. Якшәмбе кичке якка кире әйләнеп килергә тиеш булган әни күренмәде. Сеңлем белән башта без аны өйдә көттек. Өйдәге эчпошыргыч тынлыктан, әнисез чакта гына була торган салкыннан качып, ишегалдына чыктык. Ә әни юк та юк. Бик соң, кичке уннар тулганда гына кайтып керде ул. Без аны танымадык. Бөтен киемнәре, сөт, каймак, йомырка – дәү әнинең күчтәнәчләре белән тулган сумкалары, баштанаяк тәмам пычракка буялып беткән. Аягындагы резин итекләренең дә эче тулы ләм. Урындыкка утырды да, безне кочагына кысып, елап җибәрде.

Гомер булмаганны, ул елны басу юлын көздән сукалап калдыралар. Сөрелгән басуның яз көне төбе булмый аның. Сукаланган җиргә килеп керүгә, көне буе кояш күзендә ятып җебегән туфрак әнине суыра башлый. Ике-өч адым атларга да өлгерми, бәгырькәем, юеш туфракка тез тиңентен бата. Кире дә борыла алмый – анда без көтәбез, иртәгә эшкә барасы бар... Сукаланган басуны әни бичарам дүрт аяклап мүкәләп уза. Без бу юлны җәяү мең тапкыр ураганбыздыр.

Олы Мәңгәргә килеп җитсәк, юлны инде узылганга саныйбыз, монда Әтнәгә баручы машина очрамый калмый. Ул көнне әни узгынчы машиналарга кул күтәрергә ояла. Күтәрсә дә, баш-аягы белән пычракка чумган хатынны кем генә утырткан булыр иде икән?

Өйгә килеп кергәндә, дүрт чакрымны мүкәләп, аннары Мәңгәр белән Әтнә арасындагы тугыз чакрымны җәяүләп узган мескенкәемнең тел әйләндерерлек тә хәле калмаган иде.

Яңа юлдан машинада җилдереп кенә авылга кайтканда анда – еллар томаны артындагы караңгы басу түрендә яшәү өчен җан тырмашып мүкәләгән хатын – газиз әнием күз алдыма килде. Ул тормышны ярата иде. Ләкин ялгыз хатынның газаплы көнкүреше аның яшәү көчен бик иртә суырды. Эх, шушы юлларны күрә алмый калды ул.

Лилия ГӘРӘЕВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

КҮБӘЛӘК БУЛЫП ОЧТЫ...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

БАЛА – ҖАНЫҢНЫҢ ҖИРДӘ СИННӘН СОҢ КАЛЫП, КИЛӘЧӘККӘ СИНСЕЗ АТЛАП КИТӘЧӘК БЕР ӨЛЕШЕ УЛ. АНЫҢ СУКМАГЫ ҮЗЕҢНӘН АЛДА ӨЗЕЛҮ – ЯЗМЫШ СЫНАВЫНЫҢ ИҢ АЧЫСЫДЫР...

Кызганыч, тормыш кайчакта бик мәрхәмәтсез дә булып куя. Мондый чакта кайдан көч алырга, ничек яшәргә, ничекләр сынмаска? Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Дания НУРУЛЛИНА – бала югалту кебек үзәк өзгеч фаҗигане үз башыннан кичергән аналарның берсе. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.



Телефоннан үтенечемне ишетүгә, тавышыгыз мизгел эчендә үзгәрде. Кабат барысын да уйдан кичергәнсездер бу көннәрдә...

– Кабат дип... Кызымны уйламаган минутым да, сәгатем дә, көнем дә юк... Кайдан башларга да белмим. Ерактанрак тотыныйм әле... Мин – әти-әнинең сигезенче баласы. Абыйны югалтканда 6 яшьтә генә идем әле, әмма барысын да хәтерлим. Атка салып зиратка алып барганны, мине аның аяк очына утыртып куйганнарын. Без Казанда, Калинин бистәсендә үстек. Ул көнне дә безнең бистә малайлары РТИ заводы читендәге чирәмлектә футбол уйнаган. Кайсыдыр катырак типкән, күрәсең – туплары завод коймасы эченә кереп киткән, һәм минем 16 яшьлек Зөфәр абыем, койма астыннан шуышып, шул тупны алырга кергән. Сакчы, кисәтеп-нитеп тормыйча, туп-туры абыйга ата. Җәйнең яп-якты бер көнендә! Әнинең җирне тырнап елаганы бүгенгедәй күз алдымда. Аны аңлыйм мин хәзер. Ул кичергән хәсрәт инде үземә килде. Әнинең балалары тагын берничәү иде бит, ә минем Айсылуым – бердәнбер...

Әни шуннан соң авырый башлады инде. Ашказанында яман шеш таптылар аның. Җиденче сыйныфка

укырга кергән елым иде. Сентябрь башы. «Әниең начарланды», – дип, мәктәптән чакыртып алдылар. Урам буйлап йөгереп кайттым. «Әни, мин монда», – дип өстенә иелгәч, бите буйлап күз яшьләре тәгәрәп төште, һәм ул соңгы сулышын алды... «Сине көткән икән», диделәр. Илле алтыда гына иде әле әни. Хәсрәтне мин шулай яшьтән татыдым...

Ә Айсылуны бик яратып үстердем! Курчак уйнаган кебек. Кечкенә чагында да ул мине берничек җәфаламады: еламады, көйсезләнмәде. Элек айлар буе гастрольләрдә йөри идек бит – гел янымда булды. Гаилә тормышым барып чыкмады. Айсылуның әтисе – драматург Риза Ишморатның улы Фәрит белән аерылышканда кызыма ике яшь ярым гына иде әле. Икенче тапкыр инде кияүгә чыкмадым... Телевизордан кайчак тапшырулар карыйм: ана белән кыз талаша, фатир бүлешәләр, мал-мөлкәт... Мин андый нәрсәләрне бөтенләй аңламыйм. Без үзебез бер сулыш белән яшәдек. Күз карашы белән аңлашып... Урамда очраткан танышлар: «Сез әни белән кыз кебек түгел, ахирәтләр шикелле», – дияләр иде. Шулкадәр ипле, җайлы иде ул Айсылу. Акыллы иде. Дус кызлары бик күп иде. Гомумән, дуслары күп иде. Әтисенеке кебек... Шулкадәр ярдәмчел булды – бөтен кешегә яхшылык эшләргә тырышты. Кесәсендә бер тиен акчасы булмаганда да, әтисе дә шулай башкаларга ярдәм итәргә җай таба иде. Холкы белән Айсылу әтисенә охшаган иде – ирек яратты, ә эчке дөньясы минеке кебек иде.

Театр баласы булды – монда үсте. «Генеральная уборка» (Әхтәм Зарипов), «Әни килде» (Ш. Хөсәенов) спектакльләрендә малай рольләрен уйнавын күргәч, Марсель Хәкимович аны «Әлдермештән Әлмәндәр»гә алды. Айсылу Әлмәндәр бабайның оныгын – кечкенә Илсурны җиде ел уйнады. Чәче үсеп, аны җилфердәтеп йөрисе килә башлагач: «Әни, парик киеп, малай булып уйнап арыдым», – диде. Марсель Хәкимович аны артистка булырга ничек кенә үгетләмәде! «Әйдә, II курска укырга алам. «Ромео һәм Джульетта»ны куям, сиңа Джульетта ролен бирәм», – диде. Гәүдәсе бик нәфис иде бит Айсылуның. Аны елмаеп кына тыңлый иде дә, өйгә кайткач: «Сәхнәгә беркайчан чыкмыйм!» – дия иде. Артист тормышының бар авырлыгы аның күз алдында булды. Татарстанда без аяк басмаган бер авыл калмагандыр. План үтәдек. Бүгенгеләр моның ни икәнен дә белми, ә безнең чорга шулай туры килде... Гастрольләрдә йөргәндә, Айсылу кич саен сәхнә артында, нинди дә булса әрҗәдә йоклады. Ашарга да юк чаклар күп булды. Авылларга чыкканда, үзебез белән токмач, ярма гына түгел, плиткага кадәр ала идек. Аннан, әйткәнемчә, холкы да иреклерәк иде.
«Мин театрда режиссерга буйсынып яши алмам», – диде. Юк, театрга килмәде ул – сәнгатькә тартылмады. Оныкның да театр ишеген ачып кергәне юк... Шәфкать туташы булырга укыды Айсылу. Әмма хезмәт хакы бик аз иде – Айсылуга китәргә туры килде. Кибеттә эшләде. Соңгы вакытта «Кольцо» сәүдә үзәгендә сувенирлар бүлегендә өлкән сатучы булды.

Кияүгә 19 яшендә үк чыкты. Никах укыттык, туйлар ясадык. Әмма яшәп китә алмадылар, аерылыштылар. Айнурны без 5 яшьлек чагыннан икәү үстердек. Оныгыма хәзер инде 24 яшь. «Шундый рәхәт яшибез, әни, әйеме. Безнең өйдә ял йорты кебек», – дия иде Айсылу. Байлыкка кызыкмадык, чисталык, пөхтәлек булсын дип тырыштык. Матур киенеп эшкә чыгып китә, кайтып керә иде. Ирекен кысмадым, шәхси тормышына кысылмадым. Өйдә булсам, ашарга әзерләп калдырам, мин өлгермәгәндә, ул пешерә.

Ничек ышанырга кирәк аның юклыгына?!

Инде барысын икегә бүлгән ул көн...

– Ул көнне бик иртә тордык. Мирный бистәсендә яшәүче бертуган абыем вафат булган иде – аны соңгы юлга озатырга киттек. Эштән бер-ике сәгатькә генә сорап киткән иде – Айсылу зиратка барып тормады. «Мине машина белән Алинә илтеп куя», – диде. Апаның кызы белән саубуллашканда: «Кемгә күпме яшәргә калганын беребез дә белми», – дигән. Бәлки күңеле нидер сизгәндер, минем үземдә андый нәрсә булмады. Ялгыш бер шик, төш тә кермәде.

Җомга көн иде. Алда – ике көн ял. Кич эштән кайтты да: «Кызлар белән очрашабыз әле», – дип, чәй эчкәч чыгып китте. Шуның белән шул... Айнур аны ул көнне күрми дә калды. Миңа иртәнге биштә бер күршем шалтыратты. «Дания апа, бик авыр хәбәр, әмма әйтмичә булмый...» – диде. Бәрелгәч, Айсылуның сумкасыннан телефоны төшкән. Ул соңгы сөйләшкән номерларны җыйганнар. Шуларның берсе күршебез булган.

Кызлар белән утырганнар алар, аннан бер танышы мотоциклда йөрергә чакырган. Бәлки, ошатып йөргән кешесе булгандыр, белмим... Каршыларына машина килеп чыккан. Ул егет тә әнисенең 40 яшьтән соң гына тапкан бердәнбер улы булган, диделәр.

Айсылуның бик нык башы бәрелгән, бөтен эчке әгъзалары өзелгән. Иреннәрен бик каты кыскан иде – авыртудандыр... Барысы да бик тиз булган. Күбәләк кебек очып кына киткән инде ул... Җомга көнне абыйны соңгы юлга озаттык, якшәмбе – Айсылуны... 39 яше яңа тулып, нибары 14 көн узган иде. Кызымны җирләгәннән соң, өч көннән – 23 августта исә миңа 65 яшь тулды. Юк, кинода да болай булмыйдыр...

Зираттан кайткач, апаның кызы: «Карале, Айсылу сиңа нәрсә калдырган», – дип, аның минем юбилейга әзерләгән бүләген китереп тоттырды. Суыткыч өстенә куйган булган икән, күрмәгәнмен... Кул сәгате алган. Сәгать бүләк итү – аерылышуга, диләр бит, белмәгәндер инде, балакаем... (Кызыма исемне «Миркәй белән Айсылу» драмасында Айсылу ролен уйнагач кушкан идем. Ә спектакльдә Айсылу ахырда суга батып үлә. Мәетләрнең исемен балага кушарга ярамый дип, соңыннан кемдер әйтте. Мин дә бу хакта белмәдем шул...) Баштарак тагып йөрдем мин ул сәгатьне, хәзер

кимим – кагыла алмыйм. Открыткасын саклыйм. «Әнием, ты самая крутая мама в мире! Ты самая красивая! Самая молодая! Самая добрая! Самая любимая! Самая мудрая! Самая зажигательная! Ты моя, Әнием!» – дип язган.

Каберенә үзем кереп ятарлык булдым инде... Аяк астымда әйтерсең лә җир убылды. Гүя мин упкынга төшеп киттем. Шулкадәр кинәт булды бит. Бер көн эчендә бар нәрсәм җимерелде. Тормышның яме, кызыгы калмады... Ул көзне мин үзем машина астына кермәкче булдым. Репетициягә барганда, юлларны чыкканда махсус туктап кала идем. Бәрдергәннәрен көттем... Моңа әзер идем... Яшисем килмәде... Бу хакта бер кешегә дә әйтмәдем, әмма шундый уйлар белән йөрдем. Югалтыр нәрсәм юк иде... Айнур берүзе кала дип кенә тукталдым. Әнисе үлгәндә аңа 17 яшь иде. Иртә килгән хәсрәт аны да үзгәртте – кырысланды. Читтән торып югары белем алды, инде эшләп йөри.

Шулкадәр сагынам Айсылуны! Соңгы елларда җәй саен чит илләргә йөрим. Гел берүзем... Әниле-кызлы сәяхәт итүчеләрне күрсәм, үзәгем өзелә. «Без дә шулай икәү йөрер идек бит», – дим. Ул Төркияне бик яратты. Җәйгә икешәр тапкыр бара иде. Шул җәйне мине дә беренче тапкыр Төркиягә ялга җибәрде.

Баштагы өч елда төшемә бик еш керде. Яныма килми, гел каяндыр читтән, йә тәрәзә аша гына карап тора, якыная башласам – югала... Төшләргә керми инде хәзер. Яра булып кына яши...

Җанымны суырып алдылар да, шулай йөрим менә хәзер...

Киткән артыннан китә алмыйсың, диләр... Ничек тә яшәргә кирәк...

– Нәрсә белән юаныргга, ничек яшәргә? Әйтүе кыен... Әзер рецепты юк инде аның.

Ул елны Камал театры Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» әсәрен сәхнәгә куйды. Миңа Мөхлисә Бубый ролен биргәннәр иде. Айсылуны югалтканнан соң, театрның директоры Шамил Закиров белән режиссерыбыз Фәрит Бикчәнтәев өйгә килделәр. «Мин уйнамыйм Мөхлисәне, кирәкми, башка берәүгә тапшырыгыз», – дим. Ә алар: «Юк, сездән башка беркем булдыра алмый», – диделәр. Кызымның кырыгын уздыргач кына ризалаштым, репетицияләргә йөри башладым. Спектакльне декабрьдә генә чыгардык. Аңарчы көчем булмады. Барысы да җаема тордылар – әзер булганымны көттеләр. Авыр иде миңа уйнавы, роле дә авыр иде. Гомумән, барысы да авыр иде...

Хәсрәт килгәч, кеше үз-үзенә йомыла, диләр. Йомылу да түгел ул... Мин үзем бу хәлгә бик озак ышана алмадым. Йокламыйча гел аны көттем. Теләсә нинди тавышка сикереп тора идем. Ишектә кыңгырау шалтыраган саен Айсылу кайтты дип уйладым. Күңелем гел китек инде... Берничек тә үсми. Ярый әле театрда эшлим, ярый әле коллектив әйбәт. Сәхнәдә уйнау, халык белән очрашу азрак тынычландыра. Онытылу түгел бу, хәсрәтне аз гына читкә куеп тору гына. Өйгә кайткач, тагын барысы да искә төшә. Сөйләгән сүзләре, кызыклары...

Кем белән очрашсаң да: «Сабыр бул», – дип киңәш бирә. Билгеле, сабыр итәсең, кычкырып урамда йөри алмыйсың бит. Тик ул сабырлыкны гына кайдан алырга? Сабырлык бирә торган юанычларны мондый фаҗига аша узган һәркем үзенә үзе таба торгандыр.

Белгән догаларыңны укы, җиңелрәк булыр, диделәр. Җомга саен «Ясин», «Табәрәк»не, башка сүрәләрне укып утырам, озак итеп багышлыйм. Азрак тынычланам...

Тагын... Тагын – гыйбрәтләр алам. Мин бит үзем генә түгел, мондый хәсрәтле кешеләр байтак. Һәрберсен күңелемнән уйлап, барлап чыгам. Шулай юанам дип әйтсәм, дөрес булмас. Юк, юану түгел бу, әмма сүзен белмим... Айсылу 2011 елны вафат булды. «Булгария» теплоходы баткан ел бу. Елга портына барып, чәчәкләр дә куеп кайткан иде әле ул, елап шешенеп беткән иде. Нечкә күңелле, хисле бала иде... Балалары су төбенә киткән әниләргә әллә миннән җиңелрәкме?! Шул ук елны «Локомотив» хоккейчылары һәлак булды. Әти-әниләренә соңгы тапкыр карап калырга гәүдәләре дә булмады... Илбашыбызга нинди кайгы килде әнә... Кичен өйгә кайтып ишекне ачып кергәч, әллә ул улы хакында уйламыймы?!

Быел җәй Кипрдан кайттым да, елдагыча туган көне алдыннан Айсылуның каберенә киттем. Чәчәкләр алып бардым, юдым, җыйдым... Айсылудан ерак түгел Сибгат ага Хәким, аның хатыны Мөршидә апа каберләре. Оныклары Камилә дә шунда. 2011 елның октябрь башында аварияга очрады ул. Мин аны гел карап, жәлләп узам. Бигрәк яшьли китте. Бу юлы кабере бер хатын җыештырып ята иде. Туктап исәнләштем. «Әнисе зиратка килеп йөри алмый, мин аның апасы», – ди. «Камилә кебек кеше башка юк», – дип егете дә һаман өйләнмәгән икән. Рафаэльләргә сөяргә онык та калмады... Айсылу, ичмасам, күпмедер яшәргә өлгерде: теләгән җиренә барды, күңеле төшкән кеше белән очрашты, ана булу бәхетен, бала тәмен татыды...

Кайчак уянып китәм дә, янымда Айсылуның сулышын тоям. Янымда йоклаган кебек... Бик юксынам! Аны аңлатырлык сүзләр дә тапмыйм.

...«Әнием, син кайда әле, кайтасыңмы?» – дип шалтырата иде ул миңа. «Репетициядән чыктым, кызым, юлда», – дим. «Алайса хәзер чәй куям!» Чәй куя да, кухня тәрәзәсеннән карап, мине көтә – күргәч кул болгый... Фатирыбыз икенче катта гына безнең. Ишегалдына кайтып җиткән саен, үзем дә сизмичә, тәрәзәгә күтәрелеп карыйм. Һаман да... Сувенирлар бүлегендә эшләгәндә алган кызыл йөрәкне тәрәз төбендәге вазага үзе утыртып куйган иде. Ул йөрәк һаман шунда. Айсылу йөрәге кебек...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

ИР БЕЛӘН ХАТЫН КӨНДӘШЛЕГЕ

ЯКИ БЕР АРБАГА ҖИГЕЛГӘН ИКЕ АККОШ ТУРЫНДА

Римзил ВӘЛИЕВ



Иҗтимагый-сәяси тормышта, эшкуарлыкта, иҗатта уңышка ирешкән дәрәҗәле хатын-кызларның ирләре нинди булырга тиеш? Кем кемгә буйсына, ярдәм итә? Бу бик четерекле мәсьәлә. Аның кагыйдәсе дә, үрнәк бер моделе дә юк. Эшкә чумган, боерык бирергә күнеккән хатын белән яшәүче ирләр кызганыч хәлдә. Минемчә, нормаль ир-ат хатыныннан өстенрәк, көчлерәк булырга ярата. Буйсынып яшәргә теләүчеләр сирәктер ул. Шуңа күрә дә күп очракта чибәр, булдыклы, карьера ясарга омтылган ханымнарга лаеклы пар табылмый, гаилә корсалар да, озак яши алмыйлар. Кайберәүләр гаиләдә ире яки хатыны «күтәрелеп» киткәч тә, зирәклек күрсәтеп, дус булып калалар, бергәләп дөнья йөген тарталар. Хәлбуки әлеге «тигезлекне» саклау бик читен булса да...

Мөгаен, безнең гаилә шундыйларга охшагандыр. Кем алдында юл ачыла, шул алгарак үтә. Кайчак ир кешегә капка ачык, хатын-кыз да уңышлы сукмактан атларга мөмкин. Бергәләп дөнья көтәргә дип сөйләшеп, ЗАГСта имзалар куеп, йорт-фатир төзеп, уртак балалар үстергәч, кемнең депутат, кемнең директор булуы мөһим түгел. Бер өйдән эшкә чыгып китәсе, кичен җимеше дә, нужасы да уртак йортка кайтасы. Шулай да бер дустым искә төшә. Бик талантлы, билгеле шәхеснең хатыны да популярлашып китте. Килеп чыккан проблемаларны хәл итү өчен, иреннән узып, кирәкле кешеләр белән барып сөйләшеп йөри башлагач, аның абруе төште. Өйдә көнчелек түгел, көндәшлек сизелә башлады. Дустым бик гарьләнде, үртәлде. Алар аерылыштылар.


Хатын-кызның абруйлы булуына түзәргә туры килә. Акыл, гыйлем буенча иҗатта, профессиональлектә дә хатыннан калышмаска, хәтта аны узып та китәргә мөмкин ич. Беркем тыймый. Күпчелек горур ирләр үзләренең «әтәч» булуын башка урында исбатлый башлыйлар. Безнең гаиләне уртак һөнәр – журналистика нигыткандыр, бәлки. Мине «Зилә Вәлиеваның ире» дип таныштыручыларны: «Киресенчә, ул минем хатын», – дип төзәтә идем. Өй эчендә хакимият бүлү, кемнең өстенрәк булуын даулау ахмаклар, тәрбиясезләр гамәле ул. Хатын-кыз белән ир-ат бервакытта да тигез була алмый. Чөнки аларның табигатьләре, миссиясе аерым. Гүзәл затларга авыррак, аңа бала табасы, кечкенәдән үстерәсе, йортны ямьлисе бар. Эшкә барганда матур итеп киенү-бизәнү дә күпме вакытларын ала. Аның каравы, хатын-кызлар (нигездә) тырышрак була, ауга, балыкка, футбол карарга чыгып китмиләр, эшлиләр дә эшлиләр. Алар таләпчәнрәк. Шулай да президиумнарда, киңәшмәләрдә, гадәттә, костюм-галстуклы ирләр күбрәк утыра. Мин моңа бик аптырыйм. Кайчак 8 Март бәйрәмендә дә ирләр – сәхнәдә, ә аллы-гөлле күлмәк кигән ханымнар – залда. Җитәкче кәнәфиендә утырган ун иргә бер-ике түрә хатын туры килә. Күп очракта аларны эш өчен түгел, тирәлекне бизәү өчен сайлыйлар.

Дөрес, мин феминисткаларны, ирдәүкәләрне яратмыйм. Кайсы ир-ат аларны үз итә икән? Яшьрәк чакта Мәскәүдә комсомол Үзәк Комитеты секретаренең (зур вазыйфа!) кабинетына кергәч, ярдәмчесенең: «Ирегез килде, керсенме?» – дип хәбәр салганын ишетеп калдым. Теге «секретарь ЦК», (соңрак та зур урыннарда эшләде әле ул), чыжылдаган тавыш белән: «Көтеп торсын», – дигәч, сискәнеп киттем. Кайда гына эшләсә дә, күпме акча алып кайтса да, хатын-кыз тыйнак, нәзакәтле булып калырга тиеш. Ирне хөрмәт итмәгән хатын белән кем яшәсен?! Яшәсәләр дә, юньле тормыш түгел инде ул.

Хәтерлисезме, Фәридә Кудашева «Һаваларда оча ике аккош...» дип җырлый иде? Ул аккошларның берсе ир затыннандыр дип уйлыйм. Тормыш ул аккошлар очышы түгел, ә бергәләп уртак йөкне тарту. Һәркем үз хәленнән килгәнчә өлешен кертә. Һаваларда очкан ике аккошның каурыйлары җиргә коела бит! Әти белән әнинең хакимлек бүлешеп тарткалашуы аркасында бер гаепсез балалар ярым ятим үсә. Ир кеше ирлеген даулый, аңа үзенең сәләтен эшкә җигәргә, ачылырга кирәк. Кайвакыт чибәр, башбирмәс хатын үзен өстен куя, адым саен иренең җитешсезлекләренә дәгъвасын белдерә. Акчаны көрәп алып кайта алмаган, күбрәк телевизор алдында, диванда яткан ирне дә мактап булмый. Җәмгыятьтән читләшкән, хуҗалык эшләренә баткан хатынны да... Акыллы хатын үз иренә дә үсәргә булышырга тиештер дип уйлыйм. Гаиләдәге рухи тигезлек, гаделлек, шәфкатьле мөнәсәбәт бигрәк тә балаларга кирәк. Шулай булмаса, аларны киләчәктә катлаулы язмыш көтә.

Кыскасы, бер-берсенә ихтирам саклый алмаган парларның карьерасы һич куандырмый мине. Бергәләп күтәрелегез. Балаларыгызга да, үзегезгә дә бергә яшәү күңеллерәк булыр, дияр идем мин яшьләргә. Гаиләдә дәрәҗәләр түгел, тигезлек, хөрмәт хакимлек итәргә тиеш.

PRESSA



МИН КУРЧАК ТҮГЕЛ!



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

КАЙЧАК ГАИЛӘ ТАРКАЛАУГА АКЧАСЫЗЛЫК, КӨНКҮРЕШ МӘШӘКАТЬЛӘРЕ, ХӘТТА ХЫЯНӘТ ТӘ СӘБӘП БУЛА АЛМЫЙ. Ә ИКЕ АРАДАГЫ КҮПЕРНЕ ХӨРМӘТ БУЛМАУ ҖИМЕРӘ. БЕРГӘ ЯШИ БАШЛАГАЧ, АШАРГА ПЕШЕРҮДӘН БИТӘР, ИҢ ЭЛЕК ИР ИХТИРАМЫН ЯУЛАРГА КИРӘК ИКӘН...

Тормышта рәхмәтле була белмәү һәр кирпечен тир түгеп өйгән гаилә сараен җимерә. Акыл иясе Сөләйман патша: «Игелекле хатынның бәясе энҗеләрдән кыйммәт. Аның тугры йөрәгенә ышанган ир табышсыз калмас, зур үрләр яулар. Җанын фида кылырга әзер хатынына ире дә баш ияр», – дигән. Тик бу сүзләр кайчак тормышта асылын югалта. Сәбәбе нәрсәдә: ирләр юньсезме, әллә үзен ире белән бербөтен итеп тоеп, шәхесен югалткан хатыннармы?!

Алар – көнләшерлек пар. Ул баһадир кебек, хатыны аның янында курчакны хәтерләтә: кечкенә генә, чибәр һәм һәрвакыт матур итеп киенгән. Тормыш рәвешләре дә күп әниләрнең кызларына теләгән теләге: ир таба, өйгә алып кайта, хатын гаилә учагын саклый, балалар тәрбияли. Бәхет өчен тагын нәрсә кирәк? Кирәк икән шул. Моны Наилә гаиләдә 15 ел яшәгәннән соң гына аңлый.

Вилдан белән алар студент елларында танышалар. Яшь чак – җүләр чак, дип тикмәгә әйтмәгәннәр. Наиләне аның бик «текә» егет булуы җәлеп итә. Эше юк югын, акчасы булмаса да, машинасы бар әнә. Ә машинада ничек итеп җилдерә ул! Казан егетенең үз артыннан йөрүе дә ерак авылдан килгән кыз күңелен эретми калмый, билгеле. «Мин аны бөтен барлыгым белән яраттым», – ди Наилә.

Дәрәҗәле урында эшләгән әти-әнисе улларының хәерче кызны өйгә алып кайтуын кабул итә алмыйлар. Тик башбаштак малайлары бәлки акылга утырыр дигән өмет белән, теш кысып, риза булалар. Чынлап та, өйләнгәч эшләргә кирәк дигән уй керә гаилә башлыгына. Суган ташырга йөкче булып урнаша. Чөнки тәҗрибәсе юк, гамьсез улын янына алып, әтисе дә кеше күлкесенә калырга теләми. Наилә исә институт дипломын алып кайта да шкафка тыгып куя. Эшлисе килми аның. Бар хыялы: балалар табып, гаилә җылысын саклап яшәү.

Беренче сабыйларын алып кайтканда Вилдан да әтисе янына урнашкан була. Бала бит, төпләнеп киткәнен күргәч, проектлау берләшмәсенә гади хезмәткәр итеп алган улын карьера баскычы буенча күтәрә башлый ата. Хирыслыгы да бар, җитмәсә. Акча, хакимлек тәмен шунда татый Вилдан. Кызларына 5 яшь тулгач, бәхетне түгәрәкләп, малай алып кайталар, зур фатирга күчәләр. Бу вакытта инде Вилдан җитәкче кәнәфиенә утыра. Наилә исә балалары белән кайнаша. Үзен дә онытмый: фитнес заллар, матурлык салоннары юлына тузан да төшерми. Ирем янәшәсендә һәрвакыт матур булырга тиешмен дип уйлый ул.

– Дуслары мактап туя алмый иде мине. Өйдә бар яктан уңган, чибәр хатының көтеп утырганда эшләрең гөрләп бара, әлбәттә, диләр иде. Ир-ат дәрәҗәгә ирешсен өчен, иң элек тылы яхшы булырга тиеш дип саныйм. Авыр эш көненнән соң кайтып ял итә алсын өчен бөтен шартларны тудырдым. Авызына гына карап тордым. Яраткан кешеңә яхшылык кына эшлисе килеп тора бит ул.

Улларына 3 яшь тулгач та аны балалар бакчасына бирергә ашыкмый. Әти кеше илтергә кушса да, баласын чит-ятлар кулына тапшырасы килми. Иреннән кимегән назларны улыннан алырга тырыша ул. Вилдан җаваплы эштә, арыйдыр, дип юата үзен. Биш улы булган иптәш кызы да сабыйларын үзе генә тәрбияләргә теләвен әйтә. Икәүләп балалар үзәге ачарга ниятлиләр. Белгечлеге буенча да балалар психологы бит әле ул, җитмәсә. Ире дә куәтләп тора. Бизнес ачарга акча бирә.

Үзәк турында тирә-юньдә дә белеп алалар. Балалар күп килә, ата-аналар рәхмәтле. Наилә, ниһаять, үзе акча эшли. Тик ул канәгатьлек хисе тапмый. Гаиләм дигән уй аңа һич тынгы бирми. Үзен хыянәтче итеп тоя башлый. Бөтен көчен якыннарына сарыф итә алмавына эче поша. Эшне дә, гаиләне дә бергә алып бару мөмкин түгел дип саный. Аның бит хыялы бизнесвумен булу түгел, күп балалы матур бер ояда яшәү теләге иде. Дус кызлары да итәк тулы сабыйлары белән көнләштерә. Өченче баламны табам да өйдә генә утырам, ял итәм дип уйлый ул.

Ашарына пешереп, күлмәкчалбарын юып кына ирнең хөрмәтен казанып булмый икән бит!

– Үземә тиешле мәхәббәтне туачак баламнан алырга теләдем. Улым итәктән төште. Ә минем кемнедер карау теләге көчле. Ирем белән аралар суынганнан-суына бара. Бала хакында ишеткәч, аның да күзләрендә очкын күрдем. Бәлки иремне үземә бәйләргә, назларын кире кайтарырга тырышканмындыр. Авырга узгач бик куандым. Үземне идеал хатын дип санадым. Кызганыч, балам төште... (Хәзер аңлыйм, икең бер җан булып яшәмәгәндә Аллаһы Тәгалә бала бирми икән шул.) Бу минем өчен коточкычкыч фаҗига булды. Депрессия башланды. Дөньяга туа алмаган җан мине бәхетсезлектән саклап калыр төсле иде бит! Бәлки кабат эшкә чыгарга туры килүен уйлап та борчылганмындыр. Чөнки иптәш кызым белән эшләргә җаным тартмый башлады. Өйдә – ирем, эштә ул идарә итә минем белән. Бизнеска кире кайтмадым (ә үзәк – балалар үсеше белән шөгыльләнүче иң популяр мәйданнарның берсе хәзер). Кабат өй кошына әверелдем.

Ә мөнәсәбәтләр суынганнан-суына бара. Наилә сәбәпнең нәрсәдә икәнен аңлый алмый. Шулай аптырап яшәгәндә аның күзләрен ачалар. Бер ир-ат шалтыратып, хатыны белән Вилданның ике елдан артык очрашып йөрүен сөйли. «Хатыным ике бала белән

Фото: www.pixabay.com

өйдән чыгып китте. Без аерылдык», – ди ул. Назларның азаюына да, икешәр-өчәр көнгә генә түгел, хәтта Яңа ел бәйрәмендә командировкага чыгып китүгә дә җавап табыла.

– Ничек инде шундый матур, бар яктан булган хатын өстеннән йөрергә мөмкин, дип баш ваттым. Әллә күкрәкләрем кечкенә, тешләрем кыек микән дип, тышкы матурлыгымнан кимчелекләр эзли башладым, – дип искә ала Наилә.

Ә сәбәп бөтенләй көтмәгән җирдә «качкан»... Иренең сөяркәсе – аның кул астында эшләгән хезмәттәше бик максатчан, өлгер, тәвәккәл инженер-проектлаучы ханым булып чыга. Әнә бит балалар да үстергән, эштә дә карьера ясаган, үзен таба алмаган ирен ташлап чыгып та киткән (Сөләйман патша хикмәтләрендәге игелекле хатын булмаган). Шунда гына аңлый Наилә: ире белән бергә рухи яктан үсмәгән бит ул! Аңа күтәрелергә ярдәм иткән, ә үзе хакында онытканән. Аның белән бер дәрәҗәдә сөйләшә ала торган шәхес булырга тиешлеген уйламаган. Аларның өйдәге аралашулары да балалар тирәсеннән узмый. Соңгы вакытларда икәүдән-икәү калудан кача Вилданы. Сөйләшергә сүз табылмаган-гадыр, күрәсең.

Көндәше кебек уңышлы хатын буласы килү теләге дә көчле була.

Ишекне шап итеп ябып чыгып китеп булмый, балалар бар. Аларга яра салудан курка Наилә. Соңгы вакытта дини китаплар укыган хатын Аллаһы Тәгаләнең кичерергә кушканын белә. Төннәрен кайнарлыгын җәлләгән ире дә, ни гаҗәп, тезләнеп гафу үтенә. «Бөтен байлыкны үзеңә яздыртам, тик китмә генә», – дип елый-елый сорый. Мал-мөлкәт кирәкми шул, Наиләгә гаилә кирәк. Тешен кысып гафу итә. Борчулардан көндез булса да котылып торырмын дип, кабат эшләргә карар кыла. Һөнәри яктан үсәм дә иремнең хөрмәтен яулыйм дигән максат куя. Үзе белән идарә итүләрен яратмаган Наилә, белемен кабат яңартып, психолог кабинеты ачып җибәрә. Гаебен «юу» өчен ире дә акчасын җәлләми. «Ниһаять, максатың барлыкка килде», – дип мактап та ала. Балалар белән эшләү ошый аңа. Тик борчулары күп булгангамы, башкалар проблемаларын хәл итү бик авыр тоела. Үзең борчулы килеш ничек кешене бәхетле яшәргә өйрәтәсең? Баласын алып килгән аналар аннан еш кына «сез логопед та түгелме», дип сорыйлар. Наилә ул һөнәрне дә үзләштерергә уйлый. Психолог кабинетын ябып, логопед булырга теләвен белгәч, бала-чага уены дип кабул итә ире. Балам еламасын гына, теләгән һәр уенчыгын алып бирәм дигән мәгънә белән акча тоттыра (хәзер ник биргәненә, бәлки, үкенәдер дә). Укыганда ук эшли башлый Наилә. Бу һөнәрнең бик кирәкле булуын аңлый. Иң ерак районнарга йөрергә дә иренми.

– Дәрес бирергә барганда зур «Мерседес»ым белән йорт каршына килеп туктарга ояла идем. Читкәрәк яшереп куярга тырыштым. Кыйммәтле машинадан төшеп, 300 сумга эшләп йөрүемне дөрес аңламаслар кебек иде, – дип сөйли Наилә.

Клиентлар артканнан-арта бара. Логопед эше нәкъ менә аныкы булуын, бу эшкә сәләте барлыгын аңлый ул. Ничә еллардан соң үзенә ышанычы арта. Иң мөһиме: балалар ярата аны. Үзенә карата хөрмәт, ихтирам тоя башлый. Аңа исеме белән генә түгел, әтисенең исеме белән эндәшәләр! Авыр сөйләшкән балаларның ата-аналарыннан рәхмәт сүзләре ишетү нинди рәхәт икән! Өйдә боларның берсе дә юк иде бит! Кичләрен, китап-уенчыклар тутырылган тартманы күтәреп, алҗып кайтып керсә дә, бүгенге көннән зур канәгатьлек хисе алганын тоя. Ире дә башкачарак карый. Күзләрендә кызыксыну чаткылары күрә. Бергәләп яшәрбез дип, төзелә башлаган йортларын кабат тергезергә керешә. Наилә генә үзгәрә менә! Ул Вилданны гына түгел, кешеләрне дә ярата икән. Ирен башка яктан ача ул. Баксаң, акча дип агуланып беткән, шул кәгазьләр өчен дустын да сатарга риза икән бит аның яраткан кешесе. Аннан соң ял көннәрендәге «командировкалар» да дәвам итә. Тик Наилә моңа борчылмый инде. Яратамы соң ул аны? Аңа бит хәзер «текәлек» түгел, рухи яктан бай булу кирәк. Бәхетле дә булмаган ул. 15 ел бары тик бер кеше өчен генә яшәгән, аңа гына хезмәт иткән. Сине яратсыннар өчен башта үзеңне үзең ярату мөһим. Ул һәрвакыт Вилданны беренче урынга куйды. Ә ирләр үзеңне корбан итүне бәяли белмиләр. Әни-хатын янында «үсәләр» дә, үзләренә тиң күрми башлыйлар, читтән эзлиләр икән. Гомер бер генә тапкыр бирелә, ул яңача – үзенчә яшәргә тиеш. Ныклы карарга килә Наилә: аерылам...

Суд залыннан чыгалар да, икесенә бүленгән бер түбә астындагы фатирларына кайтып керәләр. Вилдан балаларны калдырмыйм, чыгып китмим ди, Наиләнең барыр урыны юк. Аерылырга үзең теләдең, инде ничек телисең шулай яшә дип, бөтен банк карталарын җыеп ала Вилдан. Баш күтәргән хатыннан үч алуны шуннан башлый. Анысына уфтанмый Наилә. Хәзер бит ул үзе акча эшли. Дөрес, күп түгел. Матурлык салоннарына да ишек ябылыр хәзергә, тик бәхет өчен никадәр аз кирәк булганын аңлый инде ул. Заказлар арта, тик күп вакыт юлда уза. Кабат кабинет ачарга кирәк дигән уй килә башына. Шул вакыттагы тәвәккәллегенә хәзер торып-торып шакката. Моңа кадәр кигән күлмәген дә ире алып кайтып биргән Наилә, Вилдан балалар белән диңгезгә киткәч, бердәнбер байлыгы булган «Мерседес»-ын сатып, кечкенә генә фатир ала. Шушында яшәр-без дә, кабинетым да булыр дип уйлый.

– Ул фатирны сатып алганнан соң килгән җиңел-

лекне аңлата алмыйм. Шунда балалар кабул итүне күз алдыма китердем дә, елап җибәрдем. Үземне бөтенләй башка кеше итеп хис иттем. Хәтта сулыш алулар да җиңелрәк тоелды. Ниһаять, тормышны яратканымны аңладым. Ничә елдан соң якты киләчәгемә өметем уянды. Диңгездән ирем белән балалар да кайтып төште. Ял иткәнгәме, бик шат иде ул. «Әйдә, яңадан матур итеп яши башлыйк әле», – ди. Ә мин машинаны сатып, фатир алуымны әйттем. Ул аны нигәдер хыянәтем итеп кабул итте. Минем бүләгемне сатарга хакың юк иде, дип үпкәләде. Бүләк – бер генә кешегә ясалган бердәнбер була ул. Казан урамында шундый ук маркалы, шундый ук төстәге машинада сөяркәсе җилдергәнен белеп яшәдем. Миңа кадәр аңа алып биргән ул бүләкне! Үзен кулга алып гафу үтенсә дә, бергә булырга кыстаса да, күңелем эремәде. Эремәячәк тә! Мин хәзер үземә нинди кеше кирәк булганын беләм. Вилданда булмаган бөтен сыйфатлар булырга тиеш анда. Ул кешенең очраячагына да шигем юк. Ышанам! Тагын берничә атнадан үз кабинетымны ачып җибәрәчәкмен. Шунда яшәрмен дә, эшләрмен дә. Яратмаган кешең белән бер түбә астында яшәүдән дә зур җәза юк икән ул. Мин шалашта яшәргә дә риза. Урамда калмаячакмын, чөнки эшем бар, һәм мин гаилә тормышында яшәп ала алмаган рәхәтлек алам. Өйдән чыгып китәргә көч туплыйм. Балаларым, әти белән калабыз, диләр. Күрәләр: әлегә мин аларга берни бирә алмыйм, ә Вилдан көн саен кыйммәтле бүләкләр күтәреп кайта. Алар өчен дә артларыннан җыештыручы булып кына йөргәнмен икән... Иң җанга тигәне дә шул: иремә кол булып, балаларымның да хөрмәтен югалтканмын. Тик кайчан да булса бәхетнең байлыкта түгеллеген, дөньяда мәхәббәт,

«Мерседес»ым да юк, акчамны да тиенләп тотам, тик мин бик бәхетле!

җылы мөнәсәбәтләрнең мөһимрәк булуын аңламый калмаслар. Шул вакытта әни кирәк булыр... Әлегә мин шәһәр буйлап җәяү йөрсәм дә, рестораннарга кереп ашый алмасам да, үземә затлы киемнәр ала алмасам да, бик бәхетлемен. Яраткан эшем белән бергә яңа матур тормыш башларга җыенам. Анда мин тәмле итеп ашарга пешереп, өйдә утырган курчак түгел, ә шәхес булачакмын!

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ

Ләлә БӘҺРАМШИНА,
психолог

Гомер узган саен, ир белән хатынның тормыш кыйммәтләре дә үзгәрә. Бер-берсен аңламыйча үпкәләшеп, авыр сүзләр әйтешеп, кызганыч, алар кайчак аерылышуга кадәр барып җитә. Ләкин катгый адым ясаганчы, элекке хисләрнең кая югалганын бергәләп эзләргә тырышыгыз әле. Моның өчен тынычлап утырып, ачыктан-ачык сөйләшү мөһим. Ир белән хатын күңелгә җыелган төеннәрне чишсен. Ләкин һәрнәрсәнең үз җае бар. «Син миңа бик аз игътибар итәсең» дип әйтү гаеп ташлау кебек кабул ителә. «Синең белән күбрәк вакыт үткәрәсем килә» дип әйтү дөресрәк. Аның сиңа кирәклеген дә күрсәтә ул. Ә ир-атка, чираттагы тапкыр үзен көчле зат итеп тою өчен, хатын-кызның теләген канәгатьләндерү мөһим. Мондый сөйләшүләр икегез өчен дә уңайлы вакытта булырга тиеш. Эштән алҗып кайтып кергән иргә ишек төбеннән үк дәгъвалар белдерү бервакытта да хәерлегә илтми. Кичке аштан соң, табак-савыт юу урынына, ирең янына барып сырпаланып алсаң менә, ике арадагы киеренкелек шундук юкка чыгар.

Шуны онытмагыз: гүзәл затлар сөйкемле булып, үзенә тартып торырга тиеш. Ягымлы хатын ире өчен – магнит. Ул сезне ишетеп, теләгәнегезне эшли икән, аның кайгыртуын тоюыгыз хакында үзенә дә белгертергә кирәк. Яхшы ир булганлыгына тагын бер инансын.

Аның сезне «ишетмәгән» чаклары да буладыр. Игътибар итегез: бәлки, сез дә ирегезнең үзегездән ни көткәнен аңлап, тоеп җиткермисездер. Тыңлый белү – аралашуда иң мөһим әйбер. Уйлап карагыз: ул (яки балагыз) сөйләгән вакытта аңа карыйсызмы, бу хакта ничек сөйләгәнен тоясызмы, әйткән сүзләрен күңелегез аша үткәрәсезме, сорау биргәндә: «Син шулай дип әйттең бит, дөрес аңладыммы?» – дип сүз башлыйсызмы? Тыңлый белмисез икән, сезне ишетерләр дип өметләнмәгез дә. Хатагызны аңлап, мин игътибарсыз булганмын дип, гафу үтенергә бервакытта да соң түгел. Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләрнең өч төрле дәрәҗәсе бар: эмоциональ, интим һәм социаль. Эмоциональ яки интим мөнәсәбәтләрдә килеп чыккан проблеманы аерылып китеп (социаль мөнәсәбәт белән) хәл итмиләр. Һәрберсен үз дәрәҗәсендә чишәләр.

Ике кеше уртак максатта килешенеп яшәгәндә генә саклана гаилә. Ә бит һәр кешенең шәхси иреге һәм кызыксынулары бар, аларны хөрмәт итү зарур. Һәрберебез бу дөньяга үзенең «минен» табарга килә, аны ача белергә генә кирәк. Ә талантың белән җәмгыятькә файдалы булу – зур бәхет. Башкарылган эштән тәм табу – үзебезгә ышанычны арттыра, хатын-кыз энергиясен саклый. Үсеп килүче балалары да, ире дә менә шундый хатыннарга тартыла инде.

PRESSA



КУНАККА ГЫНА КИЛИК, ВЫБОРГ

ТАР УРАМНАР, ТЫМЫЗЫК КҮЛЛӘР, ГРАНИТ КЫЯЛАР... БУ УРАМНАРДА ШВЕД, ФИН, НЕМЕЦ, РУСЛАР ЙӨРГӘН. ХӘЕР, ТАТАР ӨЧЕН ДӘ ЯТ ТҮГЕЛ УЛ...

Выборг Россиянең чигендә урнашкан: Финляндия белән аны нибары 27 чакрым аерып тора. Санкт-Петербургка да бик якын. Петр каласын «Европага тәрәзә» диләр, әмма бу гыйбарә Выборгка күбрәк туры килә.



Люция ШӘРӘФИЕВА

Хельсинкидан кала кайчандыр Финляндиянең икенче зур каласы саналган Виипурига бару хыялы миндә узган ел барлыкка килде. Выборг архивыннан бер исемлек кайтарттык. Ул исемлектә Байлар Сабасы, Сабай, Олы Арташ, Мәртен, Пүкәл, Килдебәк, Олыяз, Завод Нырты, Өчнарат, Калатау, Кече Кибәче, Сатыш авылы кешеләре. 268 якташым! Араларында Олы Кибәчедән әниемнең әти-әнисе Хөснулла белән Мәшүдә, әтием ягыннан бабам Хәбибрахманның абыйсы Гыйлаҗетдин, сеңлесе Хәтирә гаиләсе дә бар. 1939 елгы фин сугышыннан соң, Россиягә бирелгән җирләрне үзләштерү максаты белән килгән алар Выборгка. Матур гына яшәп ятканда Бөек Ватан сугышы башлана... «Ир-егетләрне сугышка алдылар, ә без Ленинградка кайтып, камалышка эләктек. Шунда алты баламны югалттым, калган балаларым, камалыштан чыккач, ачтан үлделәр. Иремне һәм унбер баламны югалтып, Олыязга берүзем кайтып егылдым», – дип сөйли торган булган авылдашларына Шәмсекамәр әби Хуҗина.

...Моннан 77 ел элек бомбалар яңгыры астында якташларым җәяүләп кайткан юлдан мин машинага утырып уздым. Санкт-Петербургтан Выборгка барып җиткәнче гел елыйсым килде. Ул чакта 8 яшьтә булган авылдашым Мәрзия апа Дәүлиева сөйләгәннәр колагымда яңгырап торды: «Авылга кайтырга чыктык. 50 чакрымлап юл үткәч, урман кырыендагы бер өйгә кердек. Самолетлар бомба ташлый башлады. Бөтен дөнья дер селкенә. Тәрәзәләр кырылып төште... Төнлә генә барабыз, көндез качып утырабыз. Бара торгач, ниндидер бер елгага җиттек. Әти безгә: «Резина күпер булыр, шуны чыксагыз, исән калырсыз, чөнки үзебезнең илдә булырсыз дип беләм», – дигән иде. Без чыгып та өлгердек, артыбыздан ук күпергә бомба төшеп шартлады. Никадәр халык бар иде – барысы да су төбенә китте». Алтышар-җидешәр бала белән юл газабы кичкән апаларны, нәкъ шушы җирләрдә яраланган Гыйлаҗетдин бабайны, актык сулышын биредә – Колпинода алган Габдрахман җизнине, Петергоф, Синявино калкулыкларын саклаган күрше Галиәскәр, Нуретдин бабайларны искә алып барам.



Күңел халәтемне табигать тә аңлады – юл буе яңгыр койды.

Исәнме, Выборг!

Әби-бабаларым эзләреннән килдем сиңа, таш кала! Аларны син дә хәтерлисеңдер, олпат Олафа кирмәне... Шәһәргә нигез салган әлеге биек замок Фин һәм Выборг култыгы сулары бергә кушылган җирдә урнашкан – әллә кайдан күренеп тора. Россиядә сакланып калган бердәнбер урта гасыр кирмәне ул. Кызганыч, күзәтү мәйданчыгы реставрацияләнә икән – анда менсәң Финляндия җирләрен дә күрергә була, диделәр.

...1293 елда шведлар маршал Торгильс Кнутсон җитәкчелегендә Новгородка караган кареллар җирен басып алалар. Шул урында изге кирмән төзелә башлый. Скандинавиядә христианлыкны ныгыткан Норвегия короле хөрмәтенә аны «Олафа кирмәне» дип атыйлар. Кирмәннең биеклеге – 48,6, нигез буендагы диварларының калынлыгы – 5 метр. Новгородлылар аны берничә тапкыр кире алырга тырыша – барып чыкмый. 1706 елда Петр I дә талпынып карый: үзе төзегән шәһәрнең борын төбендә генә дошман кирмәне торуын теләми. 1710 елның мартында Петр I корабында швед әләме күтәреп, командасын шведча киендереп, кирмәнгә якынлаша... Әмма кирмән күпсанлы һөҗүмнәрдән соң, 13 июньдә генә бирелә әле. Җиңүен бәйрәм итү өчен, патша күзәтү каланчасына берничә мичкә шәраб менгезергә куша. Сөенеченнән: «Куркыныч бетте», – дип, илле кешегә хат юллый... Тарихтан беләсез: Финляндия Россия составына бер керә, бер чыга аннан. Выборг та шулай. 1941 елда ул кабат фин шәһәре санала башлый. 1944 елда безнең гаскәрләр азат иткәч, Выборг советларга кала. Һәр ил, аны алу хөрмәтенә, кирмәнгә үз әләмен элә торган була. Совет сугышчылары, кызыл әләм тапмагач, аптырап калмыйлар, аның урынына кызыл итәк менгереп эләләр. Бу экспонат бүген Выборгның тарих музеенда саклана.

Сталин Выборгны иң беренче чиратта төзекләндерелергә тиешле 15 шәһәр исемлегенә кертә (безнең ил өчен бу каланың нинди әһәмиятле булуын шуннан да чамалыйсың!). Финнар ташлап киткән буш шәһәргә Россиянең төрле төбәкләреннән халык китереп тутыралар. Инде икенче кабат! Әмма крестьяннар таш каланы үз итми, янәшәдәге хуторларга шикәр чөгендере үстерергә китеп бетә. Шәһәрдә тимер юлчылар һәм

PRESSA



■ Түгәрәк башня. Аны «Юан Катерина» дип тә йөртәләр. «Төньяк илләр банкы»н каплап тора, дип, аны берара сүтәргә дә җыенганнар. Бер фин архитекторы, диварларына тарихи темага рәсемнәр ясап, саклап калган. 1923 елдан бирле монда ресторан эшли. Туристлар арасында бик популяр, диделәр.

■ Базар мәйданының каршы ягында модерн һәм неоготика стилендә төзелгән кызыл бина тора. 1940 елга кадәр анда фин милли банкы урнашкан булган, бүген бу бинага «Сбербанк» хуҗа.



кораб төзүчеләр кала. Суднолар төзергә исә Ленинград кешеләре килә. Бүген биредә Финляндиягә илтүче эре тимер юл станциясе, порт, флот урнашкан.

Выборг 30 фильмда «катнашкан».

1941 елда совет гаскәрләре шәһәрне ташлап киткәндә күп кенә объектларга радио аша идарә ителә торган яшерен миналар куеп калдыралар. Алар берничә ай дәвамында радиосигнал буенча шартлатылырга тиеш була. Совет әсирләрен кулга төшергәч, финнар моны белеп ала һәм тиз арада шәһәрне чистарту эшенә керешә. Радиосигналларны тоту максатыннан, ике ай буе шәһәр буйлап радиостанция йөри: тиз ритмлы музыка уйнап тора. Сяккиярви полькасы – радиосигналны томаларга булышуы билгеле. Шулай итеп күп кенә тарихи биналар җимерелми кала. Бүген алар Иске шәһәрнең горурлыгы. Дөрес, күбесен сүтеп атарга да өлгергәннәр. Сакланып калганнары – кирмән янәшәсендәге Крепостная урамында. Бүген иң матур биналарның берсе саналган Сәгатьле манара да шушында. Аның түбән өлеше 1494 елда ук төзелгән, чаң суга торган беренче сәгатьне 1753 елда урнаштырганнар. Фин язуына нигез салган, Библияне фин теленә беренче тәрҗемә иткән Микаэль Агрикола биредә күмелгән дигән риваять тә бар.

Выборгка килүчеләр беренче эш итеп Базар мәйданына юл ала: ул кирмән белән янәшә генә. Сәгатьле базар бинасы бик үзенчәлекле. Әмма эченә керсәң, башка базарлардан әллә ни аерылмый да кебек ул. Шулай да монда Финляндиядән китертелгән балык, сыр, шоколад, балалар ризыгы сатып алырга була. Заманында илнең икенче курорт шәһәре саналган Выборг финнар өчен бүген дә кадерле, аларны монда еш очратасың. Шәһәрне төзекләндерүгә дә үз өлешләрен кертәләр. Алвар Аалто китапханәсе дә финнар акчасына төзекләндерелгән.

Ратуша башнясы – XVII гасыр урталарыннан лютеран чиркәвенең чаң кагу урыны буларак билгеле. Берничә тапкыр зур янгын кичергән. 1738 елда ул бөтенләй янып бетә – аның урынына яңа бина төзелә. Иске Ратушаның тарихи-этнография музее шушында урнаша. Рус рәссамы Василий Громме музейга үз картиналарын һәм борынгы әйберләрен васыять итеп калдыргач, бинаны яңартырга да туры килә. Хәзер биредә торак йорт урнашкан. Вакыт һәрберсен үз урынына куйган: швед патшасына аргы яктан Петр I карап тора, Октябрь революциясе ясарга Выборгтан киткән Ленинга да һәйкәл бар.

Шәһәр чиста. XVI гасырда король Густав Ваза I: «Һәр йортның хуҗасы булырга тиеш», дигән әмер чыгарган. Шуңадырмы, биредәге һәр йортның үз «пичәтемөһере» бар. Аларны ишек өсләрендә, диварларда күрергә мөмкин. Милли ризыклары – крендельләре дә «W» тамгасы рәвешендә. Король идарә иткән чорда кала буйлап төнге сакчы йөргән һәм һәр сәгать саен: «Тыныч йоклагыз, шәһәрдә иминлек», – дип кычкырган. Әгәр дә берәр йорт янында чүп күрсә, йоклап яткан хуҗаның урын-җиренә кертеп салган.

XIX гасыр башына Выборгта яшәүчеләр саны 3 мең чамасы булган. Халыкның 44 проценты – финча, 29 проценты – русча, 14 проценты – шведча, 13 проценты немецча аралашкан. Күбесе дүрт телдә дә иркен сөйләшкән. Аларда бу гадәти күренеш саналган. Бүген Выборгта 80 меңгә якын кеше яши. Чик якын булганлыктан, 1957 елга кадәр ул «ябык шәһәр» саналган. Аерым фоторәссамнарга гына төшерергә рөхсәт



■ Шәһәргә нигез салучы Торгильс Кнутссонга һәйкәл Николай II рөхсәте белән Парижда коелган һәм Выборгка кайтартылган. Әмма «Россия дошманына үзәктә урын булырга тиеш түгел» дип, аны 45 елга подвалга «бикләп» куялар. 1993 елда шәһәрнең 700 еллыгы вакытында гына ул кабат «дөньяга чыга».

ителгән, анда да шәһәр күренешләрен түгел, кешеләрне яки ниндидер вакыйгаларны гына. 1958 елның 1 июлендә Выборгка беренче туристлар аяк баскан. Шул көнне Хельсинки–Выборг, Хельсинки–Ленинград–Мәскәү халыкара автомобиль маршруты ачылган. Финляндиядән 95 турист килеп төшкән, тик аларга вокзалдан ары узарга рөхсәт ителмәгән.

Мондагы тын тар урамнар әллә күпме сер саклый: тыкрык узуга ук көтелмәгән җирдән килеп чыгучы манаралар, әллә кая китеп югалучы сукмаклар, өйләрдәге таш уемнар, төрле диннәргә караган гөмбәз, шпиль, хачлар, карел-фин эпосы «Калевала» персонажлары... Боларны укый белергә генә кирәк. Һәр йорт – тарих. Фильмнар төшергәндә каланы чын декорация сыйфатында файдаланалар. «И на камнях растут деревья» фильмы биредә төшерелгән. Күптән түгел генә әле аңа «Киев Русе» булып торырга туры килгән.

Крепостная урамы – Иске шәһәрнең йөрәге булса, күрше Водная застава урамы – башы. Бирердәге йортлар язмышы да гыйбрәтле. Выборгта федераль әһәмияткә ия җиде урта гасыр йорты бар. Шуларның берсенә – Россиядә сакланып калган иң борынгы йортка – 430 елдан артык. Бүген ул йортның 40 квадрат метрлы ике бүлмәсендә ике гаилә яши. Соңгы елларда алар йортны шактый үзгәрткәннәр: пластик тәрәзәләр куйганнар, мичне сүткәннәр – йорт үзәктән җылытыла башлаган.

...Бер көн эчендә Иске шәһәрне урап чыгу мөмкин түгел. Һәр йорт янында тукталып, ишек-балконнарын, тәрәзә өслекләрен, тәрәзә яңакларын иркенләп өйрәнәсе, таштан могҗиза тудырган осталарга сокланасы, һәр бизәкне күңелгә сеңдерәсе килә. Сер түгел, шәһәрдәге тарихи биналарның күбесе ташландык хәлдә. Киләсе елга зур төзекләндерү эшләре башланыр дип көтәләр: федераль үзәк шушы максатка 50 миллион доллар акча бүләргә вәгъдә иткән.

Йәгез, бер дога!

Шәһәрнең йөзе – аның кешеләре, әлбәттә. «Кая барырга?» – дип аптырап торсаң, яныңа шунда ук кемдер туктый. «Нинди ярдәм кирәк?» – дип сорый, кирәк икән – тарихка экскурсия дә ясап ала. Тымызык күлләр, безнең елак таллларга һич охшамаган түгәрәк башлы купшы таллар, көймәләр белән тулы Фин култыгы, чуен күперләр, таш сукмаклар – барысы да сокландыра. Биналарында өстенлек иткән төньяк модерн стиле Финляндия һәм Карелия табигатенә аваздаш. Аларны гранит берләштерә. Әлеге кызыл таш кыя кыр-урманнардан биналарга «үтеп» кергән – борынгы йортлар өчен ул нигез ролен үтәгән. Диварларга төшерелгән урман җәнлекләре сурәте еш кына йорт хуҗасының үзенчәлекле холкын яисә бинага урнашкан фирманың ышаныч дәрәҗәсен белдерә. Әнә фин банкы урнашкан йорттагы тар тәрәзәләр, химерлар усал сакчыларны гәүдәләндерә, тугра белән бизәлгән ишекләр хуҗаларның абруен күрсәтә.

Заманында илнең икенче курорт шәһәре саналган Выборг финнар өчен бүген дә кадерле.

...Каланы төзегәндә һәр агачны, һәр сулыкны, һәр ташны сакларга тырышканнар. Базар мәйданыннан – Суворов проспектына, Ленин проспектыннан Крепостная урамынача сузылган Эспланада паркы – туристларның һәм шәһәр халкының иң яраткан урыннарыннан берсе. Биредә мәгърур поши, үсмер урманчы скульптуралары, аю фонтаны урнашкан. Поши тоягына кулың белән кагылсаң, Выборгка сау аякта кире кайтасың дигән ырым яши. Юсси Мянтюнен ясаган бу һәйкәл күчермәләрен Финляндиянең Хельсинки, Турку һәм Лахти шәһәрләрендә дә очратырга була. Ә хәзергә поши тоягын сыйпыйк та кайту ягына таба борылыйк. Тик соңгы мизгелдә, гүя кемдер саташтырды – килгән юлыбыз сулга борылды. Һәм каршыда... яшькелт төстәге тимер юл вокзалы күренде. Минем бабайларны, якташларымны кабул иткән иске вокзал бинасы инде сакланмаса да, алар аяк баскан туфрак... Шунда кылт итеп исемә төште: «Выборгка килүгә, иң беренче итеп вокзалга барам», дигән идем бит... Машинадан чыгып, вокзал мәйданына юнәләм. Һичкемнән тартынмыйча, кулларымны күтәреп, изге дога сүзләрен кабатлыйм: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим... Бу фани дөньядан киткәннәрнең рухлары шат булсын, алар кичергән бәла-казаларны, сугышларны безгә күрергә язмасын! Сиңа кунакка гына килик, Виипури-Выборг!»

Автор фотолары

16+

ЙОРТТАГЫ ЙОРТТА КАЛСЫН



Рөстәм ГАЙЗУЛЛИН,
Татарстанның атказанган артисты.
гаилә стажы – 13 ел;
балалары – Рамазан (11 яшь),
Нурсолтан (9 яшь).

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.**

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Иң мөһиме: хатын-кызның күңеле чиста булсын, дип әйтергә яраталар. Тик ерактан аның карашының тирәнлеге дә, күңеленең матурлыгы да, күзенең төсе дә күренми бит. Аралашу дәвам итсә генә күзгә ташлана башлый болар. Ир-ат башта тулаем образны күрәдер.

Тавыш мөһимме икән? Моңа кадәр уйланганым булмады, хатын-кыз сине үзенә җәлеп иткән мизгелдә, димәк, тавыш аның кадәр мөһим түгел. Минем өчен шулай. Тавышның чәрелдек булганын яратмыйм, чинап, кычкырып сөйләшкән хатын-кызларны өнәп бетермим.

2 Ир кеше өчен хатыны аңа дус та була аламы?

– Әлбәттә! Үзебезнең ун ел элеккеге һәм бүгенге мөнәсәбәтләрне чагыштырам. Хәзер без ир белән хатын булудан кала, дуслар да. Ә дус булу кирәк! Хатын-кызга да, ир-атка да. Бары тик дустыңа гына ачыла аласың. Безнең гаиләдә, мәсәлән, шундый закон бар: йорттагыны беркайчан тышка чыгармаска. Кеше арасында үзенең ирен яки хатынын хурлаучыларны аңламыйм. «Кара инде, мондый хатынны кайдан алдым?!» – диючеләр танышлар арасында да очрый. Бәлки, уенын-чынын кушып әйтәләрдер, әмма минем бала йоннарым кабара. Дус булган кеше, бер компаниядә утырганда: «Менә ашарга ничек пешерәләр! Альбинананың котлетлары нинди тәмле, син кайчан өйрәнәсең?» – дип хатынына әйтәмени?!

3 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Театр училищесына укырга кергәндә, абитуриент вакытта ук гашыйк булдым мин аңа. 15 яшьтә!

«Әйдә, дуслашыйк, очрашыйк», – дип, берничә тапкыр тәкъдим итеп карадым – Альбина кире какты, әмма бу безгә дуслар булып калырга комачауламады. Алай гына да түгел, якын дусларга әверелдек. Шимбә, якшәмбегә ул авылга кайтып китә, мин Казанда калам. Килгәч, авылда аны кем озатканын, кем белән нәрсә сөйләшкәнен – барысын сөйли. Минем дә аннан сер юк: кайсы кызны озатканымны, кем белән үбешкәнемне түкми-чәчми җиткерәм. Курсташлар моннан хәбәрдар. «Дүртенче курска җиткәч, өйләнешеп куярсыз әле», – диләр. Альбина кул селти: «Кит аннан, булмаганны!» Ә чынлыкта барысы да нәкъ шулай килеп чыкты!

Ә ничек тәкъдим ясаганымны, әлбәттә, хәтерлим. Ул көнне аны Шүрәле паркына чакырдым. Чәчәгемне бүләк иттем дә, әле берни сизмәгән Альбина белән «Күзәтү тәгәрмәче»нә утырып, өскә менеп киттек. Укуны тәмамлап, инде икебезнең дә Яшьләр театрында эшләгән чак – һаман да эш турында сөйләшәбез. Иң югары ноктасына менеп җиткәч: «Беләсең – яратам, – дим. – Миңа кияүгә чыгасыңмы? «Юк» дисәң, шушыннан төшеп китәсең хәзер...» Монысын, сөйләгәндә, соңыннан үзебез өстәдек бугай...

4 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр. Шулаймы?

– Бәлки, күңел түрендә, үзем аңламыйча гына эзләгәнмендер, белмим. Килен – кайнана туфрагыннан, дип әүвәлгеләр юкка гына әйтмәгән. Әгәр әни белән хатыным уртак тел тапмасалар, унөч елдан бирле бер кухняны бүлеп яшәмәсләр иде. Гаилә ишле безнең – алты җан. Һаман да әти-әни белән яшәвебезгә күпләр ышанмый да. Ә без аларның аптыравына шаккатабыз. Гаилә коргач, безнең өйдә бер сөйләшү булды. Икесен дә яныма утыртып: «Әни, син – минем тормыштагы төп хатын-кыз, сине әни буларак яратам, ә сине, Альбина – хатын буларак. Сезнең арада ниндидер аңлашылмаучанлык килеп чыкса, миңа икеләтә авыр булачак», – дидем. Ул яшьтә миңа кайдан шундый акыл килгәндер, гаҗәп... Шушы сүз аркасында гына тату гомер итәбездер дип әйтә алмыйм. Аларның икесенең зирәклеге бу. Безнең йортта килен дигән сүз бер тапкыр да яңгырамады, Альбинага «кызым», дип кенә дәшәләр.

5 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Альбина үзенең миңа карата үзгәргәнен Минзәләгә практикага баргач белдерде. Безне техникум тулай торагына урнаштырдылар. Казан кызларына шунда ук күз

төшерүчеләр дә табылды. Үзебезнекеләр белән басып тора идем, Альбина килде дә: «Егетләр бәйләнә калса, мин синең кызың, яме», – диде. Үзе килеп култыклап алгач, сыенгач, башка ычкындырмадым инде...

Гашыйк булуны төрлечә белдереп була бит аны. Җиңелчә флирт белән (ир-ат сизгән очракта, кирәк дип санаса, барысын да алга таба үз кулына алачак аннары) яки киресенчә – ябышып, бәйләнчекләнеп. Хатын-кыз сиңа үзе ябыша башлый икән – кире эффект тудыра. Бер чарада шундый хәл булды. Альбина белән икәү эшлибез. Бер ханым ачыктан-ачык бәйләнергә кереште. «Гафу итегез, мин өйләнгән бит», – дим. «Хатын бөтен кешедә бар инде. Бәлки номерымны язып алырсыз?» – ди. Монысы әрсезлек кенә түгел, оятсызлык. Үпкәләтәсем килми, әмма мин моны фахишәлеккә тиңлим.

6 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Тискәре, шук, шаян, баламут... Театрда күбрәк рольләрнең шундыйларын бирәләр. «Болгар» радиосының «Чәкчәк-шоу» тапшыруына да шушы образга алдылар. Тәмам ябышты! Яңа танышкан кешеләрдән: «Кара, син нормальный икән бит», – дигән сүзне ишетеп, күптән аптырамыйм инде... Миндә булган романтиклыкны, нечкә күңелемне дә күрүләрен теләр идем.

7 **Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта...**

– Тыштан нинди генә күренсә дә, куенга кереп җылынасы килмәгән хатын-кыз юктыр ул. Табигатьне алдалап булмый... Хатын-кызның шушы битлеген салырга мәҗбүр итә алса, ир-ат аннан куркып тормый инде, әлбәттә.

8 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Бар андый бер нәрсә. Моңа ун ел элек тә шакката идем, бүген дә: минем Альбина җыештыра икән, аннан соң бер әйбер табам димә. Ипотекага алган икенче фатирыбыз бар хәзер. Мин бит шәһәрнеке – асфальт баласы, җирдә казынып, нидер эшләп үсмәгән. Шуңа барысы да кызык. Балконда шкафлар ясап куйдым менә. Үземчә мәш киләм: экренләп, җентекләп, ашыкмыйча гына эшлим. Һәм беләм: сул якка борылып үреләм икән, анда – рулетка ята. Кул сузымында – пычкы. Шөрепләр – балкон шкафында... Әмма бит ара-тирә җыештырырга да кирәк. Анысын инде җенем сөйми – идән юу холкыма туры килми. Сөекле хатыныма мөрәҗәгать итми чара юк. Нәтиҗәсен дә беләм югыйсә, тик үземне җиңеп барыбер идән юа алмыйм. Бик тырышсам, бәлки, булдырамдыр да, ләкин хатын килеп булышса рәхәтрәк бит. Икенче көнне интегәм инде аннары!.. «Әнисе, менә моны җыеп куй әле», – дип, кайчак нидер бирәсең. Җыеп куя. Кире сорасаң, гел бер җавап аңарда: «Урынлы булсын дип каядыр куйган идем. Кайда икән инде?» Ярты сәгать эзләгәч, таба тагын!

9 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...**

– Мин бик кызу кеше: тиз кабынып китәм һәм тиз сүнәм дә. Ир белән хатын арасында ташлар бәрелешкән, очкыннар чыгып алган чаклар була инде. Кызам! «Ничек инде син шуны аңламыйсың?» – дим. «Әтисе, алай түгел бит!» – дип каршы төшә Альбина. «Син мине һаман аңламыйсыңмыни?» – дип тавышны ук күтәрәм... Һәм кайтып төшәм. Өйдә безнең яраткан урын бар. Балконга чыгып, кара-каршы утырабыз да, йомры-йомры тәеннәрне чишәбез. Планнар да шунда корыла. Уртак фикергә килмичә калган чак юк әле.

10 **Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.**

– Безнең андый проблема юк. Өйдә бит ике хуҗабикә: берсе өлгермәсә, икенчесе әзерли.

Бар шундый көннәр, суыткыч тулы ризык булса да, кинәт нидер пешерәсе килә башлый. Андый чакта өч сәгатькә кухня минеке! Бик яратам ул процессны. Әни пешекче безнең. Миңа карасаң, аңлашыла бит инде... Әмма балачактан ир-атның да кайчак нидер пешерүен күреп үстем. Әти шулай ярты елга бер бәйрәм ясый иде безгә. Аның борщы, итле бәрәңгесе, кыздырган балыгының тәмлелеге! Балачактан дигәннән. 20 август – минем өчен кечкенәдән гаилә бәйрәме. Әти белән әни шул көнне өйләнешкән – Яңа ел кебек зур бәйрәм ул бездә. Альбина белән без дә 20 августка туры китереп кавыштык. Быел гаилә бәйрәме көнне балалар икәүләшеп: «Әти, без дә 20 август көнне өйләнәбез», – дип көлдерделәр әле.

Пешерергә яратам дип сөйли идем бит. Тик миннән соң җыештырырга гына кирәк... Ә хатын-кыз, гафу итегез, бот күтәреп ята икән, бу инде дөрес хәл түгел. Авырып китсә әле – икенче мәсьәлә. Ә ару сәбәп була алмый. Арыганчы да пешереп куеп була бит аны, әйтик, кичтән. Безнең менталитетта ашарга пешерү – турыдан-туры хатын-кызның вазыйфасы. Аның язмышы шундый. Ишектән бергә кайтып керсәк соң...

11 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.**

– Минем хатынга гына хасмы икән ул, белмим, әмма кая да булса бара башласак, «Соңга калабыз!» – дип, аңарда паника башлана. Соңга калудан коточкыч курка, алай-болай әйткән вакытка өлгермәсә, аның йөрәге туза. Малайларда да бар ул сыйфат. Әниләреннән бирелгән, күрәсең. Тренировкага үзем озатам – беркайчан соңга калдырган юк. Әмма һәр көнне: «Әти, син еракмы әле, кайтып җитәсеңме, өлгерәбезме?» – дип шалтыратмый калмыйлар. Соңга калу алар өчен – фаҗига.

12 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...**

– Альбина: «Иң мөһиме: бүләк кирәкле әйбер булсын», – дип саный. Ә минемчә, кирәк әйберне кеше үзенә үзе дә ала. Бүләк ул шаккаттырырга тиеш! Кемгә дә булса бүләк биргәндә аның күзендә шул очкыннарны күрәм икән, миннән дә бәхетле кеше юк. Шушыннан тәм табам, канәгатьләнәм, энергия алам. Үземә бүләк кирәкми дә. Сюрпризлар эшләргә яратам. Кечкенә генә нәрсәләрдән дә ясарга була бит аны. Аның каравы, тормышны эмоцияләргә баеткач, шундый кызык!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

МИН СИНЕ ТЕЛӘМИМ ЯКИ ҺӘР ЙОЗАКНЫҢ ҮЗ АЧКЫЧЫ



Мәхәббәттә назлануның нәрсә икәнен оныттыгызмы? Сез ялгыз түгел... Гаилә тормышы белән 10–15 ел яшәгәннән соң, күп кенә хатын-кызларның якынлык кылу теләкләре бетә. Кайбер белгечләр дәрт суынуга психологик проблеманы сәбәп итеп күрсәтә, икенчеләре сәламәтлеккә сылтый. «Аны бар яклап өйрәнү зарур», – ди сексопатолог, психотерапевт, медицина фәннәре кандидаты Гүзәл ДУБИВКО. Моннан кала, иң яхшы ысул – яраткан кешең белән ачыктан-ачык сөйләшү. Организмның сексуаль функциясе парлы эшчәнлекне таләп итә. Кеше тормышындагы иң ләззәтле мизгелләрнең берсеннән читләшү сәбәпләрен белгеч ярдәмендә башта үзебез, хатын-кызлар, аңларга тырышып карыйк әле.

Хатын-кызның җенси дәрте ир-атныкыннан ничек аерыла?

Ир-ат: «килде, күрде һәм җиңде». Көчле затлар өчен теләк белән дәрт синонимнар булып тора, ә бездә ул башкачарак. Психик халәт белән бәйле. Бу хатын-кызлар өчен «мәхәббәт эчемлеге» уйлап тапмауның төп сәбәпчесе дә. Кече оча сөяге органнарына кан йөгерү, билгеле, дәртлелекне уята. Ләкин шул ук вакытта хатын-кызның бернинди теләге булмаска мөмкин. Ул бары тик җылы мөнәсәбәтләр булганда гына туа дип саный кайбер белгечләр. Җенси дәрт берничә этаптан тора:

Платоник – кешеләр арасыннан бары тик бер кешегә генә аеруча игътибар итү, аңа ошарга тырышу.

Эротик – романтика белән бәйле. Җитәкләшеп йөрү, матур сүзләр пышылдашу, гөнаһсыз кагылып китүләр. Кызларда ул тизрәк үсеш ала.

Сексуаль – якынлык кылудан шәһвәт (оргазм) алганда гына туа башлый. Егетләр әлеге этапка тизрәк өлгерә. Чөнки аларга дәртнең төп максатына ирешүгә бернинди киртәләр юк. Кызлар исә өлгереш чорын авыр кичерә. Әзерлексез яшүсмергә күрем килә башлау зур фаҗига. Беренче якынлык кылу да авыртудан башка бернинди уңай тәэсирләр бирми.

G ноктасы

■ Борынгы һинд трактаты Камасутрада хатын-кызлар тәнендә төп эроген нокталарны, шул исәптән G ноктасын (ул аналык җиңсәсенең алгы стенасында, керү юлыннан 3-5 см өстәрәк урнашкан) стимуллаштыру тәҗрибәсе хакында язылган. Ул җенес органнары тирәсендәге мускулларны тиз темпта эчкә тартудан һәм җибәрүдән гыйбарәт. Тын алу да дөрес башкарылырга тиеш. Мускулларны эчкә тартканда сулыш аласың, йомшартканда сулышны чыгарасың. Гимнастиканы лотос торышында яки тезләргә утырып, кулларны өскә күтәреп, баш бармакларны чалыштырып, бер циклда кимендә 120 тапкыр ясарга кирәк. Сабырлык таләп иткән бу стимуляциянең нәтиҗәләре тәэсирләндергеч!

Хатын-кыз шәһвәтне уртача 28 яшьтән соң ала башлый. Даими секс булган очракта гына! Дәрт кузгалып та, хатын-кыз ләззәт ала алмый икән, ул аның өчен күңел ятмаган «эшкә» әйләнә башлый. (Шунысын да онытмаска кирәк, теләк булып та, ләззәт ала алмау ханымнар өчен киләчәктә авырулар сәбәпчесе булачак. Аналыктагы миома әнә шуның нәтиҗәсе.) Гүзәл затларның җенси мөнәсәбәтләрендә психология зур роль уйный. Яраткан кешесеннән булган теләсә нинди наз рәхәтлек хисләре тудыра, ә ярату юк икән, ир-ат ничек кенә тырышуга карамастан, хисләр өермәсе купмаячак. Күпчелек хатын-кызлардан ишетергә туры килә: менә дигән яшибез, иремә тел-теш тидерерлек түгел, тик мин аны теләмимм.

Беренче кайнар төннәрдәге дәрт ялкыны нигә сүрелә?

Чынлап та, күпчелек ханымнар еллар узган саен сексны бурыч үтәү дип кабул итә башлый (тынычлап ятып йоклар урынга интегү дип әйтүчеләр дә бар!). Алар өчен интим мөнәсәбәтләр – күңел күрүгә корылган эш. Ятакта ир ничек тели шулай җайлашалар да, үз теләкләре хакында оныталар. Билгеле, бу вакытта секс ашарга пешерү кебек үк көнкүреш эшкә әйләнеп кала, дәрт сүнә. Моңа китергән берничә сәбәп бар.

■ Нейроэндокрин системасы үзгәрү. Безнең организмда ашказаны асты, калкансыман, бөер өсте, аналык бизләре бар. Аларның барысы да җенси гормон эшләп чыгаруда катнаша. Берсенең генә эшчәнлеге бозылу да сексуаль тормышка тәэсир итә. Хатын-кыз-

ларда тестостерон гормоны (аны сексуаль гормон дип тә атыйлар) аз булуы да проблемалар тудыра. Аның дәрәҗәсен лаборатор тикшеренүләр аша белеп була. Дөрес, минем дәртем юк дип кенә, үз белдекләнеп, гормоннар эчү катгый тыела. Алар барысы да бавыр авыруларына китерә.

■ Тән авырулары. Хәтта буыннар сызлау да интим тормышны җимерә. Хатын-кызга хас булган авырулар хакында әйтеп тә торасы юк. Төрле ялкынсынулар, хәтта җенси әгъзалардагы сөт (молочница) авыруы да дәртне киметә.

■ Вагинизм. Якынлык турында уйлау белән үк ишекләр ябылган кебек, аналык мускуллары кысыла. Ул психологик халәт белән бәйле. Күпчелек очракта көчләү актына дучар булган хатын-кызларда күзәтелә. Бу очракта психолог кына ярдәм итә ала.

■ Яраткан кешең белән мөнәсәбәтләр салкынаю. Монысы иң төп сәбәп. Интим тормышның җимерелүенә 80 процент очракта ачуланышу, үпкә саклау, шикләнү, көнләшү (дөрес, кайбер хатын-кызларны әлеге хис, киресенчә, дәртләндереп җибәрә) гаепле. Яраткан кешең белән ачыктан-ачык сөйләшү, азрак дәгъвалар белдерү, көнкүрештә кирәгеннән артык таләп итмичә, аның булганына сөенеп (кайчандыр нәкъ аны сайлагансыз бит!), аңлашу да араларны «җылытачак».

■ Үз-үзеңне яратмау. Күп кенә хатын-кызлар мескенләнеп яраттырырга тырыша. Бу иң зур хата. Мин таза, мин ямьсез, дип, үзләренә тәнкыйть белән караучыларны кем сөйсен?! Иремә ошамыйм, янында башкалар булмаганга гына миңа матур сүзләр әйтә дип уйлап йөреп, хатын-кыз бәясен төшерә. Үзен сукыр бер тиенгә дә куймаган хатын-кызда бернинди дәртләнү була алмый.

Афродизиак ашамлыклар

■ Диңгез продуктлары: сөмбаш, палтус балыгы, устрица.
■ Кара шоколад, авокадо, манго, инжир, чикләвекләр, бавыр, йомырка тестостерон гормоны чыгаруны көчәйтә.
■ Кара борыч, суган, имбир, дарчин, фенхель, кардамон, әнис, куркума, керән кебек аш тәмләткечләр белән әзерләнгән романтик кичке аш әкрен генә ләззәтле төнгә ялганырга мөмкин.

Гаиләдә җенси тормышны ничек сакларга соң?

Аны бары тик уртак көч куеп кына озынайтып була. Иң мөһиме: гаиләдә тыныч, уңайлы мохит. Көнкүрештә аңлашып яшәгән кебек, интим тормышта да сөйләшү, тыңлый һәм аңлый белү, оялмау (!), үзең хакында гына уйламау зарур. Кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тоту кагыйдәләре булган кебек, интим тормышта да ир-атлар өчен сексуаль әхлак бар. Ни өчен ир-атлар өчен генә? Чөнки алар сау-сәламәт икән, теләсә нинди җенси акттан ләззәт ала ала. Ә хатын-кызларга моның өчен әзерлек кирәк. Күренекле сексопатолог, профессор Сергей Либих әйтүенчә: «Ир-ат бүген кич хатыны белән якынлык кылырга уйлый икән, ул аны өч көн алдан әзерли башларга тиеш!» Матур сүзләр, аеруча игътибарлы булу безнең күңелне йомшартмый калмый. Сексологиядә эроген урыннар рәсеме дигән төшенчә бар. Ир-атта ул бер генә урында булса, хатын-кызны яраткан кешесе назлый икән, аның бөтен тәне эроген ноктага әйләнергә мөмкин. Кайчак чәчләргә тиеп китү дә дәрт уянуга китерә. Хатын-кыз өчен җенси акт алдыннан озаклап иркәләнү мөһим. Тәнегезнең аеруча сизгер нокталарын табып, яраткан кешегезгә әйтәсез икән, ул рәхмәтле генә булыр. Килгән дәртне арттырып җибәрү өчен интим гель-лубрикантлар куллану да комачау итмәс. Әкрен генә салмак музыка кую, составында афродизиак (җенси дәртне арттыручы матдәләр) булган ислемай сибенү дә (икегезгә дә ошаган) – ләззәтле төннәргә юлны кыскарта ала. Кайбер сексопатологлар иреңне уйлау берничек тә дәртләндерә алмый икән, фантазиядә башка образ тудырырга киңәш итә. Ләкин шунысын да онытмаска кирәк: бу алым иреңне куралмауга китерергә мөмкин. Ә ир-атларга игътибарлырак булырга кирәк. Хатын-кызга ничек рәхәт булганын сорап түгел, ә бәлки аның сулышы, йөрәк тибеше ешаюы, бит алмалары алсулануы аша аңлап була.

Даими җенси тормыш алып барган хатын-кызлар теләк бетү проблемасы белән бик сирәк очраша. Шунысы да мөһим: ирегезнең интим иркәләүләреннән баш тартмаска тиешсез. Чөнки җенси мөнәсәбәтләр гаилә тормышындагы ярашуның төп нигезе булып тора. Шуңа күрә секска вакыт бүләргә онытмагыз. Исегездә тотыгыз: сез – шәхес, бердәнбер һәм кабатланмас! Нәкъ менә сезнең белән ирегез яратышырга әзер. Үзегезне яратыгыз, тормыштан ләззәт алып яшәргә өйрәнегез. Дәртле хатыннар гына ирләрен дәртләндерә ала: ятакта да, тормышта да!

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.

Халык медицинасы

ДАРЧИН БЕЛӘН КОКТЕЙЛЬ

■ 1 банан;
■ 1 чәй кашыгы бал;
■ 150 мл сөт;
■ 150 мл йогырт;
■ ¼ чәй кашыгы дарчин оны.

Бөтен ингредиентларны блендерда болгатырга һәм ятарга 15 минут кала, эчәргә. Әлеге эчемлек тиз арада дәртләндерә, онытылмаслык ләззәт алырга да ярдәм итәчәк.

УСАК КАЙРЫСЫННАН ТӨНӘТМӘ

3 аш кашыгы усак кайрысына 500 мл су салып, талгын утта 5 минут кайнатырга. Төнәтмәне атна дәвамында – көненә өчәр тапкыр яртышар стакан эчәргә. Ул кече оча сөяге әгъзалары авыруларына каршы профилактика чарасы буларак та кулланыла. Шулай ук иммунитетны да ныгыта, салкын тиюдән дә саклый.

ГАСТРИТ ЯШӘРӘ



Ашказаны авырта дип, күпләр зарлана. Кызганыч, әлеге проблема олыларга гына түгел, балаларга да кагыла. Әле мәктәп яшенә дә җитмәгән сабыйларга гастрит, үт юллары тараю, үт куыгы ялкынсыну дигән диагнозлар торган саен ешрак куела. Ризыклар тәэсиреме бу, әллә башка сәбәп бармы? Югары категорияле балалар табибы, гастроэнтеролог, Республика клиник балалар хастаханәсенең 1 нче поликлиникасы каршында эшләүче көндезге стационар мөдире Наталья ГАЙБАРЯН белән әнә шулар хакында сөйләшербез бүген.

Балаларда ашкайнату органнары патологиясе элек дүртенче урында торган булса, хәзер ул, сулыш-тын юллары чирләреннән генә калышып, икенче урынга менде. Беренчедән, халыкның туклану режимы үзгәрде – иртәнге якта ашамыйча йөрү, соңыннан аяк өсте капкалау һәм төнгә каршы күп итеп ашау дөрес туклану режимы түгел. Ризыкларның сыйфаты да икенче. Стрессларның да тәэсире бар. Аннары диагностиканың яхшыруы да моңарчы беленмәгән чирләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Балаларның ашкайнату системасында иң еш очрый торган проблема – үт юллары һәм үт куыгы дискинезиясе (ДЖВП). Әлеге диагноз ашкайнату көйсезлегеннән зарланып килүче 70–80 процент балага куела. Икенче урында үт куыгы һәм үт юллары ялкынсынуы – холецистит, холангит тора. Өченче урында – үт юлларында барлыкка килгән аномалияләр.

Үт куыгы һәм үт юллары белән бәйле чирләрнең дә сәбәпләре төрле: туганда үзәк нерв системасы зарарлану, хроник ялкынсынулар, лямблиоз, аскаридоз. Вегетатив-кан тамырлары дистониясе, неврозлар да ашкайнату органнарына «бәрә».

Үт куыгына бәйле чирләр булганда, баланың эче кинәт һәм каты авырта башлый (чәнчегән яки кисеп җибәргән кебек авырту), ләкин авырту озакка бармый. Яисә киресенчә – авырту сыкрап, бораулап тору характерында һәм дәвамлы була. Уң яктагы кабырга астында авырлык күзәтелә. Баланың аппетиты булмый, күңеле болгана, косарга мөмкин, тәрәте сыеклана. Үт куыгына бәйле чирләр кыздырган һәм майлы ризыклар ашаганнан, чамадан тыш физик нагрузкадан соң да көчәя.

Дөрес тукланмау, азыктагы нитратлар, сыйфатсыз су, даруларны күп куллану аркасында балаларда ашказанының лайлалы катламында ялкынсыну – гастрит та башланырга мөмкин. Әлеге чиргә китерүче сәбәпләр шулай ук төрле: баланың казналыгы дөрес формалашмау, ризыкка аллергия, паразитлар, ашказанына үт сыекчасы эләгү, ашказанында яшәүче хеликобактер пилори микроорганизмы...

Баланың эч авыртудан зарлануы (гастрит булганда эч ач карынга ныграк авырта), аппетиты булмау, ябыгу, гел күңеле болгану, тиз аруы, тән тиресе кору һәм бернинди сәбәпсез субфебриль температура (37,2–37,7) күзәтелү – болар инде табибка күренергә сәбәп.

Ашкайнату органнары белән бәйле проблемалар аеруча яз-көз айларында көчәя. Бердән, көнлек режим һәм ашау-эчү үзгәрә – рационда яшелчәләр, җиләк-җимешләр кими. Һава торышы үзгәрү аркасында салкын тиюләр арта, бу исә иммунитетны зәгыйфьләндерә. Көннәр кыскару белән, күңел төшенкелеге күзәтелә. Рухи халәтнең ашказаны-эчәклеккә турыдан-туры тәэсире бар. Стресс вакытында бүленеп чыккан адреналин кан тамырларының тараюына китерә. Ашкайнату органнарына кан тиешенчә барып җитмәгәнгә, күзәнәкләрнең бер ише үлә, ялкынсыну барлыкка килә.

Балаларны бу чирләрдән саклап калу әти-әнидән даими контроль сорый. «Чипсы», газлы суларны, «гамбургер», «чизбургер», кыздырылган бәрәңгене көн саен куллануның зыянлы булуын һәрберебез белә. Әлеге ризыклардагы җиңел углеводлар организмга май булып утыра. Бәрәңгене кыздыра торган май алыштырылмый. Кат-кат кыздырылган майда агулы матдәләр барлыкка килә. Газлы сулардагы буяулар эчке органнарның лайлалы катламын ялкынсындыра. Гиппократның «Ашаганың ни булса, үзең дә шул буласың», дигәнен истән чыгармагыз.

Бу – мөһим!

- иң беренче ярдәм – диета;
- авыру баланы рухи һәм физик киеренкелектән араларга кирәк;
- газлы суларны беркайчан да ач карынга эчәргә ярамый;
- рафинадланган ризыклардан (колбаса, ак икмәк, туңдырма һәм башкалар) мөмкин кадәр тыелырга;
- суны күбрәк эчәргә. Чиста суны чәй дә, сок та алыштыра алмый. Сәламәт кеше гәүдә авырлыгының һәр килограммына тәүлегенә 30–35 мл су эчәргә тиеш;
- дөрес туклану режимы – көнгә өч тапкыр яхшылап ашап, араларында ике-өч тапкыр җиләк-җимеш, оеган сөт ризыклары капкалау;
- диета бозылган очракта, балага табиб киңәше белән ферментлар бирергә мөмкин.

ИҢ МӘКЕРЛЕ ЧИР



Табиблар чаң кага: гомерләрнең иртә өзелүендә йөрәк-кан тамырлары авырулары беренче урында. Әлеге чирләр иң мәкерлесе дә: кешене соң чиккә китереп җиткерми торып, аның барлыгы беленми. Югыйсә күптән инде дәвасы да табылган, вакытында ачыкланса, авыруның гомерен саклап калу мөмкинлеге дә бар. Медицина фәннәре кандидаты, Казан шәһәрендәге 7 нче клиник хастаханәнең кан тамырлары хирургиясе бүлеге мөдире Илдар ХӘЛИЛОВ үз сәламәтлегебезгә игътибарлырак булырга өнди.

Кешенең иң мөһим органы: баш мие һәм йөрәк. Хәзер, дөрестән дә, медицина бик көчле: йөрәк белән бәйле бик күп һәм җитди чирләрне дәвалый алабыз. Йөрәк авыруларын вакытында ачыклау һәм дәвалау өчен кабул ителгән дәүләт программалары да бар. Ил буенча зур үзәкләр дә ачылып тора. Әмма баш миенә һәм аны тукландыручы кан тамырларына игътибар җитеп бетми. Ә бит гомерләрнең кинәт өзелүенә күп очракта беренче карашка гадәти генә күренгән чир – артерияләрнең атеросклерозы гаепле.

Атеросклероз – кан тамырларына таңкәләр (бляшкалар) утыру. Әлеге вак таңкәләр, чәйнек төбенә утырган юшкын кебек, торган саен тыгызлана, калыная, кан тамырларын тыгылдыра, кан юлын тарайта. Алар таркалып, вак кисәкчекләр кан белән бергә баш миенә үтеп керә. Тамырлар тарайганлыктан, баш миенә кан болай да тиешенчә барып җитми, өстәвенә, ул чүпләнә дә.

Атеросклероз өлкәннәрдә генә була дип уйлыйлар. Әлеге диагноз яшьләргә, хәтта балаларга да куела.

Олы кешеләрдә күзәтелүче классик атеросклерозның сәбәпләре берничә. Беренчесе – нәселдәнлек. Икенчесе – югары кан басымы, шикәр диабеты, канда холестеринның күплеге. Тәмәке тартуның да зыяны шактый. Аз хәрәкәтләнү, майлы-баллы ризыклар белән туклану да тискәре йогынты ясамый калмый.

Яшьләрдә күзәтелгән атеросклерозның төп сәбәбе – аортоартериит – кан тамырларының ялкынсынуы. Аортоартериитның сәбәпчесе исә – аутоиммун процесслар.

Атеросклероз организмдагы теләсә кайсы артерияне зарарларга мөмкин. Иң куркынычы – баш мие һәм йөрәккә илтүче кан тамырларының атеросклерозы. Чөнки бу ике орган сафтан чыкса, организм яшәүдән туктый. Атеросклероз өстән башлана. Ягъни иң беренче булып муендагы кан тамырлары зарарлана. Аягындагы юан кан тамырлары белән проблемалар килеп чыккан кешенең барлык очракта дип әйтерлек йокы артериясендә дә проблемалар була. Монысын тәҗрибәмнән чыгып әйтәм.

Атеросклерозның ике чоры бар. Симптомсыз һәм симптомлы чорлар дип йөртелә ул. Симптомлы очракта кешене инде теге яки бу дәрәҗәдә паралич суккан була. Кайчак тик торганнан гына кулның хәле китәргә, әйбер тотмый башларга мөмкин. Ашыгыч ярдәм килеп җиткәнче, еш кына кешенең хәле яхшыра, авыру чигенә. Бу – беренче сигнал – транзитор ишемик атака.

Ә симптомсыз очрагында кеше үзендә бернинди дә авырту тоймый. Баш миенә илтүче кан тамырлары 75 процент тыгылса гына баш әйләнү, баш авырту, күз алды караңгылану кебек билгеләр булырга мөмкин.

Әгәр дә нәселегездә тик торганнан гына иртә дөнья куйган якын туганнарыгыз булса, бу – беренче «кыңгырау». Югары кан басымы да шикләндерергә тиеш. Кан тамырлары атеросклерозы ачыкланган пациентларның 80 процентында югары кан басымы күзәтелә. Югары басым аркасында кан тамырларының эчке катламы – интима ертыла. Зарарланган урынга атероматоз таңкәләр утыра.

Атеросклероз ир-атларда да, хатын-кызларда да була, ләкин көчле җенестә ул ун елга иртәрәк башлана. 50–55 яшьләрендә инде авыручылар саны ике җенестә дә тигезләшә.

Без үзебезне ничек саклый алабыз? Иң беренче адым – муендагы артерияләргә УЗИ ясату. 50–55 яшьләрдә моны ел саен кабатларга кирәк. Кан тамырларында тарайган урыннар булуы ачыкланса, кан тамырлары хирургына күренергә кирәк. Дәва ысуллары табиб белән киңәшләшеп билгеләнә. Кан басымын, кандагы холестеринны һәм шикәрне нормада тоту да чирне кисәтергә булыша.

Кабатлану булса да, тагын бер кат әйтәм: үлемгә китерүче чирләр арасында атеросклероз беренче урында тора. Әмма вакытында кан тамырларына УЗИ ясатып, дәвалану курсын узсаң, гомерне озынайтып була. Монысы инде үзебездән генә тора.

Лилия ГӘРӘЕВА

Бу мөһим!

Атеросклероз башлануга тәмәке тарту бик зур йогынты ясый. Беренчедән, тәмәкедәге сумала кан тамырларына утыра. Икенчедән, никотин үзе үк кан тамырларының тараюына китерә. Организм тыгылган артерияләрне әйләнеп узу юлларын эзли, ләкин тәмәке тартучыда бу механизм эшләми.

ЗӘЙНӘБТӘН – «АЗУ»

Әле кайчан гына сәхнәгә «Зәңгәр кыңгыраулар», «Мин сине яратам», «Сусау» җырлары белән өр-яңа тавыш, өр-яңа моң булып килеп кергән иде ул. Эфирга чыккан беренче җыры – «Бер егет гармун сайлый» кичә генә яңгыраган кебек булса да, ул көннәр белән бүгенгенең арасы утыз елдан артык. Илһам Шакировның: «Син булдырасың, җырла!» – дигән фатихасы белән башланып киткән иҗат юлы киң һәм озын аның. 1991 елда «Татар җыры» конкурсында – беренче урын (ул чордагы бердәнбер зур бәйге!); 1992 елда тормыш һәм иҗат юлдашы – ире Зөфәр Билалов белән Чаллыга бер көнгә дип барган җирдән ун көн аншлаг белән узган тәүге концертлары, шуннан алган илһам белән Россиянең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә өчәр көн тоташтан алкышларга күмелү; 1996 елда Истанбулда узган «Тюрквизион-1996» халыкара бәйгесенең дипломанты булу; 1999 елда – Татарстанның атказанган артисты, 2009 елдан Татарстанның халык артисты исемнәре бирелү – болар барысы да Зәйнәб Фәрхетдинованың чын талант икәнен сөйли. Әмма язмыш нинди генә үрләр билгеләсә дә, үзенең җир кызы булуын, хатын-кызның чын бәхете гаиләдән икәнен онытмый ул. Җырлый-җырлый тәмле ризыклар пешерсә, илһам килгәндә кылкаләмен алса – күңеленә әнә шул ял инде.
Бүген безгә тәкъдим иткән татар халык ашы «Азу» – аның яратып әзерләгән ризыкларының берсе. Гади генә кебек үзе, ә нинди тәмле!





Кирәк

(4-5 кешелек гаилә өчен)

- 500 г сөяксез ит;
- 2-3 баш эре суган;
- 5-6 эре бәрәңге;
- 2 тырнак сарымсак;
- 4-5 кызыл помидор яки 2 аш кашыгы томат пастасы;
- 3 тозлы кыяр;
- бер тотам укроп белән петрушка;
- тәменчә тоз һәм кара борыч;
- үсемлек мае;
- 0,5 литр шулпа яки кайнаган су.



Фото: Ксения Богданова

Эш барышы:

■ саламлап туралган итне кыздырып алабыз. Май яхшылап кызса, итнең сүле чыкмый, йомшак, сусыл булып пешә. Ит кызгач, янына юка телемләп туралган суганны салабыз.

■ Помидорларның кабыгын салдырып (кайнар суга салып торсаң, тизрәк куба), эре шакмаклап турыйбыз да, аларны да ит янына кушабыз. Помидор урынына томат пастасы да кулланырга була. Тәменчә тоз һәм борыч сибеп, томалап пешерәбез. Помидорлардан чыккан суы җитәрлек булмаса, шулпа яки кайнаган су өстибез.

■ Бәрәңгене бармак киңлегендә саламлап турап (эрерәк кисәкләр белән яки шакмаклап та турарга мөмкин), пешеп җитәр-җитмәслек итеп майлы табада аерым гына кыздырып алабыз. Әлегә бәрәңгегә тоз салмыйбыз.

■ Тозлы кыярны (маринадланган түгел, нәкъ менә тозлы кыяр белән тәмлерәк) шакмаклап яки озынчага турап, кечкенә кәстрүлдә яки табада йомшарганчы пешерәбез. Кыярның кабыгы каты булса, әрчибез, эре орлыгыннан арындырабыз.

■ Кәстрүл яки казанга кыздырылган итне, аннары кыяр белән бәрәңгене салып, тагын бер кат тәменчә борыч һәм тоз сибәбез һәм аз гына шулпа өстәп, тәмам әзер булганчы талгын утта томалап пешерәбез. Сүндерер алдыннан гына туралган үләннәрне һәм издерелгән яки вак угычтан уылган сарымсакны өстибез.

■ Әзер булгач, сак кына болгатып, тәлинкәләргә бүләбез.

Мастер-класс «Беседка» иҗат студиясендә уздырылды.

Беседка
студия творчества
Мастер-классы по всем видам рукоделия
Кулинарные мастер-классы
Товары для творчества
Флористика
г. Казань, ул.Муштари, 2а
(843) 264-51-15, 236-40-64
www.studiobesedka.ru
г. Казань, ул. Абсалямова, 19
(843) 221-03-73
РЕКЛАМА

Чулпан Галиәхмәтовадан

МИЧТӘ ПЕШКӘН КАБАК



Кабаклар тәгәрәп уңды быел! Кабактан төрле-төрле ризыклар әзерләп күрсәттек инде. Ә менә бу юлы – десерт чираты.

Эш барышы

■ Кабакны чистартып, эре-эре телемнәргә турыйбыз да, фольгага тезәбез.

■ Кабак өстенә зур булмаган бер-ике кисәк атланмай куябыз, юылган йөзем җимеше сибәбез. Йөзем урынына туралган күрәгә белән караҗимеш тә сибәргә була.

■ Алар өстеннән буйдан-буйга кашык белән бал агызабыз. Кабакны фольгага төреп, ярты сәгать мичтә пешерәбез.



ҖӘЙГЕ КИЕМНӘРНЕ – САКЛАУГА

Елга ике тапкыр бик мөһим эшебез бар безнең. Яз җитсә – кышкы киемнәрне, көзен исә җәйге киемнәрне саклауга кую. Быел яратып кигән матур күлмәкләрегез киләсе елга да сөендерсен өчен, киемнәр саклауның берничә гади генә кагыйдәсен үтәү мөһим.

■ Беренче һәм төп кагыйдә – кыш көне киелми торган киемнәрне көздән үк яхшылап юып калдыру. Хәтта бер генә тапкыр киелгәннәрен дә юмыйча шкафка тыгарга ярамый. Беленмәгән кечкенә генә тап киләсе язга инде тукымага сеңеп, аннан гомердә дә котыла алмаячаксыз.

■ Икенче кагыйдә – юылган киемнәрне яхшылап киптерү. Урамда, җиләс җилдә киптерсәң, бигрәк тә яхшы. Аз гына дымлы булса да, язга кадәр киемгә бурсыган ис сеңәчәк.

■ Өченче кагыйдә – өзелгән сәдәфләрне, сүтелгән җөйләрне көздән үк тегеп калдыру. Беренчедән, язга кадәр ул сәдәф югалырга мөмкин. Икенчедән, яз көне тиз генә алып киим дигәндә, киемне тәртипкә китерер вакытыгыз булмавы да ихтимал.

■ Дүртенче кагыйдә – трикотаж һәм стрейч тукымадан тегелгән киемнәрне, шулай ук шифон яки челтәр күлмәкләрне төрелгән килеш кенә саклау. Элгечкә элсәң, трикотаж сузыла. Башка киемнең каптырмасына эләгеп, нәфис тукымадан тегелгәненең җепләре чыга.

■ Шакмаклап төргәнгә караганда, киемнәрне бөтереп – рулет сыман төреп саклау отышлырак. Болай урынны да күп алмый, бөгәрләнүе дә азрак.

■ Көя күбәләге кортының йонны гына түгел, ефәкне ярatканын да онытмагыз. Чын ефәктән булган киемнәрне кышка алып куйганда шулай ук көядән саклый торган препаратлар кулланырга кирәк.

■ Сатуда вакуумлы пакетлар бар. Кием-салымны тутырып, махсус нипель аша һавасын чыгаргач, капчыкның күләме бик нык кими. Андый капларның эченә тузан да, көя күбәләге дә, яман ис тә үтеп керә алмый. Юка булганга, берсе өстенә икенчесен куеп, өске киштәдә саклавы уңай.

■ Киемне бурсыган исләрдән саклау өчен, араларына киптерелгән лаванда яки тимьян салынган кечкенә генә янчыклар кыстырып калдырыгыз. Лаванда исе көядән дә саклый.

■ Аяк киеме һәм сумкаларның рәвешләре бозылмасын өчен, эченә йомарланган кәгазь тутыралар. Сумка эченә рулонлап төрелгән җәйге яулык, шарфларны да салырга була. Сумкаларны элеп түгел, тартмада саклаcаң яхшырак.

■ Җәйге эшләпәләрне саклау – шулай ук актуаль тема. Эшләпә бөгәрләнмәсен өчен, аларны берсе эченә берсен кидереп, зур тартмада сакларга мөмкин. Киләсе сезонда тартмасыннан чыгаргач, бөгәрләнгән кырларын үтүкләп җибәрергә була.

■ Шарф, каеш ише җиңел әйберләрне саклар өчен уңайлы элгечне үзегез дә ясый аласыз. Моның өчен гап-гади кием элгече һәм ванна пәрдәсен элә торган пластмасса боҗралар гына кирәк. Элгечнең аратасына тагылган боҗраларны ябабыз да менә дигән лайфхак була.

■ Кием элгеченең аратасына уртача калынлыктагы һәм 40–50 сантиметр озынлыктагы берничә сүс бау бәйләп куйсаң, эшләпәләрне саклар өчен менә дигән җайланма килеп чыга. Гап-гади кер кыстыргычы белән баш киемнәрен бауга каптырып кына куясың.

■ Махсус элмәге булмаган итәкләрне, чалбарларны кер кыстыргычы белән элгечкә каптырып кую бик уңай.

■ Җәйге аяк киемнәрен саклар өчен уңайлы органайзерны аз гына энә тота белгән кеше үзе дә тегә ала. Моның өчен киңлеге – 30 см, озынлыгы 60 см булган ике кисәк тыгыз тукыма кирәк. Тукыма кисәкләрен бер-берсенә уң ягы белән салып, өстән һәм астан тегеп тоташтырабыз. Ачык калган ике кырые сыпылмасын өчен, бөкләп, тегеп чыгарга була. Өске яктан 15–20 см чамасы төшеп (туфлинең биеклегеннән тора), аркылыга җөй салабыз. Анысыннан 20 см төшеп, тагын бер җөй салына – өч бүлемнән торган «капчык» барлыкка килде. Өске ягына ике элмәк ясап, кием элгеченә беркетәбез. Һәр бүлемгә берәр пар аяк киеме сыя.

ЯЗНЫ КӨЗДӘН КАЙГЫРТАБЫЗ

Яз көне гөлбакчабызның тизрәк чәчәккә күмелүен телибез. Җәй башында ук төсләр балкышы күзне иркәләсен дисәгез, чәчәк орлыгын көздән үк чәчеп калдырырга була. Бу ысулны кулланганда алар яз көне иртәрәк тишелеп чыгып, иртәрәк бөреләнә, чирләргә дә бирешмиләр. Октябрь ае – чәчәк чәчәр өчен нәкъ вакыты.
Көннәр суытып, туфрак өсте чиратуга, салкынга чыдам берьеллык чәчәк орлыкларын чәчүгә керешергә була. Орлыклар алдан ук әзерләп куелган түтәлләргә чәчелә. Салкыннар тәмам урнашып беткәч, түтәл өстен салам, черемә, торф, пычкы чүбе, кипкән яфрак белән мүлчәләргә кирәк. Бу – орлыкларны өшүдән дә саклый, язгы якта туфрак өсте дә тыгызланмый.
Берьеллык чәчәкләр гаять тә күптөрле. Без исә үстерү өчен артык көч сорамый торганнарын гына карап үтәрбез.



Лаватера

Бүрәнкә сыман эре, алсу (ак һәм крем төсле сортлары да бар) чәчәкләре белән җәй башыннан октябрьгә кадәр сөендерә. Биеклеге 1 метрдан аз гына артык, бер сабактан әллә ничә тармак чыгара – куаклана. Чәчәкләре мулдан. Туфракка бер дә талымсыз, корыга чыдам, ләкин яктылык ярата.
Аны түтәлнең арткы ягына, койма буйларына утыртырга әйбәт.
Бер ояга 3-4 орлык салалар. Ояларның арасы 30–40 см калдырыла.



Эшшольция

Кояш кебек балкып, карашны әллә кайдан үзенә тартып тора. Сортына карап, 20–50 см биеклегендә үсә. Чәчәкләре уртача зурлыкта, гадиләре дә, чуптарлылары да бар. Күбрәк сары төслесе очраса да, аның агы да, алсу, кызыл төсләләре дә бар. Чәчәккә күмелеп, бик озак утыра. Артык дымны һәм ачылыгы югары булган туфракларны яратмый. Альп таучыкларын бизәр өчен дә матур, түтәл читләренә утыртырга була.



Кашкарый (астра)

Без аны «1 сентябрь гөлләре» дип атый идек. Кашкарыйны белмәгән кеше юктыр, мөгаен. Нинди генә сортлары һәм нинди генә төстәгеләре юк аның. Төркем-төркем итеп утырткanda шулкадәр дә матурлар инде! Җәй уртасыннан кара көзгә кадәр шау чәчәктә ул. Йомшак, ашлы җирне, кояшны ярата. Корылыкны авыр кичерә.



Фото: www.pixabay

Күкчәчәк (василек)

Күкчәчәк дип йөртелсә дә, аның алсу, ак, чия төсләләре дә бар. Сабагы нык, каты. Биеклеге – 80 см. Чәчәкләре гади дә, чуптарлы да була. Бер ай тирәсе чәчәк ата. Аны гөлбакчадагы буш урыннарга, күпьеллык үсемлекләр араларына утыртырга мөмкин. Үзе гади генә булса да, төркем-төркем булып үскәндә бик матур күренә.
Яктылыкны, ашлы, йомшак җирне ярата. Яңгырлы елны елга ике тапкыр да чәчәк атарга мөмкин.

27 ОКТЯБРЬ

ТАТАР РАДИОСЫ ХИТЛАРЫ

ПИРАМИДА
17:00

297 43 77

#ЖАНЛЫКОНЦЕРТ

Партнерлар





Оештыручылар





TATAR RADIOSI
сеть радиостанций





«ТАТАР РАДИОСЫ», ТРАДИЦИЯ БУЕНЧА, ЕЛ САЕН ҮЗ ТЫҢЛАУЧЫСЫ ӨЧЕН УНИКАЛЬ ҖАНЛЫ КОНЦЕРТ – «ТАТАР РАДИОСЫ» ХИТЛАРЫ» КОНЦЕРТЫ ӘЗЕРЛИ. УЛ БЫЕЛ ДА КАБАТЛАНАЧАК!

27 ОКТЯБРЬДӘ «ПИРАМИДА» КОНЦЕРТЛАР ЗАЛЫНДА ТАНЫЛГАН ҖЫРЧЫЛАР СОҢГЫ АЙЛАРДА ПОПУЛЯР БУЛГАН ХИТЛАРЫН МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫНА КУШЫЛЫП БАШКАРАЧАК.
ҖАНЛЫ ТАВЫШ! ОНЫТЫЛМАСЛЫК ШОУ! ИҢ ШӘП ҖЫРЛАР!
«ТАТАР РАДИОСЫ»НЫҢ ТУГАН КӨНЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ГАҖӘЕП ТАМАШАГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

ПАРТНЕРЛАР: ААҖ ТАТТЕЛЕКОМ КОМПАНИЯСЕ, ААҖ КАМКОМБАНК

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА


Кучкар. Очрашуларга һәм яңа дусларга бай ай. Һөнәр өлкәсендә яңа мөмкинлекләр ачыла. Уңыш сезнең тәвәккәллектән һәм вакытында үз сүзегезне әйтә алудан гына тора. Көтелмәгән керем булыр.


Үгезбозау. Моңарчы хәл ителми килгән теләсә кайсы проблема уңай чишелер. Киртәләрне сикереп кенә чыга торган ай. Яңа идеяләрне тормышка ашырырга язмыш үзе ярдәм итә кебек.


Игезәкләр. Берникадәр күңел төшенкелеге күзәтелергә мөмкин. Әмма тәвәккәллек, зиһен үткенлеге гел үзегез белән. Ниндидер яңа керем чыганагы килеп чыгарга мөмкин. Шәхси тормышны көйләр өчен яхшы вакыт.


Кысла. Ноябрь ачыш ае булып күңелегездә калыр. Куплләр өчен үзегез дә бөтенләй яңа яктан ачылырсыз. Ай башында кечкенә генә бер күңелле сюрприз көтелә. Алай да бу чорда яңа эшләр башламыйы тору хәерле.


Арыслан. Үткәндәге эшләрегезнең матур нәтиҗәсен күрерсез. Һөнәри үсеш яки хезмәттәшләрегез арасында абруегыз арту рәвешендә чагылыр ул. Ай ахырына таба җаныгызга ял бирә торган вакыйга көтелә.


Сөмбелә. Көчегезнең артуын тоярсыз. Бу айда ниндидер мөһим эшләр башкару отышлы, чөнки мәшәкатьләр тиз һәм җайлы чишелә. Күңелегезгә хуш килә торган яңа шөгыль табарсыз.


Бизмән. Сез болай да сизгер, хәзер исә ул тагын да көчлерәк. Моңарчы яшеренеп яткан иҗади потенциалыгызны куллану мөмкинлеге чыгар. Тормышыгызга үзгәреш алып килеп, уңышка беренче адым булыр бу.


Чаян. Сезнең өчен рәхәт һәм уңышлы чор килде. Моңарчы җавабы булмаган сорауларыгызга җавап табарсыз. Үз-үзегезне, якыннарыгызны яхшырак аңлый торган вакыйга булыр.


Укчы. Тормышның һәр өлкәсендә уңыш елмаер. Максатчан Укчылар эшләренең яхшы нәтиҗәсен күрер. Кеше фикеренә артык әһәмият бирүегез генә уңышка ирешүдә комачауларга мөмкин.


Кәҗәмөгез. Куанычлы вакыйгаларга бай ай. Иҗади мөмкинлекләрегезне күрсәтергә җай чыгар. Тәвәккәллек сорый торган сайлау алдында калырсыз. Кайчак ышандыру сәләтегезне эшкә җигәргә туры килер.


Сукояр. Бераз мәшәкатьле, ләкин уңышлы чор. Моңарчы алынырга куркып торган зур эшләрне дә артык көч түкми генә башкарып чыгарсыз. Бу сезне тагын да зуррак эшләргә канатландырыр.


Балык. Барысы да сез теләгәнчә булыр. Үзегезгә яңа шөгыль табарсыз. Ә ул исә сезгә яңа мөмкинлекләр ачар. Үз-үзегезгә ышанычыгыз һәм абруегыз артыр. Якыннарыгыз белән башкарган эш уңышлы булыр.

Октябрь дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Алсу Каюмова (20.10.1978) – **Татарстанның атказанган артисты.**

Аксубай районы Яңа Ибрай авылында туа. 2000 елда Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлап, Камал театрына эшкә килә. Актрисаның диапазоны киң, драматик рольләрне дә, характерлыларын да оста итеп ача белә. Хатын-кызның психологиясен яхшы тоемлап, ышандырырлык итеп уйнавы белән тамашачыны җәлеп итә.

Рольләренең кайберләре: «Әлдермештән Әлмәндәр»дә – Гөлфирә, Йөзембикә, «Илгизәр+Вера»да – Нина (икесе дә Т. Миңнуллин әсәре), «Саташкан сандугач»та – Миләүшә (Р. Зәйдулла), «Шулай булды шул»да – Гөлшат (Т. Миңнуллин), «Ханума»да – Сонэ (А. Цагарели), «Хан кызы Турандык»та – Турандык (К. Гоцци). Ире – Татарстанның атказанган артисты Рамил Вәҗиев.

Россия



Тамара Семина (25.10.1938) – **Россиянең халык артисты.**

Курск өлкәсендә туа. Мәктәпне исә Калугада тәмамлый. Булат Окуджава аларга әдәбият фәнен укыта. Актриса булырга хыялланган кыз берүзе Мәскәүгә – ВГИКка чыгып китә. Кабул итү имтиханнарына соңарса да, аның өчен генә искәрмә ясала һәм ул 1956 елда Ольга Пыжова классына кабул ителә. III курста В. Азаровның «Всё начинается с дороги» фильмында Надя ролен башкара. 1959 елда Михаил Швейцер студент кызны Лев Толстой әсәре буенча куелган «Воскресение» фильмында Катюша Маслованы уйнарга чакыра. Фильм хәтта чит илләрдә дә уңыш казана. 1961 елда яшь актрисаны «Киноактер» театр-студиясенә эшкә алалар. Тамашачы аның «Вечный зов»тагы Анфисасын да хәтерли әле.

Чит илләр



Марго Киддер (17.10.1948–13.05.2018) – **актриса, продюсер.**

Канадада туа. Иҗат эшчәнлеген Канада телевидениесендә башлый. Киноактриса буларак тәүге дебюты – Брайн де Пальманың 1973 елда төшерелгән «Сёстры» фильмы. Икенче елны ук инде аны «Тихий день» һәм «Чёрное Рождество» фильмнарында уйнарга чакыралар. Шушы рольләре өчен Канаданың «Джини» кинопремиясенә лаек була. 1975 елда актриса Америкага килеп, берьюлы өч Голливуд фильмында уйный. Дөньякүләм танылуны аңа «Супермен», «Супермен 2» фильмнарындагы Лоис Лейн роле алып килә. «Ужас Амитивилля» фильмы да зур уңыш китергән картиналарның берсе. Аннан соңрак чорларда башкарган рольләре барысы да икенче пландагы гына рольләр. 60 яшендә вафат була.

Фото: www//kamalteatr.ru; www.vokrug.tv





ҖАНГА АЧКЫЧ

(Ахыры. Башы 26 нчы биттә.)

«Рәсем ясамыйча тора алмыйм, – ди ул. – Дога кебек ул минем өчен... Кулыма кылкаләм алсам, тынычланам, бөтен барлыгым ярату, мәхәббәт белән тула. Дөньяга, балаларыма, якыннарыма...» Яшәү, үлем, ялгызлык, нәсел, тамырлар... Аның һәр эшенә ниндидер мәгънә, уйлану, фәлсәфә салынган. «New York Realism» халыкара бәйгесен оештыручылар да Раушаниянең «Үз өеңне эзләү» картинасы өчен Алтын медаль бирергә хәл иткәндә, әнә шуңа игътибар иткәннәрдер. Әйе, кеше дөньяның теләсә кайсы почмагына китеп яшәргә мөмкин – юллар ачык. Әмма үз-үзеннән беркая кача алмый: җанына кадерле булган һәркемне, һәрнәрсәне ул үзе белән уйларында йөртә. «Үз өеңне эзләү» – шул хакта сөйли. (Нью-Йорк шәһәре галереясы үткәргән халыкара бу бәйгегә аның эшләрен улы Рәүф җибәрә. Шатлыклы хәбәр Америкадан ярты елдан соң килә. «1 апрель иде. Рәүф ниндидер хатның тәрҗемәсен салган. «Алтын медальгә лаек булдыгыз», – дигәннәр. «Сез – миллионер», дигән хатлар интернетта еш килә бит, шуңа күрә исем дә китмәде. Бераздан улым шалтырата: «Әллә син сөенмисең дәме?» – ди. «Ә нәрсәгә?» – дим. «Хатны укымадыңмыни?» – ди ул аптырап. «Укыдым. Шуннан нәрсә?» – дим... Океан аша очарга да насыйп булды шулай итеп».)

Яки менә «Ачкычларны ничекләр яратырга» картинасы. «Мин анда бәхет формуласын эзләргә тырышып карадым, – ди әңгәмәдәшем. – Ир-ат – сәгать механизмы кебек, ә хатын-кыз – чәчәк атучы агач. Хатын-кыз кармак белән ирнең йөрәген каптырырга – аның күңеленә ачкыч табарга тырыша. Йозакның аның башында икәнен белми ул... (Дөрес, сирәк кенә йөрәк белән уйлаучы ир-атлар да очрый. Әмма алар белән тормыш итү бигүк рәхәт түгел: үзеңне ир-атның көчле җилкәсе артында итеп тоймыйсың.) Ир-ат исә, баскыч салып, хатын-кызның башында ниләр барын аңларга тели. Ул да ялгыша: хатын-кызның күңеленә йозак башында түгел, йөрәгендә... Бәхетле булу өчен ачкычларны дөрес ярату гына кирәк». Аның бу картинасы «Экстрасенслар көрәше» бәйгесе җиңүчесе Виктория Райдосның шәхси коллекциясендә саклана. (Узган ел «Башкортстан рәссамнары» проектында җиңеп чыгарга аңа Райдос та булыша: «Ачкычларны ничекләр яратырга» картинасын Виктория интернеттагы үз битенә урнаштыргач, Раушаниягә биргән тавышлар бер көндә 700 гә артып китә.)

«Ялгызлык» – узган елгы сериядән. «Халык арасында, әмма берүзем калган кебек басып торам. Миңа сыенган улым белән кызымны санамаганда... Артта – үткәндә очрашкан кешеләрем, алда – киләчәктә күрешәчәкләр... Хәер, тормышта һәркем шулайдыр: башкалар янында булганда да без барыбер ялгыз...»


«Йөк». «Юлда күп йөрим. Аэропортларда гел пассажирларны күзәтәм: берәүләр шундый зур йөк белән сәяхәт итә, икенчеләрнеке – аркадагы кечкенә генә биштәргә сыеп беткән. Мәңгелеккә күчкәндә дә үзебез белән аласы йөкләр бик төрле безнең...»


Хәер, монысы – рәссам әйтергә теләгәннәр. Ә тамашачы, аның картиналары каршында тукталганда бөтенләй башка нәрсәләр хакында уйларга, үзе генә белгән гамьнәрне күрергә дә мөмкин.

...Төсләр дигән идем... Юк, рәссам гомеренең бер чорын да кара буяуларга күмми. Иҗат иткән эшләре дә үзе кебек якты, ихлас, җылы аның.

Гөлнур САФИУЛЛИНА.
Казан–Уфа–Казан.









РАУШАНИЯ БӘДРЕТДИНОВА







2019 ЕЛ ӨЧЕН ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Сез күптән көткән яңалык: хәзер «Сөембикә» журналына ЕЛЛЫК язылу мөмкинлеге бар.
Бер елга язылу бәясе – 1146 сум.
Ярты елга язылу бәясе – 573 сум.
Индекслар: П2204 (алты айга язылу)
П8299 (бер елга язылу)

Татарстаннан читтә яшәүчеләр безне «Роспечать» каталогының журналлар бүлегендә таба ала.
Индекслар: 73002 (алты айга язылу)
25227 (бер елга язылу)



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+